# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

# ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

СТИХИ, ПОЭМЫ
и
ПРОЗА
*Издание второе*

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2010

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ШИГЫРЬЛӘР, ПОЭМАЛАР
һәм
ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР
*Икенче басма*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

## ХАЛЫК УЛЫ

*Күңел Тукайга тора-тора кайта. Шагыйрь яшәгән еллардан ераклашкан саен, аның иҗатының бөеклеге, асыл мәгънәсе тагын да куәтлерәк һәм тирәнрәк ачыла бара. Чын шагыйрьләрнең гомере арифметик саннар белән генә бәяләнә алмый. Даһиларның гомере халык хәтере белән исәпләнә. Тукай бүген дә әдәбиятның алгы сафында баруын дәвам итә, бүген дә милли аң үсешенең юлбашчысы булып кала килә. Заман тудырган һәм милләтне борчыган бик күп сорауларга җавапны Тукай әсәрләреннән табарга мөмкин.*

*Шагыйрьдә гуманизм, Кеше, Халык, Ватан төшенчәләре аша чагылып, бербөтен фикерне тәшкил итә. Татар милләтен, татар җанын, татар телен саклыйм дисәң, Тукай рухын, Тукай мирасын сакларга кирәк. Аңлый белергә кирәк. Тукай – үзенчәлекле, тылсымлы күпер. Шагыйрь үзенә кадәрге әдәби хәрәкәтне дә күзалларга ярдәм итә, бүгенге татар поэзиясенең бер канаты да аңа килеп тоташа. Тукай сүзе – бүгенге мәдәни тормышыбызның үзәге, сәяси кыйблабызның маягы. Заман сулышын тоюда, әдәбиятта бара торган процессларны аңлауда иң зур һәм иң төгәл бизмән булып Тукай әсәрләре тора. Тукай шигъриятенең эчтәлеге күп сыйдырышлы. Анда каһәрле тормышка нәфрәт тә, халыкның якты киләчәгенә ышаныч та бар. Тукай иҗатындагы гомумкешелек кыйммәте иң әүвәл аның бөек миллилеге – татар милләтенең кешелек асылы һәм рухы, афәтле тарихи язмышы, күпгасырлык уй-хыяллары тирәнтен вә колачлы яңгыраш алу белән бәйләнгән. Тукай иҗаты турында сөйләгәндә, иң беренче шул сыйфатлары күзгә ташлана: хакыйкать, халыкчанлык, гражданлык... Шагыйрь – татар поэзиясендә халыкчанлыкның шигъри серен, асылын ачып, аны иң югары идеал итеп раслаган зат. Тукай халыкның үз улы, аның бәгыреннән өзелеп төшкән парәсе иде:*

*Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!*
*Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.*

*Тукай халыкның вөҗдан авазы, «тугры Тукае» булды. Г.Рәхим раславынча: «Халык үзенең җырчысын үзе аралап алды... Ул һаман да безнең беренче «халык шагыйре»без булып калыр». Г.Кәрам да шундый ук рухта фикер йөртә: «Тукаев чын мәгънәсе белән шагыйрь һәм дә халык шагыйре булып калачактыр. Аның шигырьләре буыннан буынга калып, миллионнарча балаларыбыз тарафыннан ятланачак вә аның шанлы исе-*

*ме мәңгегә онытылмаячак». Ф.Әмирхан Тукай вафатыннан соң ук дөнья күргән, шагыйрь хатирәсенә багышланган мәкаләсендә яза: «Милләтемезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас иде. Менә шуңа күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үзе рухындагы нәрсәләр икәнен тойды». Милләт күгендә кара болытлар таралып торганда, Тукай дәртләнеп, канатланып җырлады, халык аһ-зар түккәндә, шагыйрь ачы хәсрәт көен көйләде. Җидееллык иҗат гомерендә татар халык шагыйре дәрәҗәсенә күтәрелгән Тукай әнә шулай милләт җанына мәңгелеккә береккән затлы шәхес булды. Шуңа да аның иҗатына ихтыяҗ бер заманда да кимемәде. Хәтта, китап укучылар азайды, дип борчылган вакытта да Тукай әсәрләре кибет киштәләрендә тузан җыеп ятудан азат иделәр.*

*Шагыйрь апрельдә туган, апрельдә дөньядан үткән. Үлем белән төгәлләнә торган ноктада тукталып калмыйча, халык тормышының һәр этабында актив яши алу һәм алга өндәү, буталчык заманда җанны сафландыра, өмет өсти торган сүз-нәсихәт табу һәм киләчәккә юл күрсәтә белү сәләте – бөекләргә генә хас сыйфат. Вакытлар узу белән әдәбият тарихындагы күп исемнәр тоныклана төште, ә Тукай исә, киресенчә, яңадан-яңа яклары һәм төсмерләре белән балкый гына бара. С.Хәким язганча: «Тукай бүгенгә органик кушылды. Без бер баскыч күтәрелгән саен, ул да бер баскычка күтәрелә, зур эшләр яктысында ул да биектә күренә». Тукай рухы яшәгәндә, Тукай моңнары чыңлаганда, Тукай сүзе җанда кайтаваз алганда, татар милләтенең ерак киләчәккә ниятләгән сәфәре ышанычлы да, якты да, күркәм дә булыр.*

*Гомер баешында Тукайда үткәнгә бер борылып карау, бәя бирү, нәтиҗә ясау хисе тоемлана. Үләренә санаулы көннәр калганда язылган «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсендә шагыйрь «җаны,ояты, хәяты разый булмаган шигырьләреннән» бүлмәсен тазартуын бәян итә. Киләчәктә «үзе яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле» җыентык чыгарырга карар бирә. Китап, Тукай вафатыннан соң, 1914 елда «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре» исемендә Җ.Вәлидинең сүз башы һәм шагыйрь иҗаты турындагы күләмле мәкаләсе белән басылып чыга.*

*Тукайның үзе исән вакытта үтә сайлап тупланган җыентыгында шигырьләре белән бергә чәчмә әсәрләре дә урын алган. Укучы хозурына тәкъдим ителә торган бу китапта да шул принцип саклanды. Сезгә тәкъдим ителә торган «Сайланма әсәрләр» Габдулла Тукайның Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзерге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) әзерләнгән һәм 1985–1986 елларда басылып чыккан биш томлы «Әсәрләр»е (төзүчесе – Рашат Гайнанов) нигезендә эшләнде. Шулай ук шагыйрьнең башка җыентыкларына да мөрәҗәгать ителде.*

*Фәрит Бәшир,*
филология фәннәре докторы

# Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

1909

## Шигырьләр поэмалар

## 1905

## Мужик йокысы

*(Шагыйре мәшһүр Кольцовның шигыреннән тәрҗемә вә икътибас ителмештер)*

Ник йоклыйсың, мужик?
Яз җитте, һәм үсте
Чирәмнәр йортында;
Тор, уян, күтәрел!

Үз-үзеңә кара:
Кем идең, кем булдың?
Нәрсә бар милкеңдә?

Ындырда юк орлык,
Иген юк урырлык;
Атың бар бик начар,
Өч тәңкә торырлык.

Игенең урмаган,
Кибәнең куймаган,
Син үзең дә ялкау,
Хатының «булмаган».

Исеңнән чыгарма:
Сине бай вактыңда
Дустларың мактады
Алдыңда, артыңда;

Син кайда барсаң да,
Урның иде түрдә,
Акчасыз күп артык
Тыныч яту гүрдә.

Синдә мал беткәнне
Дустларың белделәр;
Алдыңда, артыңда
Кул чабып көлделәр.

Урмаган арышың
Ята кырда ятим;
Хәтерең калмасын,
Бер-ике сүз әйтим:

Урмаган арышың –
Берьеллык табышың;
Аны җил коядыр,
Чыпчыклар җыядыр.

Инде кыш та керде,
Игенне бетерде;
Чаналар астында
Ак карлар шытырдый.

Үзеңдә ялкаулык,
Хатныңда аңкаулык;

Кайда кышка азык
Ачлыктан сакларлык?

Күршеләр йөк төяп
Калага саттылар
Һәм, җыйгач күп запас,
Бот сузып яттылар.

Җиктеләр пар аттан,
Өй салып нараттан;
Синең йортта аш юк
Туярлык таракан.

Синең өй балчыктан,
Бөкрәйгән карчыктай;
Кимреп, иске ипи
Ашыйсың тансыктай.

Хатының, балаң ач,
Ашарга булмагач;
Бу көнне күргәнче,
Өеңне ташлап кач.

Күршеләр бай булды,
Ашлары май булды;
Син, ялкау, йоклагач,
Янчыгың сай булды.

Иттеләр өмәләр,
Җыйдылар гөмбәләр;
Һәр михнәт соңында
Рәхәтле көн дә бар.

Тик яткач, Ходаем
Бирми мал сәбәпсез:
Бишмәтең таланган,
Күлмәгең сәдәпсез.

Хак сүзне әйткәнгә
Киң күңлең тарайса,
Урныңнан кузгалма,
Йоклый күр, алайса.

## Хөррият хакында

Кайда китте цензурлык,
Коллык, тарлык, ким-хурлык?
Артка карасак борлып,
Ерак анлар калдыя.

Тигез булды законда
Татар, урыс, япон да;
Ак алъяпкыч, зипун да
Там азатлык алдыя.

Барча цензур ябылгач,
Дәрткә дәрман табылгач,

Кызыл кара ясаган
Кярханәләр бөлдия.

Күп яшь егетләр үлде,
Мәетләр дөнья тулды,
Намнаре бакый булды
Та кыямәт тидия.

Шәкерт, студент – бары,
Дарга асылганнары, –
Сез бу арысланнарый
Онытмагыз тидия.

Кызганмады малларын,
Корбан кыйлды җаннарын,
Җан биргәндә, шатланып,
Көлә-көлә үлдия.
Инде китте элгәре
Зынҗырланган телләре,
Милләтнең былбыллары
Сайрап-сайрап тордыя.

*

Китте хәсрәт, әләмнәр,
Иркенләде каләмнәр;
Булсын күп-күп сәламнәр
Рухларына тидия.

Мәмнүн булсын рухлары,
Изге булсын духлары;
Боларның ах-ухлары
Хөрриятне бирдия.

## Дустларга бер сүз

Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Йосыф-Ягъкуб китабы»ның көен көйлим;
Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим,–
Җебем – кара, инәм каләм булсын имди.

*

И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк, –
Егла-тора алга таба атлыйк имди.

*

Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;
Диңгез якасында торып, без сусамыйк, –
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

*

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!
Мәзлумнәргә якты, нурлы көннәр килде, –
Азатлыкның кояшы тугъды имди.

*

Һәр милләтләр максудларын хасил итә,
Депутатлар ясап, Петербурга китә;
Инде нәүбәт без бичараларга җитә, –
Җыйлып-җыйлып депутатлар сайлыйк имди.

*

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр;
Бу хөррият – Манифесте государьдыр, –
Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди.

*

Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны,
Дин эшендә башчы иттек без аларны;
Яхшы булыр, тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди.

*

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәкъкыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмахына
Кулдан тотып җитәклиләр, белең имди!

## Иттифакъ хакында

Күрең патша хәзрәтен,
Җуйды халык хәсрәтен;
Күргәч фетнә кәсрәтен,
Киңлек бирде бәдәвам.

Файдаланыйк киңлектән,
Ваз кичик мин-минлектән;
Көчле-көчсез тиңлектән
Файда алыйк бәдәвам.

Тырышыйк, и хас вә гам,
Һәр көн үзгәрә заман;
Җитәр, йокламыйк һаман, –
Таңнар атты бәдәвам.

Кызганамын сезләрне,
Ник ачмыйсыз күзләрне?
Киләчәктә бәхетләр
Көтә безне бәдәвам.

Итик, дустлар, иттифакъ,
Бетсен, кадалсын нифакъ;
Тәнемез айрым булса да,

Бер җан булыйк бәдәвам.

Якты көннәр алдале,
Җәһел безне алдалый;
Бүлик без бер алманы
Биш кисәккә бәдәвам.

Җыйналып мәҗлес ясыйк,
Бер-беремездән качмыйк;
Наданлыкка юл ачмыйк, –
Бик күп изде бәдәвам.

Кайчанга чаклы татар
Ушбу уйкуда ятар;
Бер-берсенә ук атар,
Иттифакъсыз бәдәвам?

Ачыйк иттифакъка юл:
Ушбудыр иң тугъры юл;
Сыңар җиңнән ике кул
Чыгарыйк без бәдәвам.

## 1906

## Яз галәмәтләре

Язлар җитте, карлар эри башладылар,
Толыплылар толыпларын ташладылар;
Киемсезләр иркен йөри башладылар,
Тунсызларга нурлы көннәр килде имди.

Ката, чана табаннары ял итәләр,
Шылтыр-шылтыр юлдин арбалар китәләр;
Трантаслар, велосипид, кареталар
Урамнарны чуарлыйлар бер-бер имди.

Каткан, туңган агачларны хәзер кара:
Һәрбересе яшәрешеп яфрак яра;
Бу урманнар бакча булыр бара-бара,
Һәр агачта сандугачлар сайрар имди.

Җиде кат боз астындин чыгар бака,
Баткакларга, балчыкларга бата-бата;
Куе камыш арасындин бака-бака:
«Бака-кака, бака-кака», – диер имди.

Шул бакалар ярга чыгып бакылдаша,
Берсен-берсе аңлашмыйча такылдаша;
Әллә нәрсә киңәшәләр, акыллаша:
Ахры, мантыйк укыганнар бунлар имди.

Кышлар үтеп, яз көннәре килер исә,
Сәхраләрдә йомшак сәба җиле исә;
Аһ, бу көннәр гамькин күңелләрне кисә,
Үткән гомер бер-бер искә төшә имди.

Дәрьяларда бозлар ага тау-тау булып,
Һаваларда кошлар оча болыт-болыт;
И Ходаем, фазлың берлә көнне җылыт,
Үлгән дөнья яңа җаннар алсын имди!

## Кечкенә генә бер көйле хикәя

Бар иде бездә Сафи атлы кеше,
Бик юаш, бичара, беркатлы кеше.

Тире сатып, җон алып чыккан теше, –
Бар эше шул, юк кеше берлән эше.

Тиргәше юк, сугышы юк, төртеше;
Рәнҗеми, таякласа да бер кеше.

Дине таза, бик каты тәкъва кеше,
Дикъкате бар, диндә бик әкъва кеше.

Бик матур корылмыш иде тормышы,
Яхшы иде, бик чибәр көн күрмеше.

Бар иде бер Фатыйма нам хатыны;
Язамын бу хатының бер катыны.

Һәр эштә бу Фатыйма уңган иде;
Мактыймын: уңган иде, булган иде.

Һәм дә ямьсез түгел иде төскә дә,
Модный форма күлмәк иде өстә дә.

Бу хатынның һәйбәтилә гайрәте
Һәр заманда җәлеп итәрди хәйрәте.

Сафи – абыстай иде, бу – абзыйдыр;
Дөньяда мондый Сафилар азмыдыр?

Сафи абзыйга бөтенләй баш иде,
Сафи – муен,
Фатыйма апай – баш иде.

Сафи абзыйны изәр көрпә кеби,
Кабарып үзе ата күркә кеби.

Сафи абзыйга орышны мул бирер,
Сафи абзый һәр заманда юл бирер.

Башын иеп, арык ат кеби торыр;
Фатыймасы аргамак кеби торыр.

Фатыйма апай тарлана һәрнәрсәгә,
Һәм диер: бу нәрсәгә, бу нәрсәгә?

Йә самавыр яки чәйнек шелтәсе;
Лампа янмый – кыска икән филтәсе.

Күз ачырмас, Сафи абзыйны талар;
Әллә кайдан фетнә чыгарып, табар.

Монда язаем бәланең бәгъзесен,
Мең дә берсен, бәгъзеселнән бәгъзесен.

Берзаманда Фатыйма апай иренә:
– Ушбу эшләрне китер! – ди, – җиренә:

Калфагым искерде, яңасы кирәк;
Энҗесе дә, мәрҗәне дә бик сирәк.

Күрмисеңме син фәләннең килнени,
Куфта кигән, мин алардан киммени?

Мин дә сөямен киемне бик кенә,
Ник миңа да алмыйсың син, ник кенә? –

Шул сүз илә мескен ирен төрткәли,
Каршы әйтсә, яңагына сөрткәли.

Сафи абзый китәдер башны бөгеп,
Күзләреннән эссе күз яшьне түгеп.

Сарф итеп базарда актык тиенени,
Кайтадыр алып хатынның киемени.

Күп тә яздым, кариэм, сез ардыгыз
Һәм чыдамас мәртәбәгә бардыгыз.

Инде язам Фатыйманың тормышын,
Нә рәвештә тормышын һәм йөрмешен.

Беркөне килде моңа карчык явыз,
Бәдбәхет, йөзе кара, бер җалмавыз.

Ушбу карчык йөрмеш идеаздырып,
Һәр хатынны тугъры юлдан яздырып.

Монда да килде бу көн бу карчыгым,
Муйнына асып мәкерләр капчыгын.

Диде: «Кызым, мин сине бик кызганам,
Кызгануымнан йөримен, кузгалам.

Син, кызым, нурлы йөзем, бик яшь әле,
Яшьлегең дә җир йөзенә фаш әле.

Яшь хәлеңдә торма бу картың илән,
Сөймә картыңны, утыр артың илән.

Гомреңне үткәрмә, торма ир илән,
Ир илән торганчы, тор син чир илән.

Торма бер көн дә ireң берлән, кызым,
Тормасана, йолдызым, и кондызым!

Ник торасың син ireң берлән, кызым?
Үтә кайгыда кичәң һәм көндезең.

Бер тиенгә тормый бу картың синең,
Яшьлегең, матурлыгың – алтын синең.

Яки, ireң йоклагач, яшьләрне тап,
Бер сүзе җәүһәргә алмашларны тап.

Яшь егетнең куйны – оҗмах, агъзы – бал,
Йөзләре алсу-кызылдыр, буе – тал».

Ушбу сүзләр Фатыйманы җилкетә,
Яшь йөрәк – җүләр йөрәкне селкетә.

Берничә көннәр соңында Фатыйма
Йөртә башлады егетләр катына.

Бер егет үбә килеп, ике егет,
Фатыйманың да кала аузы җебеп.

Кайвакытта баргалыйдыр бакчага:
Гыйффәтен сатарга юк-бар акчага.

Ала башлады егетләр куйнына,
Йоклый иде кул салубән муйнына.

Ирене дә санламыйдыр бер дә һич,
Сафи – абыстай икәнен әйттем ич.

Кичә-көндез уйнамак та уйнамак,
Уйнамакның ахрыны юк уйламак.

Сафи абзый хатынына ялына,
Белсә дә һәм белмәмешкә салына.

Хатынының һәр эшеннән күз буа,
Кара карганы сабын берлән юа.

«Юкны әйтәсез, – ди, – сез, Фатыйма – пакь,
Пакь хатын – судан, дәхи дә сөттән ак».

Сафи булмыш Фатыйма апайга мөрид,
Шул сәбәптән тәфгале һәп ма төрид.

Ничә кәррә ятлар илә күрделәр,
Хатынын солдатлар илә күрделәр, –

Сафи абзыем һәмишә аклыйдыр,
Хатынында бер гаеп тә тапмыйдыр.

Бу рәвештә үтте-китте биш сәнә,
Соңра алтынчы сәнә килде янә.

Бу сәнә дә Фатыйма – шул Фатыйма,
Чакыра, йөртә егетләр катына.

Сафи абзый да һаман аермыйдыр,
Хатының бу хәленә кайгырмыйдыр.

Фатыймаң шулай дисәң – инанмыйдыр,
Бу эшә ниндәй йөрәкләр янмыйдыр.

Нишләсен? – Бар бер угыл, бер кыз бала;
Әнкәсе киткәч, болар үксез кала.

Ничек аерсын тизүк юлдашыны
Һәм гомерлек ярыны, кулдашыны?!

Шул сәбәптән итә алмыйдыр талак,
Гомрене тәнҗис итә, итә һәлак.

Сафи абзый аңламыйдыр шәргый дә,
Кунмамыш башына шәргың мәргый дә.

Шәргың исе кермәгәндер борнына,
Тире урнашмыш шәригать урнына.

Суфилыкка Сафи абзый суфидыр,
Һәр намазны соңга калмый укыйдыр.

Буш суфи нигә ярый дин белмәгәч,
Борнына диннең исе дә кермәгәч?

Белсә дин, Фатыйманы тотмас иде,
Көн саен агулы ут йотмас иде;

Тотмас иде каршысында фәхишә,
Фәхишәлек кайсы диндә якыша?

Куркъканы: үксез кала ике бала.
Нигә куркыйм? Калсын уникe бала!

Шул иде һәр дәмдә халь вә хадисә,
Кичмәде шул хәлдә сале садисә.

Фатыймабыз шул эшендә даимә,
Бар эше шул – каимә һәм наимә.

Күршеләрнең рәнҗиерди җаннары,
Түзмәерди җаннары, вөҗданнары.

Чөнки күршедә көнен-төнен зина, –
Иҗтимагъ итмәз зина берлән гыйна.

Күршенең аш булмас иде ашлары,
Түгелерди бу эшә күз яшьләре.

Күршеләр сабриттеләр, сабриттеләр,
Ахырында Сафины җәбер иттеләр.
Диделәр: «Син яхшылык берлән аер,
Ушбу шахшыдан канатыңны каер.

Югыйсә син тиз барырсың судлара,
Гомрең үтәр судлара, подсудлара».

Кариэм, уйлап кара бу нинди ир?
Мондый ирне йотмый түзгән нинди җир?

Ушбу тәнбиһләр соңында, чар-нәчар,
Сафи абзый хатының гайбен ачар.

«Кит хәзер, – ди, – инде миннән ихтыяр,
Карчыгың кайда чакырса, шунда бар».

И хатын, чүплеккә төшкән йолдызың,
Бәхтияр итмәс сине карт дуңгызың.

Фатыйма китте алубән ястыгын,
Муйнына асып азык-су капчыгын.

Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Пишкадәм остазымның рухы шат.

*

**Бәхре сани**

Мондыйн соңра Фатыймапай ирсез калды,
Ашсыз-сусыз һәм дә йортсыз-җирсез калды.
Инде карыйк, нишләр икән, чирсез калды,
Калган гомре ничек үтәр, карыйк имди.
Инде иркен чыгып йөри урамлара,
Барып ята яфрак асты урманлара,
Исеме керде хикәячек, романлара,
Үткән хәлен көйләп-көйләп язам имди.

Эш үткән шул, бик күрәсе килә ирен,
Балаларын, гомер иткән йортын-җирен;
Белде инде карт шәйтанга булу килен, –
Бигрәк тә начар эш икәнен сизде имди.

Ялгыз йөри бакчаларда, урманнарда,
Очырыйлар салкын яңгыр-бураннар да;
Гомер итә, бүре кеби, урманнарда, –
Урман – өем, урыс – ирем, диер имди.

Бу көнгәчә булган хәлне монда яздым,
Яза-яза артык язып китә яздым;
И Фатыйма, кызганамын – нигә аздың?
Азмаганны һичбер каләм язмас имди.

Тагы ниләр күрсең, шуларны язарым,
Язу язмактан ма гадә юк базарым;
Һич әксүксез, язарым дигәч язарым, –
Башланган эш ташланмаса кирәк имди.

# Сорыкортларга

Аристократ – сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар;
Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!

Вә һәрберсе – губернатор, кикерәләр дөбер-шатыр;
Тамак туйгач төкер-какыр, – бөтен эч май гына, май-май!

Чыгып искене бушатыр, бушаткач, сузылып ятыр;
Көнен сартир, төнен сартир – менә һиммәтләре, ай-һай!

Халык батсын да бетсен, тик боларның эчләре күпсен;
Авызлары ачык бик киң, ниең бар: «Дай сюда, дай-дай!»

Ашар безне дә бу корсак, басар тиз, без болай торсак;
Әйа корсак, вәйа корсак, җиһанны капладың, вай-вай!

Боларның һәрбере Каф яки Кавказ таулары микъдар;
Болар ни йотмаган инде, беләмсең, Миңлебай бабай!

Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак;
Тотып ярсак боларны без заман үткәрми, картаймай.

Ярыйк, дустлар, ярыйк, дим, чөнки безнең бәхтебез шунда;
Шулар йоткан безем икъбалемезне бер дә кызганмай.

Җитәр инде, җитәр инде, давайте, сызганыйк җиңне;
Салып ташлыйк киемне: һич өмид юк җиңне сызганмай.

Һөҗүм кирәк ишаннарга – сорыкорт, гөмбә башларга;
Бетер! Сындыр, кырып ташла, мәгальурра вә билбанзай!

Пәйгамбәрдән калан дин урнына килгән чегәннәрдән
Үзенә башка бер дин, кайдадыр исламымыз, һай-һай!

Эзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр;
Моны сизгән мөселманга чыдау мөмкинме җан җанмай?

Ашап яткан сорыкортка кадалдым мисле хәнҗәр мин;
Боларның мәсләге – безне талау бит, бер дә коткармай.

Яза күрмә, җитәр, артык, Тукаев, вастрок бар бит;
Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.

Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмай;
Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмай.

Чебен җанымны чын юлда бирәм бең кәррә, кызганмыйм,
Минем чөн мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай.

Бу мәзһәб – бер зәһәб мәзһәб: фәляхи эстәсәң, фәзһәб;
Моның саликләре, үлгәнче, ялганнарга алданмай.

## Кемне сөяргә кирәк?

Белү мөшкил – кирәк кемне сөяргә?
Үзең аусаң да, аудармый сөяргә?

Син үлсәң (бет!), сине кем кызгана соң?
Синең зәхмеңгә кемнәр сызлана соң?

Бу дөньяда сине кем иркәли соң?
Бәлаләрдән сине кем киртәли соң?

Синең соң хәсрәтең кемнәргә хәсрәт?
Гамеңнең кәсрәте кемнәргә кәсрәт?

Кеше сатмас кеше тапмак асатмы?
Сине соң кайсы дуст дошманга сатмый?

Синең якты күнең кемнәргә тансык?
Кирәксә, яшь җиренә кара кан сык!

Сине кемнәр генә туйдырмый бер дә?
Күңелсез хәлгә кем куйдырмый бер дә?

Кем үлчи барыйшын синең барыйшка?
Бөтен сүзен, эшен синең карышка?

Тырышма, эзләмә юкны әрәмгә,
Табылмас – юк! Әрәм җәһдең, әрәм лә.

Сиңа, дустым, бу сүз ахыргы сүзем:
Үзеңне сөй! Ярат үзеңне-үзең!

## Көз

Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.
Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.
Мисале зәгъфыран саргайды урман,
Игенчеләр игеннәрне дә урган.
Такыр калды татар башы кеби кыр;
Азык эзли – оча тургай да пыр-пыр.
Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем.
Кояш та яктысын киметте шактый;
Тәәссеф! Басты золмәт, китте якты.
Колакны шаулата инде суык җил,
Тулып эчкә, өрә мисле куык җил.
Ничәйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;
Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.
Мәзарстанга охшап калды кырлар;
Чирәмсездер тигез җирләр, чокырлар.
Үлеп торсам иде мин алты айдай,
Эреп бер йокласам мин сары майдай.
Шулай йоклап, бәһар җиткәндә торсам,
Торып тагы яшел җирдә утырсам, –
Бәхетле шул заман, мин бик бәхетле,
Булырмын шаһ, бәхетле һәм тәхетле.

*

Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарең?
Качан китәр кичең, килер нәһарең?
Килер мәллә кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?

## Государственная Думага

*(«Ай бәгърем, Нәгыймә» көенә)*

Ник бик тиз беттең син, Дума,
Ник җир-ирек алмадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник бик яшьләй картайдың соң,
Ник мәңгегә калмадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник безне кызганмадың соң,
Коллыктан коткармадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Залим башлыкларны тотып,
Ник йөрәген ярмадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник куылдың син үзең соң,
Ник кумадың үзләрен? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник баш бөктең залимнәргә,
Ник тыңладың сүзләрен? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ач-ялангач мужикларга
Кайда ирек, кайда җир? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Бирәм диден, вәгъдә бирдең.
Күрсәт җирең? Кайда? Бир! –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Депутатларны кудылар,
Черки төсле, көш тә көш! –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Иткән гайрәтең бума?

Самый важный генерал да
Түлке күрсәтте күкеш,
Ах җанашым, Дума, Дума,
Кыйлган гайрәтең бума?

Әйдә, дустлар, бер тибрәник,
Акны Тәңре яклар бит. –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Барлык гайрәтең бума?

Караны беркөн каралтып,
Акны беркөн аклар бит. –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

## Үз-үземә

Телим булырга мин инсане гали,
Тели күңлем тәгали биттәвали.

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм,
Кырылмасмы вавы, валлаһе әгъләм?

## Мактанышу

*(«Бакырган»нан)*

Ишан, ишәк өкешер,
Өкешмәктә мәгънә бар;
Ишәк әйтер: «Мин баймын,
Миндә нукта җөгән бар».

Ишан әйтер: «Үкермә,
Мин синнән дә бай әле:
Минем чалмам астында
Ат урларга җөгән бар.

Син булсаң да нукталы,
Бик мактанма, туктале;
Мин мактаныйм, син тыңла,
Минем сүзне тот әле.

Мине ишан дигәннәр
Һәрберсе синдәй ишәк,
Минем изгелегемә
Һичберсе китерми шәк.

Анларны мин нукталыйм,
Һич кызганмыйчук талыйм;
Зур корсаклы байларны
Каезламый туктамыйм.

Булсаң син хайван надан,
Синнән бигрәк мин надан;
Ялкаулык та наданлык –
Бүләк безгә Алладан.

Без халыкны алдыйбыз,
Агуны без «бал» дибез;
Корсак тулгач, милләткә:
– Син аш-сусыз кал, – дибез.

Татарларны мин җигәм,
Минем кулымда җөгән;
Ник җикмәскә, татарлар
Җебегән бит, җебегән.

Кикерсәм дә – изгелек,
Какырсам да – изгелек;
Бер сеңгерсәм – меӊ сәвап,
Күп яшәсен – искелек!

Сиңа сүзем шул, ишәк:
Яхшы булыр килешсәк;
Йөзик ялган эчендә,
Син каек бул, мин – ишкәк.

Булчы син миңа мөрит,
Мине арканда йөрет;
Ачыйк гамәл кибете,
Игътикяфләргә керик».

## 1907

## Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр

**1**

Күп яттык без
Мәдрәсәдә,
Аңламадык
Бернәрсә дә;
Селкенмәдек
Таш төсле без,
Җилбер-җилбер
Җил бәрсә дә.

**2**

Чаршау кордык,
Кояш безгә
Нурын чәчеп
Җибәрсә дә;
Каршы тордык,
Кудык, безгә
Яктылыктан
Ни килсә дә.

**3**

Юрган ябып
Йоклап яттык,
Уйганмадык,
Таң атса да;
Уйланмадык!
Бәхтемезнең
Кояшы ба-
еп батса да.

**4**

Гамьсез яттык,
Сасы җирдә
Чергән тирес-
тәй черсәк тә;
Чиркәнмәдек,
Бу хәлләрдән
Вакытсыз гүр-
гә керсәк тә.

**5**

Кибеп беттек,
Саргайдык без,
Корып беттек
Таяклардай;
Иснәп нәҗес,

Ләззәтләндек
Бөтенләй кыр-
гаяклардай.

**6**

Әхлак, вөждан,
Инсафларны
Сөреп чыгар-
дык истән дә;
Бозылдык шул-
кадәр начар,
Уздырдык без
Иблистән дә.

**7**

Ашсыз-сусыз,
Утын-шәмсез
Тар җирләрдә
Яттык сасып;
Гаетләрдә
Төш күргәндә,
Коендык без,
Бозга басып.

**8**

Капчык ясап
Җиләннәрдән,
Байлар саен
Теләндек без;
Урам саен
Йөгергәләп,
Капка саен
Терәлдек без.

**9**

Күрде милләт
Арзан безне
Агачтан я-
ки таштан да;
Яурупада
Газиз бит без
Күз өстендә-
ге каштан да.

**10**

Оят сатсак
та, ач булдык,
Азган-тузган
Кызлар төсле.
Бетләп яттык
Ачлыктан без
Бетләгән <...>
<...> төсле.

**11**

Укып мантыйк,
Булдык палач,

Чәйнәп сагыз-
лар лач та лач;
Ни он түгел,
Камыр түгел, –
Булдык без пеш-
мәгән калач.

**12**
Ялкаулыкмы
Кирәк бездә,
Аңкаулыкмы
Кирәк бездә;
Булган, пешкән,
Уңган шәкерт
Меңнән бердән
Сирәк бездә.

**13**
Яшь көннәрне
Наданлыкка
Корбан иттек
тә чалдык без;
Суган саттык,
Борчак аттык,
Бәрбәр булдык:
Сач алдык без.

**14**
Байлар итте
Бүләк безгә
Аксак-туксак,
Калган кызын;
Шуларга кол
Булдык, галля-
мә булгач, ки-
чен, көндезен.

**15**
Очраса без-
гә тол карчык,
Хатыннар гәр,
Йортка кердек;
Гөнаһ һич кыйл-
масак та, без
Җәһәннәмгә –
Утка кердек.

**16**
Ни хурлыклар,
Ни зилләтләр
Күрмәдек без
Бу милләттән;
Күрми изде,
Мискин! безне
Күзендә бул-
ган гыйлләттән.

**17**
Хурлау түгел
Татарларны
Бу сүзләрдән

Безнеӊ максуд;
Күзсез булгач,
Нишләсеннәр:
Дөньяда юк
Сукырга суд.

**18**
Сүз юк күзсез
Татарларга,
Сүз бар күзле
Хәзрәтләргә:
Чакырмыйлар
Халыкны без-
неӊ хәлне аз-
маз рәтләргә.

**19**
Күрдек анлар-
дан тик корсак,
Алай борсак,
Болай борсак;
Ай-һай, тирән
Бирән корсак,
Туймас корсак,
Тулмас корсак.

**20**
– Ислах! – дидек,
Күӊел гәрчә
Ислах булмасны сизсә дә;
Кузгалмадык
Почмаклардан,
Җаннар бик күптән бизсә дә.

**21**
Хуш, хуш! хәзрәтләр, без киттек;
Сездән изгелекләр көттек;
Көтмәдек түгел, күп көттек;
Киттек шул без,
Инде киттек.

**22**
Алга, алга!
Алга табан,
Алга, дустлар,
Басыйк табан;
Моӊгар чаклы
Җәһел безне
Артка тарткан
да алдаган.

**23**
Әйдә халык-
ка хезмәткә,
Хезмәт эчен-
дә йөзмәккә;
Бу юлда һәртөрле хурлыкка,
зорлыкларга түзмәккә!

## Шагыйрьгә

*(Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең бер нәсихәте)*

Ничек диләр? Сине «шагыйрь» диләрме?
Шигырь язмак белән шагыйль диләрме?

Сәмави сүз! Халык аңлар микән соң?
Аны аңлаучылар анлар микән соң?

Итәм тәнбиһ: кызыкма бу исемгә,
Бу тәнбиһне төшер һәрдәм исеңгә:

Гомердә син бу ат берлән аталма,
Торып җирдән, сәмалардан ат алма.

Сине күрсәтмәсен һичкем дә, дип: «Бу
Менә шагыйрь, мөхәррир бу, әдип бу». –

Явар өстеңгә бөһтаннар, хәсәдләр,
Корылыр юлыңа һәртөрле сәдләр.

## Тартар кошы сайрый

*(яки татарский марш)*

Тора татар! тора татар!
Уйкудан тиз тора татар;
Тора! тора! тора татар,
Баш күтәргән бар татар!
Үтте төннәр, ай батар,
Чулпан калкар, таң атар!
Тора татар, ди, тора татар, ди.
Сайрый тартар: «Тар-тар-тар».
Тор! тартыш! тиз бар, татар!..
Тор! селкен! кузгал, татар!
Алга адым сал, татар;
Бул син галиел-гальдән гали,
Сезнең бит икъбал, татар!
Һәрбер милләт җиз торбаны
Сезне кушып тартадыр,
Кычкырталар: торалар, торалар!
Тора татарлар – тора татар!
Гыйльмә рәгъбәт сал, татар,
Ит син шуны алтатар;
Корсын туплар! Мәктәпләр –
Безнең арсенал, татар.
Надан булу – гъәр, татар,
Аңгар дөнья тар, татар;
Алсаң өлеш һәр фәннән,
Бәхтең булыр яр, татар!
Һәрбер ак башка алданмас,
Һичшиксез алдар татар;
Курыкма, зинһар, аздырмый
Һәрбер тар чалбар, татар!
Үтсен кышлар сездән дә,
Ачылсын язлар, татар;
Сайрасын былбылларың,
Чалынсын сазлар, татар!
Чыксын шәмсең, эрсен кар,
Шалтырап аксын ермаклар;
Ятмасын мәңге, җитәр! –

Мисле сәлеҗ Сангатар.

## Теләнче

Кыш, буран, салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә,
Җил куа карны, һаман да кар «төшәм» дип тартыша.

Сызгыра җил, ыжгыра, тик кар буранын арттыра;
Шул вакыт мәсҗед катында дөм сукыр бер карт тора.

Кичә-көндез ушбу җирдә, Тәңренең язмыш көне,
Капчыгын тоткан, сорана җәй вә көз, яз, кыш көне.

Кызганыч хәл! Кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен;
Бирсәңезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, «тиен»!

Әйтсәм әйтим инде сезгә: бу кеше бик бай иде,
Эчкәне балдан, шикәрдән, ашлары тик май иде.

Берзаман тоткан иде шөһрәтләре дә даннары
Бу сукыр картның Казан, Ханкирмән, Әстерханнары.

Ул кибетләр, мин сиңайтим, ул хисапсыз маллары,–
Кайсын алсаң, шунсы хәзер: гөлләреме, аллары?

Ул тройка атлары, ул бик матур фәйтуннары, –
Кайда ул төлке толыплар, кайда, ай-һай, туннары!

Шәп иде! Бик шәп иде, мин шуннан артык ни диим?
Шыр ялангач бит, күрәмсез, бирсәңезче бер кием.

Барча хәзрәтләр иделәр бу бабай мәфтүннәре,
Калмады бу карт өчен һич итмәгән әфсүннәре.

Башларын салындырып һәм кәкре-бөкре боргалап
Йөрделәр бу карт янында, юрга тайдай юргалап.

Кайда бай хәлендәге җаннан сөекле дустлары,–
Кайда качкан барчасы: Гайнүкләре, Әхмүшләре?

Кызганыч хәл! Кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен;
Бирсәңезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, «тиен»!

Биш намаз саен намаз әһленә кул сузып кала;
Күрми һәм хәзрәт бу картны, тик кырын күзне сала.

Ә шулаймы? – Акча барда бар да дуст шул, бар да яр,
Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!

## Син булмасаң!

И матур! мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!

Бер минутта ташлар идем бу томанлы моңларый, –
Син мине мискин кыйлып моңландыручы булмасаң!

Мәүҗе-мәүҗе улмазди, болганмазди гыйшкың диңгезе, –
Рихе сар-сар төсле, син болгандыручы булмасаң!

Әкләнердем беркадәр мин шәмсә йә бәдрә бакыб, –
Анлари хөснеңлә ләшәй сандыручы булмасаң!

Тәрк идәрдем вәхшәти, – тик кәндеңә тартып бәни,
Кяинатә каршы ям-ямландыручы булмасаң!

Халисән коллык идәрдем Тәңрия, дәрвиш кеби, –
Күңлеми тәшвишлә шәйтанландыручы булмасаң!

Җаныма касд әйләмәздем хәсрәтемдән гяһе гяһ, –
Кәндеми кәндемгә дошманландыручы булмасаң!

Кайвакыт Мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, –
Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң!

Шигъръә биңзәрди бераз биһүдә әшгарем бәнем, –
Һәр каләм тотканда истән тайдыручы булмасаң!

Әдәби телгә күчермәсе:

## Син булмасаң!

И матур! мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!

Бер минутта ташлар идем бу томанлы моңнарны, –
Син мине мескен кыйлып моңландыручы булмасаң!

Дулкынланмас, болганмас та иде гыйшкың диңгезе, –
Көчле җил төсле, әгәр син болгандыручы булмасаң!

Юаныр идем бераз кояшка йә айга карап, –
Матурлыгың белән аларны каплаучы булмасаң!

Кыргыйлыкны ташлар идем, – мине үзеңә тартып,
Җир йөзендәге бөтен нәрсәгә каршы куймасаң!

Дәрвиштәй, Аллага чын күңелдән кол булыр идем, –
Тәшвиш белән күңелемне аздыручы булмасаң!

Хәсрәтемнән кайвакыт үз-үземә кул сузмас идем, –
Үземне үземә дошманландыручы булмасаң!

Кайвакыт Мәҗнүндәй көлмәс һәм шатланмас идем, –
Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң!

Язганнарым бераз шигырьгә охшар иде, –
Һәр каләм тотканда истән тайдыручы булмасаң!

## Яз

Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз!
Тагын җитте мөнәүвәр яз, аяз яз.

Яза күр, и каләм, яз, гәрчә аз-аз,
Дәһ булсын, әйләсен дил иһтизаз, яз.

Эрергә башлады бозлар вә карлар,
Томаннар чыктылар җирдән вә парлар.

Төшерә искә язның бу томаны
Дөханы ахыр – ахыры заманы.

Кисәктән җанланып, бозлар агалар;
Чабалар, берсене-берсе кагалар.

Белерсең син боларның мәхшәре дип,
Бу бозларны – үлекләр гаскәре дип.

Өрелмеш дип белерсең санки мөгез,
Вә яки мөгезен селкеткән үгез.

Болар әллә бара дәһшәтле судка,
Беленми: кайсы – җәннәт, кайсы – утка.

Бу галәмне тота бертөрле каушау,
Бөтенләй болганадыр, килә шау-шау.

Бөтен сахра гарип төсләр аладыр,
Болыт төсле ала булып каладыр.

Бераздан күрсәтәдер чын төсен җир,
Чәч орлык, сөр сабан инде, бу – чын җир.

Кояш та җып-җылы нурлар сачадыр,
Күңелсез җир йөзе күңлен ачадыр.

Китә, саубуллаша кыш зәмһәрире,
Чыга җиргә яшел чирәм хәрире.

Терелә, җанланадыр халкы галәм,
Яңара халкы Хаува, халкы Адәм.

Шулай шул: уйлата яз төрле якны,
Димәк ки – бер мәматны, бер хәятны.

## Бишектәге бала

Бәхетле нарасидә! Тар бишек тә киң әле аңгар!
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңгар!

Вәләкин, бир заман, ул тик бераз үссен дә ир булсын;
Күренер киң җиһан аңгар кабердән һәм ләхеттән тар.

## Шиллердән

Син бүлеш, сөйсәң мине, гыйльмең вә гыйрфаның белән;
Нәрсә белсәң дә, икәү уртаклашыйк аның белән.

Син исә: «Эстәр исәң, җанымны бирермен»,– дисең,
Нәрсәгә җаның миңа, нишлим синең җаның белән?

## Мөтәшагыйрьгә

Тегермән әйләнә; әйләнсә дә, тартылмыйдыр ярма;
Мәшәкатьләнмә бушка көчләнеп, юл уртасын ярма.

Һөнәрләр күп җиһанда, син дә моннан башка сангать тап;
Чабатаң берлә нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?

Тырышма нафилә җиргә вакты гаҗзеңне икъраргa:
Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга!

Тәшагырь итмә, зинһар, кермә шагыйрь битлегенә син,
Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син.

## Пар ат

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.
Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.
Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.
Берзаман ачсам күзем, бертөрле яп-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә бер тапкыр күрәм.
Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм, дип, төрле уй корган җирем.
Хуш, гомер иткән шәһәр! инде еракта калдыгыз;
Аһ! таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.
Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;
Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.
Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!
Әллә нәрсәм юк кеби; бер нәрсә юк, бер нәрсә ким;
Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.
Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?
Бикмөхәммәт, Биктимер – берсен дә белмим, әллә кем!
Сездән айрылып, туганнар! – җайсыз, уңгайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.
Шундый уйлар берлә таштай катты-китте башларым;
Чишмә төсле, ихтыярсыз акты-китте яшьләрем.
Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан».
Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»
Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!
Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

## Ләззәт вә тәм нәрсәдә?

Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм;
Мин ләзиз шәйләр, вә ли кайсында ләззәт, кайда тәм?–

Бер матур кызның нәзек билен кысып кочмактамы?
Яки, пар юрга җигеп, фәйтун белән очмактамы?

Йә сихерле шишәдән абелхәят эчмәктәме?
Мәст улып, аляме дөньядан тәмам кичмәктәме?

Яки бер ишә вә йә бер каумә баш улмактамы?
Могтәбәр бер шаһ улып, әтрафә фаш улмактамы?

Бер ишан булмакла аштан ашка сикермәктәме?
Май тамак төпкә килеп, бик тәмле кикермәктәме?

Әллә гармунчы булып, һәртөрле көй уйнаудамы?
Бер көй уйнап, моңланып, һәртөрле уй уйлаудамы?

Әллә сәүдәгәр булып, табышка шатланмактамы?
«Шәп табыш бүген, хатын!» – дип, төнлә мактанмактамы?

Баш улып бер гаскәрә, алтын нишан алмактамы?
Баш кисеп, каннар түгеп йөрмәктә, җан алмактамы?

Йә кабартма, сумса берлән чәйләп утырмактамы?
Бик озак, бөкләп аяк, корсакны тутырмактамы? –

Бәнчә, бу дөньяда һич чын төс тә юктыр, ямь дә юк;
Һичберендә бунларың ләззәт тә юктыр, тәм дә юк.

Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар, –
Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

## «Дөньяда торыйммы?» – дип киңәшләшкән дустыма

Тормак ярый: бертуктамый ялганласаң,
Тугры сүзле инсаннарга ялганмасаң,
Вөҗданыңнан шәйтан төсле тыр-тыр качып,
Үзең алдап, башкалардан алданмасаң;

Кардәшеңне үз нәфсеңнән алгалмасаң,
Ярлыларны бурлаклар дип сангалмасаң,
Тик бер ялгыз корсагыңны зурайтырга
Бар гомереңне хезмәт иттерсәң, ялласаң;

Һәрбер байны тәхриреңберлә ауласаң,
Тәкъриреңдә тик майласаң да балласаң,
Бу сүз корсак файдасына зарардыр дип,
Хакыйкатьне яшермәктән оялмасаң;

Эчтән динсез булып,
тыштан «дин», «дин» дисәң,
Ярлыларны дошман күрмәк диндин дисәң,
Мин мәсләкле, мин мәзһәбле, мин эшлекле,
Һәр артыклыкның чишмәсе
«мин, мин» дисәң, –

Читен тормыш! – капиталга чукынмасаң,
Хәзрәтендә тезләр чүгеп укынмасаң;
Тор, рәхәтлән, кәп-кәкрене туры дисәң,
Истибдадның намусына тукынмасаң!

Зинһар, иптәш, хаклык сөйгән булып йөрмә,
Ялган сөйлә, күрмә зиндан, күрмә төрмә;
Тип! дөньяда ач-ялангачларны белмә,
Иске дөнья тузанын ит күзгә сөрмә!
Лязем түгел инсаф, вөҗдан – бер данә дә,
Һич кирәкми гайрәт итмәк, мәрданә дә;
Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү
Фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә.

Тор дөньяда: иманың сат, вөҗданың сат, –

Шулай торсаң, гомрең үтәр бигрәк ансат;
Алдаучылар, кяферләргә дөнья җәннәт, –
Гомрең үтсен рәхәт-рәхәт, ансат-ансат.

Мәгълүм инде: мин кушканча тормыйсың син,
Нифакъ берлә ялган сөйләп йөрмисең син;
Җаннан куркып, куян төсле дер-дер тетрәп,
Чын мәсләкне арлы-бирле бормыйсың син.

Үл! туфрак бул, кайт аслыңа, – аслың яхшы;
Хәнҗәр берлән күкрәгеңә касдың яхшы;
И Җир шары! нидән, белмим, хак сөйгәнгә
Мең кат синең өстеңнән дә астың яхшы.

Хаклык астка күмелгән шул, өсттә түгел,
Шуның өчен астка табан тарта күңел;
Хаклык берлән мәхшәргәчә бергә булыр
Өчен, син дә, – тиз бул, тиз бул, – җиргә күмел!

Бәхил бул, дуст! Мин һәм тиздән менәм дарга, –
Туйсын ашап җансыз тәнне козгын, карга;
Тормыйм инде, – бу дөньядан туйдым инде!
Моңар чаклы торганмын мин гакыл тарга.

## Юаныч

Гомер агымы судай ага,
Кага безне алга таба;
Китәр баштан кайгылар да,
Әкрен-әкрен ага-ага.
Алда көннәр дә бар әле;
Укып, милләт агар әле;
Бер көн килер, ия чыгар,
Бу хәлең мөстәгар әле.
Мәгърифәт эзлә, бар әле,
Истигъдад бездә бар әле;
Адаштым дип егълый күрмә:
Гыйлем чын эз табар әле.
«Ля тәйәсү!» әмрене тот!
Оныт нәүмизлекне, оныт;
Күрәмсең, күктә бар болыт, –
Явар рәхмәт, явар әле.
Безне артка тарткан картлар
Мәзарстан таба атлар.

## Шүрәле

### I

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл –
«Кырлай» диләр;
Җырлаганда көй өчен, «тавыклары җырлай» диләр.
Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.
Ул авылның – һич онытмыйм – һәрьягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы? дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә,
Халкының эчкән суы бик кечкенә – инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;

Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
Бик хозур! рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләк-
ләр, килеп киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.
Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.
Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.
Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,
Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен саулатләре.
Ачыла алдында тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? без дә Хакның бәндәсе.

## II

Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.
Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым...
Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле,
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит «Шүрәле».
Аз гына сабрит әле, әй кариәм! хәзер язам;
Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.

## III

Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар,
Юк түгел аю, бүре; төлке – җиһан корткыч та бар.
Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши,
Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.
Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр,
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр.
Һич гаҗәп юк, булса булыр, – бик калын, бик күп бит ул;
Күктә ни булмас дисең, – очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

## IV

Шул турыдан аз гына – биш-алты сүз сөйлим әле,
Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.
Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.
Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны балта берлән тук та тук!
Җәйге төннең гадәтенчә, төн бераз салкын икән;
Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.
Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,
Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.
Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора;
Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.
Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә,
Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.
Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!
Борыны кәп-кәкре – бөгелгәндер тәмам кармак кеби;

Төз түгел куллар, аяклар да – ботак-тармак кеби.
Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел – көндезләре.
Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.
Кәкре түгелдер моның бармаклары – бик төз төзен,
Тик килешсез – һәрбере дә ярты аршыннан озын.

**V**

Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»
– Бер дә шикләнмә, Җегет, син;
мин карак-угъры түгел,
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел.
Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле, күргәч сине, шатланганымнан үкерәм.
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.
Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети.
– Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр,
мин карышмый уйныймын,
Тик сине шартыма күнмәссең диеп мин уйлыймын.
– Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?
Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.
– Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.
Мин дә көч-ярдәм бирермен: әйдә, иптәш, кузгалыйк,
Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!
Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире,
Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире;
Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын, –
Кариэм, күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын?!
Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу,
Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.
Шүрәле тыккан кулын – селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан хәйләсен – һич балтага күз салмыйдыр.
Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.
Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра.
Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына,
Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына:
– Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәмгенәм;
Мондин ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм.
Башкалардан да тидермәм, ул минем дустым, диеп,
Аңгар урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп.
Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр;
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?
Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша;
Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.
Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;
Ул моның фөрьядларын асла колакка элми дә.
– И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! кем син? исмең кем синең?
Иртәгә килгәнче дустлар, тәндә җаным торса гәр,
Шул фәлән атлы кеше кысты диермен, сорсалар.

– Әйтсәм әйтим, син белеп кал:
чын атым «Былтыр» минем.
Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!
Шүрәле фөрьяд итәдер; аудан ычкынмак була,
Һәм дә ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була.
Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз «Былтыр» мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»
Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
– Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең, –
диләр.
Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!
И җүләр! кысканга былтыр, кычкыралармы быел!»

## Театр

Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.

Театр – яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.

Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең –
Көләрлек булса, булмаса – еларсың.

Күрерсең тормышың нинди: җитешме?
Җитеш булмаса, кай җире җитешми?

Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең, –
Шулай шактый белем тәхсил итәрсең.

Үсәр яхшылыгың, син яхшы булсаң;
Җылы канлы итәр ул, вәхши булсаң.

Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк – кол бул, кирәксә – император.

Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул,
Тәмам хөр ул, вә бик киң ул, азат ул.

Вә ул дарел-голүм, дарел-әдәптер,
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер.

Вәләкин шарты бар: яхшы төзелсә,
Әгәр һиммәт агачыннан өзелсә,

Ул – алма, мөддәте тулганда пешкәч,
Кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч.

## «Алтынга каршы»

И Тәгалә! җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал,
Яндыручы бу мөкаддәс җирне – бу ялкынны ал!

Куш мәләкләргә: җиһаныңны тазартсыннар иде,
Барча алтынны җыеп, дүзәхкә атсыннар иде.

Сап-сары шәйтаннар анлар шунда янсыннар иде,
Җөмлә гасыйлар үчен шунлардан алсыннар иде.

Бу җиһан Иблис вә шәйтаннар белән калыр тыныч,
Бетсен иде шул сары йөз, – шундадыр зур куркыныч.

Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра;
Ялтырап, күзләрне чагып, тугъры юлдан яздыра.

Мин тәмам гиздем җиһанны, – кайда, кайда йөрмәдем,
Тик шул алтыннан – бәла, шәйтан-фәлән һич күрмәдем.

Һәр тараф, һәр җирдә халкың – шул металлның бәндәсе;
Күрмиләр хакны, чөн алтын һәр хакыйкать пәрдәсе.

Бу халыкча: зөһед, тәкъва, тугърылык та, дин дә шул!
Хәзрәти Коръән, Зәбур, Тәүрат та шул, Инҗил дә шул!

## Бер татар шагыйренең сүзләре

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Куркъмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;
Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү харам.

Шикләнмибез дошманнарның көчендин без,
Бүгенге көн Гали, Рөстәмнәргә тиң без;
Шагыйрь гомре хәсрәт, кайгы күрсә күрер,–
Дулкынланмый тормый ич соң өлкән диңгез.

Яхшылыкка эреп китәм – балавыз мин,
Мактап сөйлим изге эшне – бал авыз мин;
Бер яманлык күрсәм, сүгәм, мактый алмыйм! –
Ул тугърыда бик явыз, ай-һай, явыз мин!

Яманлыклар тәмам мине котырталар,
Таяк берлә гүя корсакка төртәләр,–
«Нигә болай?», «Ярамый»,– дип сөйләндереп,
«Тфү, чортлар! ахмаклар!» – дип төкертәләр.

Әгәр атса нахак җиргә бер-бер рами
Мине, димим: «Дуст, бу рәмьиң һич ярамый».
«Яңлыш аттың, иптәш, кире ал, – дип, – угың»,–
Дустлык итәм, кадалганына карамый.

Ачы булгач күңлем, шигърем ачы чыга,
Бәгъзан пешкән дип уйласам да – чи чыга;
Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,
Әллә ничек! – мыр-мыр итеп мәче чыга.

Мактаулыдыр аллы-гөлле нәрсә төсе,–
Тәмле нәрсә була күбрәк ачы-төче,–
Шулай итеп, ачы-төче язсам да мин,
Чыкса кирәк яхшы ниятемнең очы.

Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам;
Тау башына менеп кычкырмакчы булсам,
Биек җир бит, егълырмын дип шүрләп калам.

Максуд җитәр: бара торгач – юл кыскарыр;
Әллә кайда яткан хиссият кузгалыр;
Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим,
Тәңрем фәйзы минем күңлемгә эз салыр.

## Утырышу

Кайвакытта кара күзле, кара кашлы
Матур берлә утырамын кара-каршы;
Шунда ул кыз, әллә ничек сүзгә китеп,
Күргәннәрен, белгәннәрен сөйли башлый.

Мин күзеннән аның күземне алмагач,
Һәр сүзенә «чын, чын» димичә калмагач,
Мин гашыйкны сүз аңлый дип уйлый инде,–
Кадап куйган һәйкәл төсле кузгалмагач.

Кайда аңлау миңа?! бер сүз дә аңламыйм,
Ишетмим дә, тыңламыймын да, санламыйм,–
Бу эшне ул үзе сизсә ачуланыр
Иде, ләкин тугърысы шул: ялганламыйм!

Һич яратмыйм аның шулай саташуын,
Фани дөнья сүзе берлә маташуын;
Телим, ташлап кирәкмәгән вак сүзләрне,
«Сөям, җаным» ләфызларына ашуын.

Һаман сөйли; мин тик ирнен, тешен карыйм;
Йөртәм күзне: калкып чыккан түшен карыйм;
Борнын, аузын, ияклрен, беләкләрен,–
Калмый бармак, тырнак –
һәрбер төшен карыйм.

Тыңлыйм, имеш! юри шулай утыртамын,
Күз алмасын әрле-бирле очыртамын;
Әкрен генә селкенсә дә, кузгалса да,
Торып китә микән әллә дип куркамын.

Мин ул кызны, үз уемча, фәрештә, дим,
Дөнья берлә вакланyуын һич эстәмим;
Аңар күрә үземне бик түбән саныйм,
Аның урны фәләкләрдә, гарештә, дим.

Минемчә, тик яралган ул сөелергә,
Сөяргә һәм куанырга, сөенергә;
Күргән саен, минем төсле гашыйкларга:
«Бу минеке булмас!» – диеп көенергә.

Минемчә, ул үз кадрене сизсен иде,
Дөнья берлә галякасен киссен иде;
Кайгы нигә? шатлык нигә? гомер нигә? –
Мондый юк-бар нәрсәләрдән бизсен иде.

Сүз тыңлаган булып, итәм йөз тамаша;
Дәртем сыймый эчкә, тулып тышка таша;
Ак кулыннан тотыйм, тотыйм, җибәр, диеп,
Гакълым берлә шул вакытта кул талаша.

Шулай итеп сәгадәтле сәгать үтә,
«Ул» да, торып, үз урнына чыгып китә;
Белмәс хәлне,– яшь нәрсә бит,–
аңлый алмас,
Кычкырсам да: «Кочаклашыйк, тукта! тукта!»

## Сөткә төшкән тычкан

*(Бер Америка гәзитәсеннән)*

Ничектер, белмимен, беркөн идән асты кошы – тычкан
Егылган да келәттә бер табак сөткә килеп төшкән.

Йөзеп карый табакта арлы-бирле – һич чыгып булмый!
Сыек сөт бит, – бата, һич тә табактан ычкынып булмый.

Йөри тычкан, йөзәдер, тик торып булмый, йөрәк түзми,
Йөзәдер аркылы, буйга, – котылмактан өмид өзми.

Тырышмак бушка китми бит, бераздан соң була уңгай:
Бу тычкан шулкадәр йөзгән, куерган сөт тә – булган май.

Хәзер бит батмый, – тычкан киерелеп майга аяк баскан;
Сикергән дә табактан ул, чыгып, үз урнына качкан.

*

И карендәш! Син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сөбат!

## ...га

*(Лермонтовтан икътибас)*

И матур! иренмәче, еш-еш кына көзгегә бак!
Күр йөзеңне: нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак!

Ул күзең йолдызлыгын һәм ул кашың кыйгачлыгын,
Ул авызның никадәр үпсәң дә туелмаслыгын

Күр дә: бу шагыйрь мине бигрәк белеп мактый, диген;
Бу шигырь мәгънәсе хәзер бик ачык, якты, диген.

Ихтыярсыз, күңлең уйлар: миннән артык юк, диеп;
Сизми калып, син суларсың: мин матурмын, уф! диеп.

Үз-үзеннән разый булыр, яшь күңел дулкынланыр
Һәм диер: ай-һай, матур мин, кем алыр, тик кем алыр?

Шунда уйларсың: бу шагыйрь бушка аһ ормый, диеп;
Аһлары, фөрьядлары чынлап та урынлы, диеп.

Йә, җанашым, син дә бу хәлдә минем яклы бит, ә?
Раһы гыйшкында һәлак булсам да, мин хаклы бит, ә?

## Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре

Әлли-бәлли итәр бу,
Бохарага китәр бу;
Бохарадан кайткачтын,
Мулла булып җитәр бу.

Яшел чапан кияр бу,
Ап-ак чалма чорнар бу;
Остабикә кирәк, дип,
Бер бай кызын сорар бу.

Сүз дә әйтмичә бирерләр;
Кодачалар килерләр:
«Күп яшәсен яшь мулла,
Остабикә!» – диерләр.

Собраньягә барыр бу,
Указ сорап алыр бу;
Шулай итеп, бу җиргә
Хәзрәт булып калыр бу.

Рәхәт гомер сөрер бу,
Сый-хөрмәтләр күрер бу;
Алла боерса, өй саен
Бәлеш ашап йөрер бу.

Иршатнамә алыр бу,
Зәңгәр йортлар салыр бу;
Мин үлгәчтен, догачы
Булып кына калыр бу.

Гыйззәтем бу, кадрем бу,
Минем йөрәк бәгърем бу;
Куанычым, шатлыгым –
Бу, бу минем бу, бу, бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Сары майдай эр, җаным,
И күңлемнең сайкалый;
Бакчы, күрче: бишеккә
Әкрен генә ай карый.

Мулла әнкәсе булгач,
Утырырмын түрдә дә;
Дөньяда да күп файда,
Рәхәт күреп гүрдә дә.

## Туган җиремә

Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,
И Казан арты! сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач, куймады, кайтарды ахыр җисмеми.

Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,
Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине,–

Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби;
Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби.

Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гаркъ итмәде;
Алды дүрт ягымны ялкын, якмады, харкъ итмәде.

Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!

Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;

Һәр фосулы әрбәгъәң: язың, көзең, җәй, кыш көнең,
Барча, барча ак оек, киндер, чабата, ыштырың!

Һәм көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;
Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.

## Безне урынсыз яманлыйлар

Сәдакать бездә юкмыш; булмаса, ялганымыз бардыр;
Нифакъ выставкасында күп медаль алганымыз бардыр.
Нәзафәткә ригайәт юк, имеш, бездә,– нә бөһтандыр!
Аның чөн йорт саен безнең берәр комганымыз бардыр.
Тагын бездә гыйлем әһле – зыялылар да юк, диләр;
Утыз еллап Бохар, Каргалыда торганымыз бардыр.
Татарда акча юк, байлык та юк, дип, юкны сөйлиләр;
Урам тулы, кулын җәеп, бурыч сорганымыз бардыр.
Санагать юк, һөнәр юк, дип яманлыйлар урынсызга;
Яһүдидән җиңел мал тапкучы ишанымыз бардыр.
Закон белгән юрист юк бездә дип уйлау хата хәтта,
Печән, шалкан базарында закон сатканымыз бардыр.
Табиблек фәне юк дип тә яманлыйлар, ди, дошманнар;
Мәризъләрне ясин берлән сугып екканымыз бардыр.
Мөһәндис барлыгын мөнкир «Кәфер почмагы»на барсын;
Күрер шунда: буен-иңен белеп калганымыз бардыр.
Инанмаңыз, берәү юктыр диерсә бездә шагыйрьләр;
«Таһир»дән, «Бүз егет»тән, шөбһәсез, узганымыз бардыр.
Уңай тормыш болай да, һич имибез баш яңалыкка;
Котырсыннар бозык яшьләр, алар: чалбарлары тардыр.
Хәрам уен-фәләннәрдән зарар тимәс, Ходай кушса:
«Һидая шәрхе» намендә чуен калканымыз бардыр.
Алар алдарлар алдансаң, җәсүр мөфти дә юк, дирләр;
Мәһабәтле, озын буйлы Мөхәммәдъярымыз бардыр.
Художниклар вә рәссамнар дә бардыр, юк диялмаслар,
Мәдинә, Мәккә, дип, төрле буяу сатканымыз бардыр.
Җирәнмәслек мөсафирханә һәм ашханә юк, диләр;
«Сарай»дан чисталыкта ким түгел «Болгар»ымыз бардыр.

## Китмибез!

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
– Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! – диләр.

Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.

Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар – шул иске камчы,
башкалык – тик фәсләре!

Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!

Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз,
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз.

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (гыйззе вә җәл).

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ!

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
– Если лучше вам,
туда сами пожалте, господа!

## Матбага берлә уйнаган бер байга

Булды кондыз, аслы үзгәрде, диеп, мин күрсәм үз,–
Хәзрәтеңне белмәдем! – дуңгыз икәнсең син һәнүз!

Матбага алгач, сине инсане галидер дисәм,–
Кайда галилек сиңа, хали икәнсең син һәнүз!

Тугъры юлны тапты бу, тәүфикъ, имеш, ярый дисәм,–
Лотфе Хактан пакь икән, гари икәнсең син һәнүз!

Гыйльмә нашир булды бу, яхшы кеше булды дисәм,–
Нәйләем ки, бик кабих, шахшы икәнсең син һәнүз!

Бу сәхи, бер бай кеше тәкмил итәр барын дисәм,–
Бер хәсис, мәгърур икән, карун икәнсең син һәнүз.

Бу ганидер, милләтә ярдәм вә гаүнәйләр дисәм,–
Иске Нәмруд, Самри, Фиргавен икәнсең син һәнүз!

«Белдем инде милләтең дәрден»,–
дисең, борчак атып,–
Файдасы юк бер хәрам корсак икәнсең син һәнүз!

*

Туктале, бер көн килер дә, өйрәтер, әлбәт, ләхет, –
Миллионың ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!

Бу кадәр зур, галишан милләт белән ник уйнадың?.. –
Ахыры, син милләти каткан тирең дип уйладың!

Туктале, алдыңда, дуст, мәхшәр дә бардыр, суд та бар,–
Каһре Хак бар; тиз янар корсагың – анда ут та бар!

Анда хакимнәр дә алтыннарга һич алданмыйлар;
Анда адвокат та юктыр, – акчага ялланмыйлар.

И аягың коргыры! намусымызны таптадың;
Золмәтеңнең хөрмәтенә шәмсемезне капладың.

Син үзең сүнсәң сүнәрсең, бу кояш сүнмәс әле;
Ул мөкаддәс, залимең әмренә тиз күнмәс әле.

Ташла тиз! пычратма матбугатны, кит! бер якка кит!
И печән өстендә өргән һәм талашып яткан эт!

## Мәхбүс

*(Пушкиннән)*

Утырам мин тимер читлек эчендә,
Каты кайгы, ачы хәсрәт эчемдә.

Караңгыда, каты җирдә, юештә,
Һаман бертөсле җирдә, бер рәвештә.

Күренде бервакытта бер яңа эш:
Ирек-иркендә үскән яшь каракош

Тәрәзәм алдына килде дә кунды,
Чукырга канлы калҗасын тотынды.

Шуны ул бер чукый, тагын да ташлый,
Очар төсле, канатын селкә башлый;

Чукый, йолка, вәләкин анда-санда
Карап-карап куя миңа табан да.

Бу моңлы иптәшемнең күз карашы,
Тагын да әллә нинди ят садасы

Дигән төсле була: «Мондин күчик без,
Канатлан син дә, сахрага очыйк без!

Азатлык кошлары без, әйдә, әйдә,
Бөрадәр! Тиз китик без шунда, кайда

Җәелгән ямь-яшел кырлар, болыннар;
Тавышсыз, тынсыз, аулак һәр урыннар.

Вә шунда, кайда диңгезләр төтен күк
Булып күренәдер күзләргә күм-күк.

Болытлар сәйритә анда, алара,
Алар артында зур таулар агара.

Вә шунда, кайда аулак, җил дә мин тик,
Йөрербез бергә-бергә – син дә мин тик».

## Вәгазь

*(Лермонтовтан)*

Сиңа сүз шул ки: син сөймә, яратма;
Күзеңне тый, – матур кызга каратма.

Кача күр, яхшы саклан, дуст, гыйшыктан;
Күңелне биклә, юл бирмә ишектән.

Гомерлеккә башың әйләндерер ул;
Ирексез әйләр ул, бәйләндерер ул.

Алыр җаның, – сине җансыз ясар ул;
Авыр тау төсле яньчер ул, басар ул.

Һаман артыр, чигеннән дә ашар ул;
Кибәрсең син, – йөрәк бәгърең ашар ул.

Матур сиңа бирер, бәлки, кулын да;
Беразга гәрчә син рәхәттә бул да, –

Үтәр еллар. Читен булыр синең халь;
Керер сачкә, сакалга шул усал чал.

Кушар ул туктамастан кайгырырга;
Дәлил булып гомергә айрылырга

Сөекләңнән. Бәхетсез син булырсың,
Күңелсез, кызганыч, мискин булырсың.

Бераздан син түшәккә дә егылдың;
Җыерчыклы йөзенә карчыгыңның

Карарсың тилмереп, мәэюс булып син;
Еларсың мөлдерәп, мәхзүн булып син.

Әгәр исеңгә төшсә кайсы чакта,
Качандыр уйнаганы бу яңакта.

Күңелле, якты, нурлы яшь гомернең,
Ничек ашкынганы да яшь күңелнең, –

Килер күз алдыңа ул яшь вакытлар,
Сәгадәтләр, күңеллелек, бәхетләр;

Томанланыр, караңгы, ямьсез уйлар
Синең күңелеңне тырнар һәм агулар.

Бу дөньяда тору, дуст! – ярсыз артык,
Икәү булганчы булмак ялгыз – артык.

Күңеллерәк әҗәлгә баш иярgә
Вә Газраилгә: «Мин ялгыз!» – дияргә.

Күңелдән дә алай ук рәнҗемисең
дә күрмисең ике хәнҗәр ачысын.

Берәү булсаң, ике җан бирмисең син,
Ике рәт җан ачысын күрмисең син.

## Бер гәзитә идарәсе хәленнән

Бәйрәм җиткән. Акча кирәк – касса коры;
Мөхәррирләр язган өчен акча сорый;
Нашир исә, читлектәге бүре төсле,
Идән буе арлы-бирле атлап йөри.

Машинистлар, мөрәттибләр дә бар шунда.
Тарткалыйлар кайсы анда, кайсы монда
Бай абзыйны: «Акча бир дә акча бир», – дип.
Тәңре! яндырма һичкемне бу ялкында.

Кайсы әйтә: «Мин иртәгә итек алам».
Кайсы әйтә: «Мин амиркан читек алам».
«Бирә күр, бай, бүген, – дидер берсе тагы, –
Гарәфә көн мин авылга китеп барам».

Безнең байның ике күзе ялтырады,
Арды, тәмам эштән чыкты, аптырады;
Кызарынды, бүртенде дә, ачуыннан
Иреннәре дер-дер итеп калтырады:

– Әй, конторщик! Счет яз, – ди, –

Шалкановка,
Мансуровка, Зәйнуллинга, Талкановка;
Игълан хакы тиеш бугай урыслардан,
Яз: Петербург, ничек әле... Балкановка.

– Язган, абзый! Һәрберсенә; алачак юк,
Мин булганда исәпләнми калачак юк;
Бәйрәм өчен биш-ун тәңкә бирче, абзый!
Өйдә бер бөртек чәй, шикәр бер шакмак юк.

Колагында байның тавыш шаулый һаман, –
Һәр хезмәтче хезмәт хакын даулый һаман;
Бара торгач нашир абзый качып чыга,
Хезмәтчеләр куа эздән табан-табан...

Бәйрәм инде; һәркем ачылган, шатланган,
Яңа кием кигән, пакьләнгән, акланган;
(Әзин җаниб) бу тарафта нишлиләр соң?
– Алданган һәм агач атларга атланган.

Хезмәтчеләр? – мәгълүм инде, фәкыйрь хәлдә,
Кызганычлы, мескен хәлдә, хәкыйрь хәлдә;
Бәйрәм күрмәк кайда инде?! – газап фәкать:
Бу күренешкә егъла да, көл дә, шак та кат!

*

Синең, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат.
Трактир ач татарга, – сат та тор һәртөрле мәшрубат.

## Ишек бавы

*(Кышкы туйда)*

Ишек бавы бер алтын,

Безнең апай мең алтын;
Җылныйм дисәң, бер алтын
Бир, җизни, тыш бик салкын.
Саранланыр чак түгел,
Бир, җизни, комсызланма;
Акча бирми кертмибез,
Тукта, сабырсызланма.
Синең җанашың булса,
Ул – кайнеңнең апасы;
Без билетсыз кертмибез,
Бу бит җәннәт капкасы.
Безне разый кыйл, җизни,
Без каршыңда ризванбыз;
Хур янына илтәбез:
Без вилданбыз, гыйльманбыз.
Безнең апай гәүһәрдер,
Тәннәре чын мәрмәрдер,
Ләгыль, якут, гәүһәрдер,
Аузы балдыр, кәүсәрдер.
Зур дәүләт ич, җизни, бу,
Тагын моннан зур ни бар?
Торма малың кызганып,
Җан бирсәң дә, урны бар!
Бирсәң – күп бир син безгә,
Без разый түгел әзгә;
Яудыр алтын, көмештән:
Бакыр төрмә кәгазьгә.

## Байроннан

Бераз елдан соң укып бу шигырьне,
Карарсың, бәлки, бу хәсрәтле җырны

Вә уйларсың: ничек шагыйрь яраткан,
Ничек янган, синең өчен җан аткан.

Белерсең: инде шагыйрь юк, диерсең;
Егылган ул, сирәк мәхлук! диерсең.

Фикер кыйл: шунда, ди, инде ул үлгән,
Йөрәген бу шигырь астына күмгән.

## Гыйлавә

Булмадың ярым вә булмассың, беләм, җефтем минем;
Әмма булдың янмага күңлемдә син – нефтем минем.

Дин, шәригать синдә юк; юк тыелуың, юк бойрыгың;
Син – чабак Иделдәге, тик күрсәтәсең койрыгың.

Син закон-статьяларга баш имисең – хөррә син;
Әйләнәсең, тулганасың – түгәрәк син, көррә син.

## Бәйрәм вә сабыйлык вакыты

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы-тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә;
Бәйрәм җитсә, минем дә исемә төшә:
Уйнамакчы булам сыйбъян берлән бергә.

Төшә искә гарәфә кич яткан чагым,
Уйлап: «Кайчан таң?» – дип,
ул атмаган таңым;
Тәти читек, тәти күлмәк-ыштаннарны
Баш астыма өеп куеп яткан чагым;

Таң алдыннан яңлыш йоклап киткән чагым,
Төшемдә дә нурлы бәйрәм көткән чагым;
Әнкәемнең тавышлары колагымда:
«Гает җитте, тор, аппагым! тор, аппагым!»

Таң аткачдин урам буе чапкан чагым,
Мәгъсуманә ләззәт, хозур тапкан чагым;
Корбан ите, төрле тәмле аш өстенә,
Гает укып, көлә-көлә кайткан чагым.–

Уйласаң ул якты көнне, килә күз яшь;
Хозур ла соң! инсан өчен бу хәл, бу яшь!
Бәйрәм көнне күктән җиргә нурлар ага,
Әйтерсең лә чыккан бу көн ике кояш!

Тәңре! чигерче яшемне, синнән сорыйм;
Теләгемне синнән сормый, кемнән сорыйм;
Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм,
Рәхәтләнеп, сикреп, көлеп, уйнап йөрим!

## 1908

## Бер шәехнең мөнәҗәте

И Ходай! мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз;
Зикремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз.

Юкны сөйлиләр җәдитләр, чыннан әһлинсафлә без,
Мактыйбыз ич Тәңремезне иштә бу биш «каф»лә без.

*

Ерак кыйл безне син афате нәфсә,
Мөдавим кыйл һаман кафате хәмсә.

## Тәэссер

*(Лермонтовның «Молитва» сәрләүхәле*
*шигыренә тәкълид)*

Гомернең иң читен, җайсыз, уңгайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән,–

Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр,
һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөкдин.

Ходайа! син тыйган эшләр тәмам әкътагъ вә әбтәр, дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһехак! Аллаһеәкбәр!» – дим.

## Урланган мәгънә

*(Төрекчәдән)*

– Нихәл, шагыйрь? Кәеф хушмы? –
дидем шагыйрьгә беркөнне.
– Кәеф юк, дуст, әле мин күп җәфа чиктем золымнан, – ди.

– Ни булды? Нишләделәр? Әйтче, шагыйрь, кемдер ул залим?
Яшермә инде миннән, кемлеген мин дә белеп калыйм.

– Менә шул: башка шагыйрьләр тынычлык бер дә бирмиләр,
Шигырь язганда, һәр юлга минем мәгънәне урлыйлар.

Алар урлап бетергәчдин минем шигъремдә ни мәгънә
Кала соң? – Калды инде барча әшгаремдә бимәгънә.

Бу шагыйрь дустны мин, мәзлум күреп, гаять тә кызгандым
Вә дәрхаль өстәл өстеннән моның әшгарен эзләндем.

Табып, мин шагыйремнең барча әшгарен карап бактым,
Укып чыктым: бөтенләй буш нәзым, тозсыз шигырь таптым.

Дидем: «Ай-һай, явызлар, нинди залим, уңмаганнар бит,
Моның шигърен алар чынлап та алган, урлаганнар бит!»

## Егет илә кыз

Егет:
– Сөям чүмеч кеби борныңны, җаным.
Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалем.

Җанашым, аһ, иләк аузыңны үпсәм!
Ни кайгы, инде мин шул чакта үлсәм.

Кыз:
– Мәхәббәтсез! лыгырдый шунда җукны,
Үзеңдә килмәгән җир бер дә җукмы?

Егет:
– Ачуланмасана, Гайниҗамалым,
Сине мин кимсетеп әйтмим лә, җаным.

Синең төсле матур кызлар сирәк бит,

Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит.

Сине алсам, чүмечле һәм иләкле
Булам ич – акча туздырмак кирәкми.

## Шәйтанның муенына

– Сөймә юкка, көймә юкка, йөрмәче шул кыз белә;
Бер дә сөйми ул сине, син юкта ул синнән көлә.

– Көлсә көлсен, шул кирәк шул, анда синең ни эшең?
Әйдә көлсен ул матур, дөньяга күрсәтсен тешен.

Теш нурын чәчсен дә дөньяны җибәрсен балкытып;
Җире, күге яктырып китсен әле бер ялт итеп!

## Чын вә Ялган

Әүвәле дөньяда җир юк, су гына булган, диләр;
Анда йөзгәннәр, имеш, тик Чын белән Ялган, диләр.

Бу ике дошманга Тәңредән бирелгән бер көймә,
Бәс, утырганнар көймәгә берсе каршы берсенә.

Күп тә йөрми, Чын белән Ялган чыгарганнар сугыш,–
Булмаса дустлык, җитә бит сугышырга бер юк эш.

Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан, ди дә,
Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә!

## Шагыйрь

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да, –
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз – һаман да яз:
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

## Саташкан

Яз башы. Бозлар китә, ләкин су очмый – җон ага;
Җон белән бер бүрке үлмеш теп-тере мәҗнүн ага.

Тукта, мин капчык ямыйм, соңра сөйләрмен калганын;
Һәрвакытта шул сүтелгән төшләреннән он ага.

Әрни-әрни ләгънәт әйтәм тискәре бу дөньяга:
Җилле көн булган саен, һәрбер урамда ком ага.

Сач тә җиткән, алдырырга куркыныч, бик куркыныч:
Тотса баштан сачтараш, шылтыр да шылтыр җон ага.

Син генә рәхәт кояшын караталасың – карат.
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!

Кайвакытта капкалыйм мин ашны – тәмлесен генә;
Тәмле җимешләр эчендә тәмлесе – пилмән генә.

Син генә бар күккә патша; мин тагын токмач та ашыйм.
Син яшә, һәм мин яшим; әйт: шаш диген, тагын шашыйм!

Күрә калсам эш белән, тырный еланнар мөгезе;
Яп-ялангач, бик киенгән һәм кеше төсле үзе.

Офтанам, ачуланам һәм каш җыерам дөньяга;
Китмәсен алып туратны, – күктә бер козгын ага.

Мәңгегә шул көйгә барырмы кара таплы бәхет?
Өч җәридә шәп, диләр: «Йолдыз» вә «Әлислах», «Вакыт».

Юк бу дөнья, каплаган күк, юк бу җирләр берсе дә,
Юк чебиләр, юк песиләр, «пес-пес»е юк, «перс»е дә.

Юктыр, әлбәттә, боламык – улдадыр әлбә генә;
Юк тарантас, юк карета – барсы да арба гына.

## ...га

*(Мәслихәт)*

Син дисең, имеш ки, шагыйрьгә барам;
Барма, барма – син әрәм аңгар, әрәм!

Үз уеңча, шагыйрь ул җырлый дисең,
Җыр исә тыңларга күңелле дисең.

Син алай иткәнче, и кашың һилал!
Бар да бер кош кибетеннән былбыл ал.

Ал да читлеккә куеп сайрат аны;
Мактасын хөснеңне – син саргайт аны.

## ...гә

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит – чын җүләр түгел диген!

Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи?

Ул синең васфеңдә: «ля шәркыйя, ля гарбия», – ди!

Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла сатып.

## Алдандым

*(Лермонтовка тәкълид)*

Һич элекке төсле алдыңда түбәнләнмим хәзер;
Без ераклаштык, ишет: син – син хәзер,
мин – мин хәзер.

Инде әмриткән сүзең дә аяте Коръән түгел;
Тәмле сүзең яки шелтәң күңлемә солтан түгел.

Син оныттың; мин дә иркемне саташулар белән
Алмыймын алмаштырып, – бушка маташулар белән.

Җитсен инде! күп тәләф иттем сиңа елларны мин;
Һай, тоталмам, ахры, бик күп кудым җилләрне мин!

Әйе, тилмерткән иде шул ул су төсле күзләрең;
Җитте күз, кул җитмәде: күктә шул ул йолдызларың!

Дөньяда һәрнәрсәдән бизгән иде бу яшь йөрәк –
Күрде дошман барчасын; сине сөяргә яхшырак.

Кем белә: егълап аяк астында үткән көннәрем,
Мәгънәсез аһлар белән буп-бушка үткән төннәрем

Бер-бер эш милләткә бирерләр иде, алданмасам, –
Мин, җүләр, гошшакъ рәтенә яшьтән үк ялганмасам.

Җисменә җан өрсәм, үтермәс иде милләт мине;
Та кыямәт зикридәрди, бәлки, тәгъзимләп мине.

Нигә назлы вәгъдәләр биргән идең син ул вакыт?
Ник хәзерге сурәтең күрсәтмәдең соң шул вакыт?

Кувәи шигъриями – җанымны бирдем мин сиңа,
Әйтче, и салкын матур! каршы ни бирдең син миңа?

Хуш, җаным! – сөймим хәзер сине вә синнән башканы;
Син сөя бир алда тагын берне – миннән башканы!

Барча кызлар алдый, дим, һичберсе юк ки алдамас;
Кайсы кызлар алдамас соң, син фәрештәм алдагач!

Кич мине, мин башны бөкмим, мин үземчә зур хәзер;
Син дә бер мәгърурә булсаң, мин дә бер мәгърур хәзер.

Бер Ходайсызлык белән ялганлый башлыйм инде мин;
Күз дә йоммый һәр кешене алдый башлыйм инде мин!

Егъламыйм – яшь түгәсем килми хәзер һичкем белән;
Инде мин һәркем белән дә һәрвакыт уйныйм, көләм.

Яшь кулың бер мәртәбә артык тотып кысмак өчен,–
Тик шуңар, – түгел тагын үпмәк вә йә кочмак өчен,

Мин миңа каршы – гакылсыз яр! –
бөтенләй җир йөзен
Сугышырга чакырырга хәзер идем берүзем.

Актыгы: мин бар вөҗүдемне сиңа иттем фида;
Белмәдең лә, белмәдең кадрем! гөнаһ! и бивафа!

## Кызык гыйшык

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,
Бер кеше салкын су алды бер чиләк.
Өст-башын салган; вәләкин шикләнә
Су салырга тәнгә, чөнки чиркәнә.
Бер куя җиргә чиләкне, бер тота;
Нишләсен мискин – суык су куркыта.
Күп азаптан соңра гайрәткә килеп,
Суны җилкә аркылы читкә сибеп
Куйды да, – син нечкәләп бер баксана: –
«Әл дә тәнгә тимәде», – дип шатлана!

*

Мин моны яздым, бу – гыйшкым миследер;
Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам –
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам.
Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, сер бирмим, имеш!
Бер шигырь язсам да, ялган кул куям,
Мин сөйгәнне белмәсен дип куркудан.
Тугъры килсәм, сүз сөйлим салкын гына,
Булса да күкрәк тулы ялкын гына.
Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай,
Шәһренә күптән барып җиткән бугай.
Кайда ул миннән җибәрмәк хат-сәлам?! –
«Белми китте, күп шөкер» дип шатланам.

*

Белми, дим дә, бәлки, белгәндер әле!
Әллә инде белгәнен белдермәде?
Аңламыйм, төшмим дә аңлау касдына,
Шигъреми җәйдем аягы астына;
Өенә җиткәнче басып кайтса аңар,
Шагыйре зур илтифатыннан санар.

## Өмид

Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт;
Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың берлән җылыт!

Мин адаштым, тугъры юлга ул торып күндермәсә,
Дүрт ягым гыйсъян уты – сүнмәс һич, ул сүндермәсә.

Бер бетү чокрында мин, юктыр нәҗат, коткармаса,
Мәңге тотныр нәрсә юктыр, ул килеп җеп салмаса.

И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр җирдә шәм;
Нәрсә ул дөнья кояшы! син миңа нур бирмәсәң!

Бер йөзең күрсәтсәнә, тугъсын гүзәл көннәр минем;
Чәчкәләр атсын өмид бакчамда ал гөлләр минем.

Мин караңгыда хәзер, үтсен бу таң атмас кичәм;
Таш йотам икмәк белеп, һәм зәһр эчәм, саф су дисәм.

Бер тигез җирдер дисәм, бассам аягымны – бата;
Күп вакытта сискәнәм, яңлыш тотып кош дип бака.

Кап-караңгы. Уңны-сулны күрмим – астны-өстне мин;
Иркәлим дошманны, чәнчәм чын хакыйкать дустны мин.

Кыскасы: җансыз да, вөҗдансыз да мин – яктырмасаң,
«Мин әле кая барам?» – җуйган эзем таптырмасаң.

Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә;
Син дә, вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.

Юк! түбән калмас бу җан: фитърәттә гали булган ул,
Кисмәк өстендә кара кош – иттифакый кунган ул.

## Тормыш

Авырлык төшсә, түз, сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми?

Бу тормыш кем белән туктар талаштан? –
Сугыш син һич тә армас-туктамастан.

Синең төсле берәү ул: бергә-бер сез,
Көрәшкәнне җиңалмый ул каберсез.

Көрәшмәк куркыныч: күп хәлләре бар,
Вәли җиңгәч, ганимәт маллары бар.

Канечкеч ул вә ерткыч юлбарыстан;
Качармы юлбарыстан бер арыслан?

*

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан,
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.

Көрәш угърында ар, тал, тирлә, имгән;
Өмид итмә булышмакны ләимнән.

Әгәрчә зәррә мыскал һиммәте бар,
Аның артында тау-тау миннәте бар.

Сәгадәт талына менсәң – үзең мен;
Ни ярдәм кылсә дә килсен үзеңдин.

Димәс һичкем: «Минем аркамда менде,
Хәзер җүнләп сәлам дә бирми инде!»

## Җавап

Шигъре Лермонтов вә Пушкин – олугъ саф диңгез ул,

Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай – өч йолдыз ул.

Син дә шул диңгез ярында, и агу йоткан көчек!
Телләрең сузган буласың, – җитми, җитми, кит күчеп.

Кит хәзер, ләкин китәрдә сал колак бу сүзгә бер:
Барчы, эт, гомрең буе шул күктә өч йолдызга өр!

## Тешләре ямьсез матурга

«Әйләнәмдә яшь егетләр әйләнә дә әйләнә,
Мин яратсын дип, үзенчә һәрбере ыспайлана;

Нишлим инде, аптырадым», – дип шикайәт әйләдең;
Мактануга охшатып, беркөн хикайәт әйләдең.

Ул егетләрне качырмак? – бик уңайдыр ул сиңа;
Күрсәтимче мин, алайса, бик асат бер юл сиңа:

Син, алар килгәч, тәбәссем ит, фәкать бер көл генә, –
Ник аяк бассын шулай иткәч тә берсе-бер генә.

## Кулың

Чын бәхетледер кулың тоткан колың;
Гайне кодсият вә гыйффәттер кулың.

Ялтырыйдыр санки нурдан бер балык, –
Бер фәрештә күңледәй пакьтер кулың.

Терлә хәсрәттән агуланган күңел;
И матур кыз! зәһрә тирьякътыр кулың.

Яшь күңелне тотса ычкындырмый һич, –
Бер сихерле, серле кармактыр кулың.

Һәр бәхетнең башы шуннан башлана, –
Бер бәхет бәхренә тармактыр кулың.

Мин кулың тоткачтан аштым күккә дә, –
Бер дә чиксез гали чарлактыр кулың.

Әйе, буең да зифа, туба кеби, –
Шул мөкаддәс талга яфрактыр кулың.

Шагыйранә сүз бу, аңларсың үзең, –
Бу сыйфатлардан ераграктыр кулың.

Тукта, бер мактыйм әле дип уйладым, –
Әллә ник мактарга ансаттыр кулың!

## Тотса мәскәүләр якаң!

Ни кыйлырсың, хаҗи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгъмаз ирдең киң җиһанга, малыңа мәгърур булып;
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң.

«Типтереп» йөрдең тәтәйләрдә, театрны сүгеп;
«Нет, князь, постой!» – диерләр, тотса мәскәүләр якаң.

Әйләнәндә әйләнеп йөргән монафикъ муллалар
Әйләнеп тә карамаслар, тотса мәскәүләр якаң.

Яшьләр өстеннән донос илткәндә яхшы «дустларың»,
Бел, үзеңнүк яптырырлар, тотса мәскәүләр якаң.

Бел, хәзер дөнья кяфергә һәм сиңа җәннәт әле;
«Мөэминә зиндан» булыр ул, тотса мәскәүләр якаң!

Тыңламасаң бу нәсыйхәтне, язу бушка фәкать;
Эш үтәр бит, тыңласаң да, тотса мәскәүләр якаң.

Җитмәгәнме бер хатын, өч-дүрт хатын асрау нигә?
Бер хатынга зар булырсың, тотса мәскәүләр якаң!

## Ысулы кадимче

### I

Мәгәр көннәрдә бер көн, әмре трахтир,
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.
Кулымны селтәдем фани җиһаннан,
Агызда папирос, алдымда сыра.
Трахтирларның ул гашыйкларыннан
Тезелделәр килеп катыма торра.
Диделәр: «Кем, ничөн тик утырасың?
Давай гармун китерт, безнеңлә җырла».
Китерттем эскрипкә берлә гармун;
Кызыклы барча нәрсә килде монда.
Фәкать бер бүлмәдә, һичкемсә күрмәс,
Китерттек берничә акшарлы кыз да!
Гуләйт иттек, тәмам шунда исердек,
Бөтен бит-баш кызарды, тотты кызма.
Бераздан санки безгә килде илһам:
«Гыйлем» булдык, хәзер без әһле фәтва.
Керештек тикшерергә муллаларны,
Ки ягъни кайсы азгын, кайсы тәкъва.
Сүгеп теттек җәдитләрне дә, ягъни
Алар динсез: шулай язган китапта.
Хәрам дибез театр, тансаларны, –
«Тегендә типтерү» әүля вә әгъля.
Күңелләр калды саф ширк вә залялдән:
Минутта пот вә пот динлелек арта.
Без оҗмах кошлары булдык бу җирдә,
Бөтен бүлмә тулып китте савапка.

### II

Хисапсыз күп эчелгән – мәлҗегәнмен,
Утырган җирдә шунда калгыганмын.
Шул ук хәлдә миңа бер төш күренде,
Төшемдә бик гаҗәп бер эш күренде.
Сөйлимме мин төшемдә, аһ, нә күрдем? –

Үземне гүяки оҗмахта күрдем.
Тезелгәннәрдер әтрафымда хурлар,
Ки айдан якты йөзләр, балкый нурлар.
Пичәтләнгән шәраблар алга килгән,
Афисиантлар – бары вилдан вә гыйльман.
Эчемлекләр бөтенләй бесплатный,
Берәү дә бер тиен акча түләтми.
Кызык соң! бер кулым берлән эчәм мин,
Икенче кул белән хурлар кочам мин.
Кетердәп тәмле пешкән кәтлите бар,
Закускага дәхи кошлар ите бар.
Бераздан бер тарафтан чыкты ризван, –
Тәмам алтын-көмешкә, нурга чумган.
Дидем: «И хәзрәти бәүуабы җәннәт,
Нидән ләкте миңа бу назы-нигъмәт?»
Диде: «Оҗмахлысың син, чөнки динле, –
Химайәт әйләдең пивнойда динне».

**III**

Төшем шул төшкә җиткәндә уяндым;
«Әле мин кайда?» – як-якка карандым.
Утырган дустларымнан җилләр искән;
Кесәмгә кулны салсам – тайдым истән:
Ходай орган караклар, уңмаганнар,
Кесәмнән пыртманитны урлаганнар.
Шул ук хәлдә килеп керде афисиант,
Рәхимсез йөртәдер күзләрне ялт-ялт.
Диде: «Барин, двадцать рублей с вас.
Давайте скорей, – скоро уж час!»
Дидем: «Динге маи иптәшләр украл;
Сабакылар, они украл да удрал».
Афисиант күп талашмый китте миннән,
Ике данә кылычлы янга килгән.
Ике кулдан икесе килде тотты,
Афисианты яңак төпкә утыртты.
Чыгып барганда, дөп-дөп типкәлиләр,
Яман сүзләр белән сипкәлиләр.
Озак та үтмичә мин часка кердем,
Төшемнең растлыгын шул чакта күрдем.

## Бер рәсемгә

Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә, кашына;
Мең вә мильюн афәрин бу сурәтең нәкъкашына.

Бу озын сачны каян алган икән соң бу кояш?
Күр Ходайның кодрәтене, – бер күзең сал башына.

И кояш! ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.

Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә.

Булсайде оҗмах түрендә әүвәл үк рәсме монын,
Илтифат итмәс иде Адәм дә үз Хаувасына.

Күрсә Һарут берлә Марут, юлдан азмаслар иде,

Бәлки, бакмаслар иде шәйтаннары игъвасына.

Татлы ирнен үпсә бер мән, кәүсәреңне нишләсен?
Пар килер ул дөньяның үлмәс Хозыр Ильясына.

Күрсәйде Иблис ләгыйнь дә, кайда баш тартып йөрү!
Баш иярди сәҗдәгә, кайтып тагын Алласына.

Булмаса сайраулары мәдхе сәнасында моның,
Кит! пычак керсен җиһанның барча сандугачына!

## Киңәш

Якын дустым! сиңа миннән киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.

Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.

Ачып яшьрен хәзинәңне йөрәктән,
Сөйләшмә бер дә артык сүз кирәктән:

Кешеләр үзләрен анчак сөярләр,
Бәхетсезләрнең өстеннән көләрләр.

Алар ерткыч, алардан читтә бул син,
Алар барда бүрең бер якта торсын.

Сереңбелгәч, кызартырлар йөзеңне,
«Җүләр бу!» – дип, ачырмаслар күзеңне.

Кача күр, кош кеби, мактауларыннан,
Хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан.

Әгәр басса сине бер-бер заманны
Еламый йомшамас хәсрәт вә кайгы, –

Утыр аулакка, кайда һич кеше юк,
Сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түк.

Килеп керсә берәү нәкъ шул чагында,
Сиңа мин бер киңәш әйтим тагын да:

Диген син: «Күзләрем никтер авырта,
Өзелми яшь ага кич һәм дә иртә!»

## Шатлык вә хәсрәт

*(Плещеевтән)*

Болытлап көн, яшен яшьнәп, каты күк күкрәгәннән соң,
Тонык, шыксыз һава, күзне ачалмаслык бураннан соң, –

Ачылды берзаманны күк йөзе: инде болыт китте;
Күңелгә шул вакыт бертөрле рәхәтлек тулып китте.

Озаккамы вәләкин бу?.. Бераздан диңгез өстендә
Кара, ямьсез болытлар булдылар пәйда, – шул ук хиндә.

Күрәсең, бу болыт берлә гомерлеккә кояш бергә;
Шулай бергә бугай: шатлык та хәсрәт, канлы яшь берлә.

## Улмы? – Ул...

Ул зыялыдыр, беләмсез: мәгърифәт, хикмәт сата;
Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә – ак яка.

Шәп сикергечтер үзе, нәкъ тастымалы тансаның;
Ул аяклар, мин сиңайтим, «траттата да траттата!»

Бер тарафтан бер гәзит тулган аның статьясы,
Чүпләнеп аннан да моннан төрле-төрле сафсата...

## Мәхәббәт

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байроның, Лермонтовыңмы, Пушкиныңмы – кайсысы?

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, –
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! –
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхраре мәхәббәт миннән уңда, зан итәм, –
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! – мин аларның таңчысы!

## Төлке һәм йөзем җимеше

*(Крыловтан)*

Ниһаять карыны ачкач, Төлке дуст бер бакчага керде;
Ул анда өлгереп җиткән йөзем җимешләрен күрде.

Йөземнәр күңгә каршы ялтырыйлар ләгыль, якуттай;
Боларга хәйләкәр ач Төлкенең күзләр яна уттай.

Йөземнәрне ашарга үрелә, сикергәләп карый;
Күрә күз, җитмидер буй, – ул тәмам хәлдән төшеп арый.

Озак михнәтләнеп калгач, йөземнәрне алалмыйча,
Алалмау хурлыгын үз өстенә йөкләп калалмыйча:

«Йөземнәр чи, әле өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр, – ди. –
Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә анлар!» – ди.

## Бәйрәм бүген

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!

Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын;
«Ул киенгәндер», – дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
«Ислемай сөрткән икән дөнья!» – дидем: бәйрәм бүген!

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән:
«Күңле нечкәргән!» – дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын:
Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

## Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш

### I

Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,
Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә.

Алдымызда ат кәмитен күрәлем
Һәм Микитин җәмгатенә ирәлем.

Бу Казанда хуп-хуп эшләр күп торыр,
Һич моның тик бери тәкый юк торыр.

Хак Тәгалә нәрсә кыйлса, ирке бар,
Рус Микитиннең Казанда циркы бар.

Шунда бардыр бер мөселман пәһлеван –
Бик озын, бик көчле, гайрәтле җиван.

Шәп батыр: Зәркум кеби, Салсал кеби;
Хәйләгә оста, Сәет Баттал кеби.

Бер хикәят килде телемгә арый,
Яхшылап сөйләп биреп булса ярый.

Таңга калсын тиречеләр, итчеләр,
Шәмчеләр дә, майчылар, кибетчеләр.

Берзаман бардым Печән базарына, –
Шунда мин таптым азык язарыма.

Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.

Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

Һәр заманны монда хәлләр шул икән,
Һәркем үз хәле белән мәшгуль икән.

Йөгрешәләр сөртенә дә абына
Барча мөэминнәр «Көфер почмагы»на.

Нинди эш булган соң анда, нәрсә бар?
Бер сугыш чыкканмы әллә йә пожар?..

Мин дә чаптым шунда мөэминнәр белән.
Мәскәүски якка күз салсам, күрәм:

Тәгәрәп юл уртасыннан таш килә,
Таш түгел лә – бер киселгән Баш килә.

Баш килә шундый каты, шундый кызып,
Полный ход килгән трамвайдан узып.

Һәр тараф тулган караучы – юк саны;
Баш «Көфер чаты»на җиткәч туктады.

Күрделәр бер кисәк адәм башыны;
Агълаю килде дә түкте яшене.

Гәүдәсе юк бер гаҗәеп Баш ирер;
Шәһит ирер, ике күзе яшь ирер.

Юк аягы, гәүдәсе һәм юк кулы, –
Бер кисек баштыр, һаман сөйләр теле.

Сакалы ак, һәм йөзеннән нур чыкар,
Күз камашыр – һәркем йөзенә бакар.

Йөзен орды туфракка, кыйлды зари,
Зари-зари егълады шәмче Гали.

Башны күргәч, ихтыярсыз җан ачый:
Әй җаным, бу кайсы мискиннең башый?

Агълыйдыр һәркем, күзеннән яшь сыгып,
Агълый кибеттән кәләпүшләр чыгып.

Һәм аяк астында яткан тиреләр
Барча: «Ай мискин дә ай мискин!» – диләр.

Шунда тау-тау торган он капчыклары,
Агълыйлар саилче кыз, карчыклары.

Агъламаска – бер мөселман башы бу,
Һәр мөселман бәндәнең җанашы бу.

Агълый Кисекбаш, моңын-зарын сөйли,
Ак сакаллар: «Нәрсә булды?» – дип сорый.

Кызганычлы бер кыяфәт, яшьле күз
Берлә мискин Баш болай дип башлый сүз:

«Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз,
Мин хаҗи – бардым хаҗә туксан тугыз.

Күп тәваф иттем Хиҗаз сәхрасыни,
Җиддәсен һәм Мәккәсен, Сангасыни.

Мин гласныйлыкта тормышдым янә
Бу шәһәрнең Думасында ун сәнә.

Һәм дә Мәскәүдән дә маллар алмышым,
Сумына туксан тиенне чәлмешем.

Итә ирдем көн дә бер Коръән хәтем,
Алмышым гомремдә унбишләп хатын.

Кич барыр ирдем «Тәтәйләр рәте»нә,
Әүрелеп көндез кеше сурәтенә.

Бар иде картлыкта алган хатыным,
Бер балам – аһ, күз нурым! аһ, алтыным!

Карт көнемдә бунлар иптәшләр иде,
Яхшы юлдашлар вә сердәшләр иде.
Тартып алды бунларый миннән Дию,
Сезгә важибтыр миңа ярдәм кыйлу.

Анларый алды да керде коега,
Кайгы куймый күзләремне уйкуга.

Кыйлмасаңыз сез миңа ярдәм әгәр,
Сезгә миннән яүме мәхшәр дәгъва бар!»

## II

Шунда картлар җәмгулыб киңәштеләр:
«Нишлибез соң? – агълап эш булмас!» – диләр.

Кайсы әйтә: «Патшадан солдат сорыйк,
Ул Диюне җәдрә берлән аттырыйк».

Кайсы әйтә: «Садри Максуди барыр,
Мәсьәләне, бәлки, Мәҗлескә салыр.

Без аның өчен күп тырыштык, шар салып,
Ахырында Думага да сайладык».

Кайсы әйтә: «Камчылы ишан барыр,
Ул Диюнең, бәлки, сихрен кайтарыр».

Уртадан бер күп белекле карт кеше
Әйтә: «Бу хакта минем фикрем шушы:

Тыңлагыз, бу – тик Карәхмәтнең эше;
Инде ул, мәгълүмеңез, көчле кеше.

Ул барып алсын Диюнең җаныны,

Кайтарыр ул бу Кисекбаш каныны».

Барча картлар: «Яхшы бу, яхшы!» – диләр,
«Вәт менә рәхмәт! Бабай тапты», – диләр.

Бу бабай фикрен туры итсен Хода!
Итте бер мөэмин кеше шунда нида:

«Миңлебай! бар, тиз, Карәхмәтне чакыр!» –
Чапты китте Миңлебай чатыр-чатыр.

Үтмәгәндер күз ачып йомган заман,
Килде дә җитте Карәхмәт – каһреман.

Эстәде Башны күтәреп бакмага:
Гайрәтен вә куәтен күрсәтмәгә.

Ничә кем зур әйләде – күтәрмәде,
Зәррә мыскал җиреннән тибрәтмәде.

Һич күтәралмый аны, хәйран кала;
Көчләнә, тирли батыр, хәлдән тая.

Ул Баш әйтә: «Бу Карәхмәт шаштымы?
Ул күтәрерлек җиңел бер башмы бу?

Бер түгел, меңләп Карәхмәт килсә дә,
Хәтта Зайкин, Медведев бер булса да,

Һич насыйп булмас аларга кузгату,
Файдасыздыр кузгатырга күз ату.

Чикмәсен бушка газапны – булмый да,
Чөнки бар мең пот тәгассыб бу мидә.

Бу мидә йөзләп гыйнад амбары бар,
Бу мидә мең пот сыраның пары бар.

Бу мидә бардыр җәһаләт ун вагон,
«Мин беләмлек» дәгъвасы – бер мең вагон.

«Иске – изге» фикре бардыр ун келәт,
«Һәр җәдит – кяфер» – егерме склад...»

**III**

Хазирун: «Аһ, нинди изге Баш!» – диләр,
«Тик янә урнына ябышмас», – диләр.

Инде мөэминнәр каты кызгандылар,
Чын күңелдән Баш өчен сызландылар.

Һәм үрә торды батырның чәчләре,
Газбилә аузыннан утлар чәчрәде:

«Мин, – диде, – дөньяда тормыйм, ичмасам,
Шул Дию-залим башыны кисмәсәм.

Бармыймын хәтта Микитин циркына,
Шул Дию башына күңлем җилкенә.

Шунсыз инде бер дә рәхәт күрмәмен,
Һәм Пугач-Зайкин рәтенә кермәмен.

Йә үләм мин, йә шуның муйнын кисәм,
Хак гыйнайәт әйләр ирсә, мин басам».

Бар халык та: «Бар, Карәхмәт, бар», – диләр,
«Бу Кисекбаш хатынын коткар», – диләр.

«Бармыйлармы? Мин барам, әлбәт, барам,
Бармасам, дөнья йөзе булсын хәрам!..»

Бу гаһедтән соңра Башның күзләре
Яктырып китте – ачылды йөзләре.

Ул Баш әйтә: «Әй батыр, рәхмәт сиңа,
Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа.

Барча иркеңнән вә циркыңнан җөда
Булдың инде, бәс, сиңа миннән дога.

Әйдәгез, әй, әһле базар, берьюлы
Фатиха: уңсын Карәхмәтнең юлы!»

Шул вакыт куллар белән тулды сәма,
Чын күңел берлән кыйла һәркем дога:

«И Ходаем, бир Карәхмәткә мәдәт,
Ушбу юлда бир аңар көч һәм сәләт!»

Берзаман куллар салындылар төшеп –
Күрделәр: килде трамвай җитешеп.

Пәһлеван вагонга җирләште кереп,
Алды «пересадка» берлән бер билет.

Барча мөэминнәр озатып калдылар:
«И Ходаем, рәхмәтеңне сал!» – диләр.

Кузгалып китте вагон, җилдәй бара,
Баш йомарланып китә, җирдән бара.

Башны күргәч, кузгалып гайрәтләре,
Өрде барча итчеләрнең этләре.

Йөгерәләр алды-артлы бер көтү
Кәкре койрыклар! – кая Башны җитү!

Ул барадыр йөгрек аттан да каты
Һәм җәядән аткан уктан да каты.

Үз хәленчә китмәде тыр-тыр вагон,
Таш ата башка малайлар яльгабун.

Калды уң якта «Китаплар ханәсе»,
Сулда – «Әлислах» идарәханәсе.

Бер сәгать, бер көн вә өч көн киттеләр, –
Зур завод Крестовниковны үттеләр.

Җиде көне, төне чөнки киттеләр,
Нагяһан бер сахрая ирештеләр.

Шунда җиткәчтен трамвай туктады,
Баш йомарланып барадыр туктамый.

Туктагач шунда сихерле машина:
«Нишлибез?» – диде Карәхмәт Башына.

Ул Баш әйтә: «Син вагоннан төш хәзер,
Бик якынлашты кирәкле төш хәзер.

Без барыйк азрак җәяү алга табан;
Иштә бу алдыңдагы күлдер – Кабан.

Бар дорыр күлнең төбендә бер кое,
Шунда керде ул теге залим Дию!»

**IV**

Сүз рәте килгәч, итәм әзрәк бәян,
Таки яшьрен күл төбе булсын гаян.

Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьяләр;

Мөгезе мәрмәр боланнармы кирәк,
Алты йөз башлы еланнармы кирәк.

Су анасы, – бик явыз, йөзе кара, –
Ел да бер угъланны йә кызны ала.

Шул заман, кем, килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.

Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу күлгә сачтылар.

Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».

Шул заманнан бирле, кем, алтын-көмеш
Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.

Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр,
Дип, гакыллы зур хәкимнәр сөйлиләр.

Киптисә, бер дәфга кузгалып бары –
Күл буеның мәдрәсә талибләре

Барча байлыкны җыячаклар, имеш,
Һич һөнәрсез бай булачаклар, имеш.

Ел-ел артыннан һаман үтмәктәдер,
Күл буе талибләре көтмәктәдер...

**V**

Әйдә максудка! Алар көтсен әле,

Сүз Кисекбашка килеп җитсен әле.

Ул Карәхмәтнең билендә бавы бар;
Бауның алты мең колачлы буе бар.

Бау белән ул эшне яхшы җайлады:
Бер очын Башның теленә бәйләде.

Бер очын учлап, Кабанга чумды ул,
Туп-туры шуннан коега тотты юл.

Ул төшә, бер көн төшә, өч көн төшә;
Туктамый инмәктәдер көндез-кичә.

Бер – аягы әйләнәдер, бер – башы,
Һәр минут, һәрдәм Хозырдыр юлдашы.

Ул иңә, Алла сүзен тәкрар кыйла,
Тышта агълыйдыр Кисекбаш, кайгыра.

Нәкъ төшеп киткәнгә ун тәүлек тула, –
Ахры, җиргә аяклары төртелә.

Пәһлеван, гаять арып, эштән чыгып,
Ун минут торды катып, гакълын җыеп.

Бервакыт безнең батыр ачты күзен:
Бер сарай алдындадыр күрде үзен.

Шундый яхшыдыр ки, һич мондый сарай
Салмагандыр Кәчимеский Ибырай.

Капка башында яшел ләүхә тора;
Анда иштә ушбу сүзләр укыла:

«Монда сакин бужи фирка җания,
Табигыйннәр мәзһәбе Гайнания».

Тартты куптарды Карәхмәт капканы,
Соңра тиз-тиз элгәрегә атлады.

Керде дә күрде: сарайда бер хатын
Җәлбитәрлек һәр кешенең дикъкатен:

Йөз нуры дүрт якны әнвәр әйләгән,
Тәңренең гыйшкы аңар кяр әйләгән.

Намаз укыр ул ахирәт хатыны,
Аһ итәр – күккә чыгадыр төтене.

Күз яше сәҗдә җирене болгамыш;
Ул Кисекбашның хәлале бу, имеш.

Үтте аннан, китте башка бүлмәгә,
Шундый күренеш – кызганычтыр күрмәгә:

Анда биш йөзләп мөселманнар тулы,
Багълыдыр һәрберсенең аяк-кулы.

«Алла, Алла! саклый күр утдин!» – диләр,
«Кыйл шәфәгать, йа Баһаветдин!» – диләр.

Сикерәләр, җенләнәләр үзләре,
Һәм акайган, кот очарлык күзләре.

Чөн болар һәп пәһлеванны күрделәр;
Бер авыздан бөйлә фөрьяд кыйлдылар:

«Мәрхәмәт ит, и Карәхмәт, безгә син;
Безне коткар, из Диюнең измәсен.

Һәр минут үткән саен, без куркуда:
Бу Дию һәр көн бишәр адәм суя.

Күп идек без былтыр, үткән көз генә,
Инде калды барчабыз биш йөз генә».

Шунда бер бүлмә күренде – шактый киң;
Күрде батыр: шунда яткан ул ләгыйнь.

Биниһая зур башы – гөмбәз кадәр;
Ни сәбәптәндер башында фәс тә бар.

Салынып төшкән килешсез мыегы –
Бик озындыр, мисле күсе койрыгы.

Бармаклары охшар адәм гәүдәсе, –
Күп татарны имгән ирде ул гасый.

Билгеле инде, Карәхмәт курыкмады;
Ул аны «тор! тор!» диюбән төрткәли.

Нәгърәләр берлән Диюне уйгата;
Һич уянмый уйкусыннан, ул ята.

Төрткәли торгач, ниһаять, уйгана,
Куркынычлы күзләре уттай яна.

Ул Дию уйганды: дүрт якка бакар,
Көфер сүзләр, агъзыйдин утлар сачар:

«Ник йөрисең монда рөхсәтсез кереп,
Һич оялмый тәмле уйкум боздырып?

Белмисең, махсус колониям бар минем,
Мәхкәмәм бар, автономиям бар минем.

Куркъмадың, монда ничек кердең кыеп?
Бар икән йөргән кеше җаннан туеп!»

Язмыймын сугыш нә рәсмә булганын,
Кайсысы җиңгәнен йә җиңелгәнен.

Гөрзи төшкәч, кайсы билдән батканын,
Кайсысының маңгаеннан батканын.

Кариэм, иткел канәгать барына,
Итмәсәң – әйдә Печән базарына.

**VI**

Иртә берлән кайнамакта ул базар,

Анда да монда кызадыр сәүдәләр.

Кызса да гадәттәгечә сәүдәләр,
Әллә ник бүген күңелсездер базар.

Һәр мөселман әллә нигә кайгылы,
Нәрсәгә хәмлитмәгә бу кайгыны?

Юк, аларга кайгырырга юл да бар:
Нәкъ бер айдыр – юк Кисекбаштан хәбәр.

Җәмгулыб өч-дүрт кеше һәр чат саен,
Гәпләшеп кайгырталар Башның хәлен:

Ягъни ул мискингә ни булган икән?
Ике якның кайсысы җиңгән икән?

Әһле ислам шул рәвешчә яхзәнүн...
Күренә шул хәл еракtан, ах, вагон!

Нәрсә булган? Нинди хикмәт, кем белә? –
Ташбака төсле, вагон әкрен килә.

Өч сәгать үтте күренгәндин бире,
Юк әле асла якынлашкан җире.

«Ник болай бу?» – дип гаҗәпләнгән базар,
Әйләмәктә пассажирлар интизар.

**VII**

Тын гына торган вакытта шул рәвеш,
Килде ямьсез, куркынычлы бер тавыш.

Бик каты күк күкрәгән төсле була,
Җир ярылган, тетрәгән төсле була.

Бер – арысланнар акыргандай була,
Бер – көтү ишәк бакыргандай була.

Күз ачырмаслык чыгып комлы буран,
Басты золмәт җир йөзене шул заман.

Һәр тараф золмәт, күренмидер кояш,
Куркуга төште кешеләр – карт вә яшь.

Һич кеше белми: ни хикмәт бу, ни бу?
Әллә чынлап та кыямәт көнме бу?

Әллә бер «койрыклы йолдыз» төштеме?
Әллә Тәңре сур өрергә куштымы?

Дөньяга соңгы минутлар килдеме?
Әллә ханның мәсҗеде җимрелдеме?

Әллә тәүбә капкасы ябылдымы?
Әллә бер бай корсагы ярылдымы?

Ташпулатлар җөмлә дер-дер селкенә...
Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

Әрҗәдә читек-кәвешләр кузгала,

Һәм өеп куйган кәләпүшләр ава.

Танымый дуст дустны, кардәш кардәшен,
Һәр кеше куркып укый «ләхәүлә»сен.

Ни бәла килде Казанның халкына?
Очрадылармы Ходайның каһренә?

**VIII**

Бәс, шу рәсмә куркышып торган заман
Чыкты аңсыздан кояш, китте тузан.

Күрделәр: җитте килеп мәгълүм вагон,
Тагылып артында бер нәрсә тагын.

Ни күрәләр: өнме, ялган төшме бу? –
Тагылып килгән теге фәсле Дию.

И дулый! мәлгунь Дию, и тартыла!
Акыра ямьсез каты – җир селкенә.

Бите-башы канланып беткән янә;
Әйләнәсендә Кисекбаш әйләнә...

Сөйрәлеп җирдән Дию килгән икән,
Һәм вагон шуннан озак торган икән.

Бу Диюдән ул буран купкан икән,
Куркытучы шул Ходай суккан икән.

Инде һәркем күңленә шатлык тула,
Ул Кисекбаш елмаеп көлгән була.

Шул минут чыкты вагоннан пәһлеван,
Күтәреп башыны арыслан сыман.

Чөн Печән базары халкы күрделәр,
Барча күрешмәк өчен йөгерделәр.

Җөмлә бердән: «Әссәлам! дә әссәлам!»
Һәм Карәхмәт: «Вәгаләйкем әссәлам!»

Һәр мөселман дәрт белән күккә оча:
Бер Кисекбаш, бер Карәхмәтне коча.

Чыкты вагоннан тагын бер ир бала,
Бик чибәр – күргән кеше хәйран кала.

Чыкты тагын да чапанлы бер хатын,
Җәлбитәрлек тиречеләр дикъкатен.

Бер хаҗи шул хәл хатынга күз кыса,
Һәм дә яп-яхшук оятсыз сүз куша.

Ул Кисекбаш күрде дә бу тәкъваны:
«Тимә хатынга!» – диеп, бармак яный.

«Белмәдем мин!» – дип, хаҗи зари кыйла,
Күзләреннән яшьләрен җари кыйла.

Шул вакытта камчылы ишан килә;
Ул Кисекбашны тотубән өшкерә.

Күрделәр: Баш яшь егет булды янә,
Кул-аягы, гәүдәсе килде янә.

Бу кәрамәтне күзилә күрделәр,
Тәңрегә мең-мең шөкерләр кыйлдылар.

Ул Дию күздән югалды юк булып,
Очты Яңа бистә якка ут булып.

Сез беләмсез: ул Кисекбаш әл дә бар;
Көн күрә яхшы гына, ул – сәүдәгәр.

Дин юлында күп газап күргән өчен,
Армый-талмый дин өчен йөргән өчен,

Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать,
Чылбыры юк, белмимен, нидер сәбәп...

Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Ну Печән базары халкы күңле шат!

**«Кисекбаш»ка гыйлавә**

Рәт-рәт итеп гаскәрен куйгач тезеп,
Һәм дә җиткезгәч аякка торгызып,

Шунда сәргаскәр үзенчә бер горур
Берлә гаскәргә карап читтә торыр.

Бу «Кисекбаш»ны язып, мин дә шулай
Аз гына мәгърурланып тордым бугай.

Буш вакытта рәткә тезгән җырларым
Булса, сафланды, димен, гаскәрләрем.

Көлкеле чыкты: ярарлык ул ягы,
Әмма бик яхшы түгел гармун ягы.

Сарт китабыннан алынган үрнәге –
Нәзмы шуннан бик мөкәммәл булмады.

Монтазам булсынмыни соң гаскәрең,
Алгач үрнәккә Бохара гаскәрен!

## Ата илә бала

*(Кара такта янында)*

Яз, газиз угълым: кара тактаны сыз акбур белән!
Һәм кара күңлеңне ялт иттер сызып ак нур белән!

Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше;
Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше.

## Яхшы хәбәрләр

Язгы яңгыр тамчысы бер башка тамчыдан сорый
(Әллә белмичә сорый, әллә шаярыпмы юри):

«Ни сәбәп, уклар кеби, без, берьюлы күктән төшеп,
Бу тәрәзәгә килеп тә бәреләбез шып та шып?»

Бу сөаленә җавапта иптәше әйтә моңар:
«Бу начар өйнең эчендә икмәге юк ярлы бар.

Җиткерәбез без аңар бер бик матур шатлык хәбәр:
Алдагы көзгә арыш, һич шөбһәсез, булыр чибәр».

## Таз

*(Бер авыл малае авызыннан)*

Мәдрәсәдә бар иде бер таз малай, –
Бик шаян, шуклык белән мөмтаз малай.

Бик тирән – башындагы каткан бүрек,
Бер дә салмый, булмый һич башын күреп.

Кайсы чакта бүркен алып ташлыйлар:
«Әй, кояш чыкты! кояш чыкты!» – диләр.

Ул заман без барчамыз бик кечкенә,
Зурымызга яшь булыр унөч кенә.

Башчыбыз Таз, берзаман без уйнадык;
Һичберәү күрмәс әле дип уйладык.

Аһ, бәла! безне казый күргән, имеш,
Уйнаганны ул карап торган, имеш.

Кәйфемезне бик тиз үк кыскартты ул, –
Безне шул чактук хөкемгә тартты ул.

Куркышып казыйга тезләндек хәзер,
Төрле юл котлырга эзләндек хәзер.

«Казый абзый! безне син кызган», – димез;
«Һәр усаллык башы шул Таздан», – димез.

«И кизү! бар тиз китер, ул кайсы Таз?
Мин башын кашыймчы ул Тазның бераз».

Килде Таз. Без тик торабыз куркышып, –
Барчамыз бертөрле хәсрәткә төшеп.

Кушты казый: «Ят! сузыл! и Таз пәри!
Талчыбыктан сез котылмассыз әли!» –

Дип, казый безне дә куймый шелтәли;
Шул вакытта Тазга талны селтәде.

Бер-ике сукты казый, – бу нинди эш?
Бер дә чаж-чож итмидер суккан тавыш.

Нәрсәдер бар монда – бер алдау эше,
Иштеләдер каты нәрсә тавышы.

Нәрсә бар? Таз аркасында нәрсә бар?
Камзулын Тазның күтәреп баксалар:

Хәйлә иткән монда да ул Таз-явыз, –
Белмәгә мөмкин рәсемгә баксагыз.

Казый абзый куйды шаркылдап көлеп,
Гайрәте сүнде, кызык эшне күреп.

Безне гафитте, сугалмый калды ул,
Талчыбыкка яткыралмый калды шул!

## Су анасы

*(Бер авыл малае авызыннан)*

### I

Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде, шаять, бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, – юк янымда юлдашым.

Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.

Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берлән утыра тузгыган сачен тарап.

Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.

Сачләрен үргәч тарап, сикерде төште суга ул;
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.

Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага,
Җен оныткан, ахыры, – калган тарагы басмада.

Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,
Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.

Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

Берзаманны әйләнеп баккан идем артка таба, –
Аһ, харап эш! – Су анасы да минем арттан чаба.

Кычкырадыр: «Качма! качма! Тукта! тукта, и карак!
Ник аласың син аны, – ул бит минем алтын тарак!»

Мин качамын – ул куадыр, ул куадыр – мин качам;
Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк, ичмасам.

Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт,
Су анасыны куарга күтәрелде барча эт!

Вау! да вау! да, һау! да һау! –
бертуктамый этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә.

Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем;
И явыз карчык! тарагыңнан коры калдың, дидем.

Өйгә кайттым да: «Әни, алтын тарак таптым!» – дидем;
«Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым», – дидем.

Сөйләгәчтен кыйссаны, алды тарагымны әни;
Курка үзе алса да, – уйлый эченнән әллә ни...

**II**

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.

Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
Шык та шык! – кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.

Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да кузгалмыйм әле.
Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни:

– Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери!

– Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! бая көндез алып качты синең угълың, карак!

Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм;
Калтырыйм, куркам:
«Ходай! – дим,– инде мин кайда барыйм?»

Һич өзлексез шык та шык! безнең тәрәзәне кага;
Ул коточкыч сачләреннән чишмә төсле су ага.

Әнкәем алтын таракны, тиз генә эзләп табып,
Атты да тышка, тизүк куйды тәрәзәне ябып.

Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине!

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым.

## Алтын әтәч

**I**

Борын үткән заманнарда, Мәмәт атлы Һират ханы
Олугъ данлыклы хан булган; җиһан халкы аны таный
Икән, ягъни бу дөньяда беренче патша дип саный.
Мәмәт хан чит халыклардан ала булган олугъ дани.

Сугышса, дер дә дер тетрәткән ул бу фани дөньяны;
Чыгарткан чит халык аузыннан ул күп аһ вә фәганы.
Бара торгач, усал эштән тәмам туйган моның җаны;
Сакалга ак та кергәч, ташлаган артына дөньяны.

Сугышмый башлаган һич; күңле кайткан хәл дә азлыктан;

Ходаи бер кешедәй, тормаган бер дә намазлыктан.
Бер ай да үтмәгән, һәр якка ханның хәле фашланган –
Тирә-күрше халыкларга: «Һират ханы юашланган!»

Явызлар, серне белгәч, аңлагач ханга ни булганны,
Тотынганнар тынычсызларга һәр якъдин Мәмәт ханны.
Мәмәткә дәүләтенең чикләрен сакларга «чит»ләрдән,
Тыныч булмак өчен һәр дүрт тарафлардагы чикләрдән,

Тиеш булган хәзер сансыз-хисапсыз гаскәр асрарга.
Торалар каршы, дошманны куа – йокламый гаскәр дә.
Тырышалар, вәләкин барчасына өлгералмыйлар;
Тулы дүрт якта дошман – бер сәгать тә тик торалмыйлар.

Мәмәт хан гаскәре дошман көтеп торганда мәшрикътән,
Менә килеп чыгалар төн ягыннан яки мәгърибтән.
Мәмәт хан гаскәре көткәндә таудан йә тигез җирдән, –
Карыйлар: бихисап дошман килеп тә җитте диңгездән.

Бу хәлдән нинди рәхәт соң? – Хан аулакта елап куя,
Таҗын, тәхтен тәмам ташлап качарга да теләп куя.
Бөтенләй аптырап беткәч, чакырды хан багучыны,
Мөнәҗҗим, фалчыны һәм дә хәким исмен тагучыны.

Хәкимгә:
«И хәким! мин бик авыр хәлләргә калдым!» – ди;
«Йә, күрсәт хикмәтеңне, кыйлчы бер эш,
кыйлчы ярдәм», – ди.
Хәким, бер капчык аузына кулын сала да сызганып,
Куя хан алдына шуннан гаҗәп Алтын әтәч алып.

Һәм әйтә: «Падишаһым! Син котылдың инде – бик яхшы;
Гомергә дәүләтеңдә бу Әтәч булыр сиңа сакчы;
Бу кошны миннән ал, хан,– мәсҗедең башына кунаклат!
Югартын син аңар һәр дүрт тарафны да карат, саклат!»

**Мәснәви**

«Булмаса курку сиңа – бу тик торыр;
Килсә дошман гаскәре – бу кычкырыр.

Булмаса дошман – кыйлыр шунда карар;
Булса, борлыр – куркыныч якка карар.

Бер тарафка бакса, дисә: кикрикү! –
Бу борылган якка син гаскәрне ку!»

Хәкимгә патша ни рәхмәт укырга аптырый инде;
«Сиңа нәрсә бирим, әйтче? Ни сорсаң да бирермен», – ди.

Кызулык берлән патша әйтәдер: «Синең теләгеңне
Мин эшләрмен тәвәкъкыфсез – бөтенләй үз теләгемдәй».

**II**

Ханның мәсҗеде башына, бәс, Алтын әтәче кунды;
Карый һәр якны: алны-артны, өстне-астны, уң-сулны.
Кагынмый һәм чыгармый тын да – һәр якны тыныч күрсә;
Уянгандай йокыдан, кагынадыр – куркыныч күрсә.

Бәла күргәч тә сайрый, кычкырадыр: «Кикрикүккүк!» – ди;
Әгәр китсә бәла дәрхаль торадыр тик кенә – туктый.
Әтәчнең шөһрәте һәр якка китте, инде фашланды;
Сугыштан тартты кулны чит халыклар да – юашланды.

Хәзер дошман кешеләргә Мәмәт ханга һөҗүм кайда! –
Әтәч бикли аларның юлларын алдан да, арттан да.
Үтә бер ел тынычлык берлә, үтмәктә икенче ел;
Аманлык һәр тарафта – исмидер һич куркынычлы җил.

Менә көннәрдә бер көн хан тора куркып йокысыннан;
Килә тавыш колагына: «Харап эш! беттек, и солтан!»
«Ни булды? Нәрсә бар соң?» –
дип сорый гаскәр башыннан хан.
«Әтәч кычкырды тагын да – килә бугай явыз дошман!»

Һират халкы тәмам куркыштылар, башланды шау-шу да;
Хатыннар, яшь балалар, карт бабайлар төште каушауга.
Ышанмый хан; торып хан, мәсҗеденә ул үзе карый;
Күрә: Алтын әтәч борган башыны көнчыгыш сарый.

Йөгер тиз! Әйдә башла, и җәяүле гаскәр, атларга!
Ашык! и атлы гаскәр, син дә тиз бул! атлан атларга!
Шулай хан көнчыгышка бихисап гаскәр рәван кыйлды;
Олугъ угълын шуларга баш – беренче пәһлеван кыйлды.

Әтәч тә тынды, һәм әкрен генә тукталды шаулау да;
Тынычланган кеби булды йөрәкләнгән Мәмәт хан да.
Үтә бер көн, ике, өч, дүрт, үтә җиде, сигез көн дә;
Сугыш булганмы? юкмы? – килми гаскәрдән хәбәр бер дә.

Хәбәр юк ханга. Беркөне Әтәч тавышлана тагын;
Менә тиз-тиз икенче фирка гаскәр сафлана тагын.
Итә башлык бу гаскәргә Мәмәт хан кечкенә угълын:
«Бу гаскәр берлә абзаңны табып кайт, бар, җаным угълым!»

Үтә көннәр... Үтә әүвәлгесе төсле сигез көн дә;
Ике шаһзадәгә ни булганыннан чыкмыйдыр өн дә.
Һират халкы тагын шауларга башлады, тагын куркъты;
Әтәч тавышлана тагын да: «Кикрикүк!» тә «күк!», «күк!» ди.

Мәмәт инде өченче гаскәре берлә үзе китте
Туры мәшрикъ таба: «Тәңре, үзең ярдәм вә фазлит!» – ди.
Бара көн-төн, һаман ял итми, асла тынмыйдыр үзе;
Ни бар алда? Чыгармы бер-бер эш? – һич белмидер үзе.

Биш-алты көн бара; шаһзадәләр дә, гаскәре дә юк;
Түгелгән кан да юк һич; ичмасам, ат эзләре дә юк.
Менә сигезенче таң атканда, хан туктады бер тауга;
Җәелде гаскәр, атлар да – ничек бу җиргә туктауга.

Күренде хан күзенә тау башында бер кызыл чатыр –
Гаҗәп төсле матур, нинди күңелләрне дә кузгатыр.
Гаҗиб бик матур бер сахра; һава тын, җил дә юк бер дә;
Җиһан йоклый тавыш-тынсыз, бәрабәр – йоклыйдыр кыр да.

Бу нинди куркыныч! – Чатыр тирәсендә бөтен гаскәр
Үлеп ятыр булып тау-тау: кырылганнар, изелгәннәр.
Мәмәт хан ашыгып, тиз-тиз чатырның алдына бара;
Ни күзләр берлә күрсен! Аһлар ормыйча чыдап кара:

Үлеп ятмыш ике шаһзадә,– бакый йортка күчкәннәр;
Бере күкрәгенә берсе кылычларын чәнечкәннәр.
Күрә шаһзадәләр атландыгы юрга җирәннәрне –
Йөриләр чүпләнеп әкрен генә канлы чирәмнәрне.

Җылый хан кычкырып: «И җаннарым! и каһерманнарым,
Җаным өйгән ике шаһзадәм, и рухым, рәваннарым!»
Хан артыннан җыларга башладылар җөмлә гаскәр дә;
Җылый һәрнәрсә, һәркем – җанлы-җансыз барчасы бергә.

Исеркәп ушбу хәлне, кычкырып егълый хәҗәрләр дә;
Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә.
Шулай торганда, аңсыздан чатыр нурга тулып китте,–
Мәмәт хан каршысына бик матур бер кыз килеп чыкты.
Көлеп, як-якка айдай нур йөзеннән яктылык сачып,
Кочаклап алды ханны, – бер фәрештәдәй канат ачып.
Тора хан кыз күзе алдында куркынган поши төсле,
Кояш алдында тын алмыйча каткан төн кошы төсле.

Хан алдында фида булды хәзер һәркем дә, һәрни дә;
Гашыйклыктан онытты ул үлек шаһзадәләрне дә.
Матур кыз ханны кулыннан тотып кергезде чатырга;
Җәюледер мамык мендәр, түшәкләр анда ятырга.

Тулы һәртөрле нигъмәт; ялтырыйдыр алтын өстәлләр;
Чәчәк атып торалар – төрле-төрле гөлләр үскәннәр.
Кытай кясәләрендә ак, кызыл төсле шәраблар бар;
Терел, эч тә күңел ач – анда һәр абелхәятләр бар.

Матур кыз берлә вакты бик матур кичә хәзер ханның;
Матур кыз кичә-көндез дә кирәгенә хәзер ханның.
Сыйлый кыз һәм сөя, һәртөрле назлар күрсәтә ханга;
Сихерләнгән, тәмам гашыйк булып беткән Мәмәт хан да.

Бу кыз берлә көлеп-уйнап тәмам атна кадәр торгач,
Күңел ачкач, зәвекъләнгәч вә күп рәхәт-сафа сөргәч,
Мәмәт хан кайта инде яшь бикә берлә Һиратына,–
Ияртеп гаскәрен, саф-саф тезеп һәр дүрт җиһатына.

Хәбәр итте Һиратка – алдан ук күп илчеләр чапты,
Ки ягъни: «Хан сәфәрдән бик сәламәт, сау-исән кайтты!»
Халык каршыга килгән; барчасы бергә җыелганнар;
Хатын-кызлар, балалар – җөмлә хан кайтышка килгәннәр.

Халык ханны сәламли; ханбикә баш селкә фәйтуннан;
Яланаяк малайлар йөгерәләр фәйтун артыннан.
Шулай барганда, аңсыздан Мәмәт хан бер кеше күрә,–
Тәгаҗҗеб берлә фәйтуннан торып карый аягүрә.

Карап күрсә: йөзе нурлы бер аппак бүрекле карт –
Җитен төсле сакалы ак, кыяфәтчә күрекле карт.
«Моны соң кайда күрдем?» – уйлый торгач, ахры, белде:
«Исәнме, и хәким бабай, кулың бир, монда кил, кил»,– ди.

Хәким, ханга килеп: «Җә, хан, исәпне без өзик инде,
Беләмсең вәгъдәбезне? Син онытсаң, мин онытмыйм»,– ди.
«Олугъ хан, вәгъдә бирдең син: фәкыйранә теләгемне
Тәмам бирмәкче булдың бит – бөтенләй үз теләгеңдәй.

Шулаймы? Бәс, шулай булса, биреп җибәр миңа кызны,
Менә шул яшь бикәңне – ул йөзе ай, күзе йолдызны!»
Хәкимнең сүзләреннән хан ниһая дә гаҗәпләнде;
«Ни сөйли карт пәри, бу әллә шашканмы гакылдан?» – ди.

«Ни булды, карт, сиңа? Син әллә җенләндең, саташтыңмы?
Әтәч бирдем дигәч тә, әллә син хәддеңнән аштыңмы?
Дөрест, мин вәгъдә бирдем һәм бирәм;
әйтмим дә: «Кит, бар!» – дип,
Вәләкин син сора үлчәп, – минем вәгъдәмгә чик бар бит!

Кирәк булса, менә казнамнан ал пот-пот көмеш-алтын;
Сиңа булсын менә пар ат, көмеш көпчәкле бу фәйтун.
Күзең туйганчы һәртөрле читек-кәвеш, кызыл мал ал!
Кирәк булса – вәзир бул яки ярты ханлыгымны ал!»

«Миңа һичнәрсә бирмә, тик бу ай йөзле кызыңны бир!
Әгәр вәгъдәдә торсаң син, бу кыз – чулпан күзеңне бир!»
«Тфү! чорт, карт пәри!» – диде, бөтенләй кызды инде хан;
Мыек, сачене, сакалны да үрә торгызды инде хан.

«Җитәр, күп шаулама, карт!
Мин – Мәмәт ханмын! беләмсең син?
Сиңа кыз нәрсәгә, һәм нишлисең ул кыз белән соң син?
Алайса, мин сиңа, карт, инде һичбер нәрсә бирмим, – ди. –
Югал күздән, икенче рәт сине алдымда күрмим, – ди. –

Тере чакта котыл да бак юлыңны – әйдә кач моннан!
Сөйләшсәң күп, күрерсең күрмәгәнеңне палачымнан!»
Хәким картым тагын булган иде азрак талашмакчы
Мәмәт хан берлә: ник син бирмисең,
дип тарткалашмакчы, –
Утыртты картка хан бер зур тимер чукмар белән башка, –
Егылды карт: теге дөньяга китте бер дә кайтмаска.
Һират шәһре шул ук хәлдә давыллап, җилләнеп китте,
Кисәктән әллә нинди бер давыллы җил бәреп китте.

Менә шул хәлдә хан куркъты – төсе киткән, агарынган;
Көлә кыз «ха-ха-ха!» асла гөнаһтан куркъмаганыннан
Мәмәт ханның. Тәгаҗҗеб берлә хан тиз әйләнеп карый
Матур кызга, – эченнән куркъса да, ыспайланып карый.

Озакламый шәһәрнең капкасыннан керделәр инде,
(Котылдылар усал карттан, аны үлтерделәр инде.)
Менә Алтын әтәч аңсыздан урыннан очып төште
Дә дәрхаль кунды фәйтунга;
куа хан: «көш! тә көш! көш!» – ди.

Әтәч «прых! прых!» итеп ханның башы түбәсенә кунды,
Канатын каккалап ифрат ачы тавышлә кычкырды.
Әтәч ханның башын гайрәтләнеп-гайрәтләнеп чукый;
Карап-карап халыкка, хан башыны «тук! та тук!» тукый.

«Ни булган бу Әтәчкә!» – дип, халыкның котлары очты,
Кисәктән хан егылды – фәйтуныннан капланып төште.
Егылгач, бер генә рәт «аһ» диде дә үлде дәрхаль хан;
Халыкта тын да юк һич, тик тора бер җирдә – шаккаткан.

Ә кыз шул хәл гомердә булмаган төсле гаиб булды;
Карыйлар: бу Өтәч кайда? – Өтәч тә бергә юк булды.

Бу ялган инде, әлбәттә, шулай да языла шул бу;
Сабыйлар күңеленә аз-аз уку дәрте сала шул бу.

## Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә

Шадыман ул мәркадеңдә! – Без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадрең, инде котлыйбыз сине:

Яктылыкка иң элек атлау вә эз салу белән,
Гайбебезгә туп-туры дустанә күз салу белән.

Гәрчә «үлде» дисәләр дә, син бөтенләй үлмәдең;
Яхшы исмең калды, син мәнси вә мәтрүк улмадың.

Аһ! синең газмеңдә бәхтең каршы тормый бирсә юл,
«Яшь егет! күрсәт эшең, манигъ түгелмен», –
дирсә ул! –

Иртәрәк милләтне сәүкъ әйләр идең чын эзгә син!
Нинди гали, нинди зур эш эшләр идең безгә син!

Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,
Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар!

## Милләтчеләр

Татар халкы! син үләргә мәхкүм инде,
Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм инде;
Тиберченмә! терелмисең, юл өстендә
Ятма аунап, үзеңне үзең күм инде.
Милләтчеләр сине фәкать алдый гына,
Дигән булып: «Җанланасың син тиз менә».
Алданма син! калган акчаң өчен алар
Укыйлар ич баш очыңда ясин генә!
Лябед сиңа терлер өчен корбан кирәк,
Җитми мыр-мыр хәтем – чын, саф Коръән кирәк;
Көймә бата; йота торган балык өчен
Фида булган мөрәүвәтле бер җан кирәк.
Милләтче бик куркак бит ул, судан курка,
Гәрчә, милләт, диеп, авыз суын корта.
Кайсы чакта күперсә дә, тиз шиңә бит
Теге – ишегалдындагы ата күркә.
Алданмыйча, газиз башың кабергә керт,
Милләтчеләр барчасы да – эшсез шәкерт;
Алар өчен барыбер: син теләсәң, бет!
Алданма син: шәкерт алар, шәкерт! шәкерт!
Дөрест сүз бу, монда шик-шөбһә кемгә бар?
Тугъры сүзне нинди файда кәтемдә бар?
Күрерсең син шәкертләрнең сәдакатен:
Бер бай үләргә ятканда, хәтемгә бар.
«Милләт!» диләр, – ул чынмыни? ихласмыни?
Үз корсагын шәкерт алда тотмасмыни!
Әллә ничек рәхмәт берлә җанлансаң да,
Алар сине тагын сугып екъмасмыни?

Биһүдәдер! – сорыкорттан көтмәк гыйлаҗ,
Син бер гали, сатылмаслык иргә мохтаҗ;
Хак Тәңренең каршысында килешмидер
Тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаҗ!

### ...гә

*(Ядкяр)*

Шагыйрем! кодсиятең булсын синең күңлеңдә сер;
Дөньядан шагыйрь икәнеңне яшер, дустым, яшер.

Белмәсеннәр – кайсы җирдән агыла бу кодрәтең,
Син, ләтыйф тәннәр кеби, күрсәтмәгел чын сурәтең.

Һәрвакыт, һәр җирдә син башка киемнәргә төрен:
Йә җүләр бул, йә мәзахчы бер кеше төсле күрен.

Бирмә сер һичкемгә: сөйләшсәң сөйләш өстән генә;
Көл – караңгы йөз бирү анчак килешмәстән генә.

Читкә бор – сүз килсә каршыңда шигырьләр бабына;
Иптәшең шагыйрь генә бассын аяк михрабыңа.

Итмә үз тормышны; тап башка җиһан, башка хәят;
Дөньяның буш шау-шуы шагыйрьгә чит, шагыйрьгә ят.

Кем генә булсаң да, ул – юк ансына һичбер сүзем;
Тик сүзем шулдыр сиңа: саклан булудан үз-үзең!

Бел: килешмидер сиңа бу вак мәгыйшәт, вак тормыш;
Чөнки мәңгегә очалмас, йортта күп асралса кош.

Фәйзы бакый – таҗе шагыйрь мәңгегә булмас сиңа,
Ваксынып, син төшсәң алтын шылтыравы астына.

Баш имә – зур син – бу әдна җанлылар дөньясына;
Падишаһ син! бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа.

Таш йөрәкләр кырсалар күңлеңне – түз, эндәшмә син;
Эшләре шул: болгасыннар әйдә зәмзәм чишмәсен!

## Булмаса

Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?
Наз итәр кемнәргә гөл – каршыңда былбыл булмаса?

Сурәтеңнең иң чыны, бел: шагыйрең күңлендәдер;
Күзгеләрдән чын төсеңне күрмисең – ул булмаса.

Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;
Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса.

Һич килештермим синең төсле гүзәллек шаһына,
Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә килеп кол булмаса.

## 1909

## Күңел

Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!
Күп сөекледер бөтеннән – Тәңрегә сынган күңел.

Һәр минут миннән тели дөнья күңел җимешләрен,
Нәрсә пешсен, булса ялкынсыз күңел, сүнгән күңел?

Алга сәүкъ ит сахибеңне, бул чыдауда таш кеби,
И фәләкнең төрле-төрле золменә күнгән күңел!

Ялтыра, ялтыр – килешсен калебе саф шагыйрә,
И моңарчы төрле тап-тутларга өртелгән күңел!

Шундый гали матлабың – мең җан бирергә урны бар,
И югарылык белән типкән вә селкенгән күңел!

Игътиля итсәң, канатың, ач, – вакыт җитте бугай, –
И тумыштан гарше әгъляләргә җилкенгән күңел!

Син йоларсың һәр һәлакәттән – ышаныч бар сиңа,
Яр читендә торганымда ярдәмең булган күңел!

Яхшы аңла: юк сафа инсанлыгыңны җуймыйча,
И шуны җуймау юлында күп газапланган күңел!

## Васыятем

Кайт, и нәфсе мотмәиннәм! бар, юнәл, кит Тәңреңә;
Бирдең арканңы моңарчы, инде бир бит әмренә.

Дустларым, кардәшләрем, сез муллаларга әйтегез:
Бу ике юлны, мине күмгәч, укырлар кабремә.

Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:
Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә!

## Бәгъзе зыялыларымыз

Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар,
Сирәк ләкин, дөрест әйтсәм, кешелекле, хәялылар.

Әгәр күрсәң кызарган йөз аларда, бер дә алданма:
«Оялгандыр» димә яңлыш,
«җибәргәндер» дисәң – әүля!

## Тәрәддөд вә шөбһә

Бер шытырдауны ишетсәм, аузыма җаным килә;
Уйлыймын: «Шелтә кыйлырга әллә вөҗданым килә?»

Аптырыйм: юк изге эш ятканда да, торганда да;
Эш кушарга каршыма һәр дәмдә шәйтаным килә.

Нәрсә күрдем бу җиһанда? Ни бетердем? Уйласам:
Алдыма чын эз вә юлдан читкә тайганым килә.

Җырлыймын, ләкин җырымнан файда бармы халкыма?
Бер мәләктән яки шәйтаннанмы илһамым килә?

Раст, бу шагыйрьлек белән мин чынлап ук аурыйм бугай:
Бер-бер атлы рәтләнеп, мәйданга диваным килә.

Мин сизәм: дөнья йөзе дүзәх, җәһәннәмдер миңа;
Бер шигырь язсам гына, җәннәт вә ризваным килә.

Һәр каралткан кәгаземдә санки багъ, бостан була;
Һәр хәрефтән каршыма вилдан вә гыйльманым килә.

Шигъреми яздым: басылды; мин тагын зур кайгыда:
Фикремә юк-бар белән исмемне игъланым килә.

Һич риза булмыйм үземнән язганымнан соңра мин:
Һәр заман күз алдыма кимлек вә ноксаным килә.

Кайвакытлар һәр сәгадәттән өмидемне өзәм, –
Әллә кайдан шунда икъбал атлы чулпаным килә.

Ялтырый ул күкләремдә, күп өмидләр арттыра:
Күз яшем сөртергә гүя назлы җананым килә.

## Исемдә

*(Русчадан)*

Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар,
Гафифанә вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар;

Исемдә һәм эчемнән көткәнем якты бәхетләрне,
Теләп яшьрен генә – рәхәт, сәгадәтле вакытларны;

Исемдә, иң элекке саф мәхәббәт дәрте кузгалгач,
Илаһи бер тәләззездән беренче кәррә тамган яшь;

Яратканым, канымның көйгәне, хәсрәтлә янганым;
«Сөям!» – дип әйткәнем, шунда кызарганым, оялганым;

Заман кичте, сулар акты, хәзер юк инде ул ялкын;
Кызу сүнде йөрәктә, мәңгелеккә инде ул салкын;

Тыныч калды йөрәк, шау-шу вә гаугадан тәмам тынды;
Моңаеп тибрәнә тик бер тәхаттырдан гына инде.

## Күрсәтә

Ай, кеше! Тыштан үзеңдә изге хаслэт күрсәтә,
Яхшыга – рәгъбәт, яман эшләргә нәфрәт күрсәтә.

Тик Ходай хәзер урынны сайлый ул азмак өчен, –
Әһле дөньяга тышыннан истикамәт күрсәтә.

Әмре Хак корсак белән каршыга каршы килмәсә,
Ул хәзер дингә вә Коръәнгә итагать күрсәтә.

Булса килмәслек үзенә тугъры әйткәннән зарар, –
Ул да чынлыкны сөя, сүздә сәдакать күрсәтә.

Алганы булса берәүдән, ахирәт истән чыга;
Биргәне булса: янарсың, ди, кыямәт күрсәтә.

Бик горурлы ул, сиңа һич ихтыяҗы булмаса;
Бер эше төшсә әгәр, балдай фәсахәт күрсәтә.

Ут кабызмый ул, төтен эчкәндә, иптәштән элек;
Әүвәле аңгар суза – икрам вә хөрмәт күрсәтә.

Дусты өстеннән эчүдә булса сакый ул әгәр,
Тип-тигез салган була, – гүя гадәләт күрсәтә.

Мин арыслан! ди, синең малны тәләф иткәндә, ул,
Син аңар калсаң: фәкыйрьмен, ди, җәбанәт күрсәтә.

Чәнчә дә ул күңлеңә явыз лисане хәнҗәрен:
Нигә кәйфең китте, дустым? ди, мәхәббәт күрсәтә.

Тыңласаң тыштан, синең гайбәт аның аузындадыр;
Син килеп керсәң, ачык, мәгъсум кыяфәт күрсәтә.

## Ике юл

Ике юл бар бу дөньяда: бере будыр – бәхет эстәү;
Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак –
мәгърифәт эстәү.

Синең кулда: теләрсәң – мәгърифәтле бул, бәхетсез бул;
Вә яки бик бәхетле бул, ишәк бул, мәгърифәтсез бул.

## Гаилә тынычлыгы

Әгәр булсын дисәң бер өй эче шау-шу вә җәнҗалсыз:
Ире булса сукыр, ул җитми, – булсын һәм хатын телсез.

## Ике кояш

Күр: ничек иртә кояш чыкса, җиһанда нур тула, –
Һәр күңелләр нурланадыр, чыкса Гыйззәтуллина.

Бу икәүгә Тәңре биргән бертигез зур мәртәбә:
Берсе уйный күк йөзендә, берсе уйный сәхнәдә.

## Эштән чыгарылган татар кызына

*(«Зиләйлүк» көенә)*

Сөялгәнсең чатта баганага,
Яфрак төсле сары йөзләрең;
Кызганмыйча күңлем чыдый алмый:
Бигрәк моңлы карый күзләрең.

Атылган кош, адаштырган эттәй,
Үткәннәргә мәэюс карыйсың;
Күрәм, ике ирнең селкенәдер:
Кайсы татар баен каргыйсың?

Аз шул бездә байлар, кайсысы кем
Фәрештәдән канат каермас;
Алсын гына шәйтан иманыңны,
Җәһәннәмлек бу дип кайгырмас!

Күрдем әле синең залимеңне:
Һаман кәеф сөрә, типтерә;
Рәхәтләнә, кяфер! Сине шулай
Баганага сөяп киптерә.

Сизмисең бит син дә синең яннан
Нечкә күңел шагыйрь узганын,
Синең болай мискинләнгән хәлең
Аның күңлен ничек өзгәнен!

## Гашыйк

Син күрерсең бу кешене: күп вакыт уйный, көлә, –
Ул шулайтеп халәте рухын яшермәкче була.

Белмичә, «уйный» диләр, эчтән ниләр уйлаганын,
Сизмиләр – чыкмый төтен тышка –
мәхәббәт янганын!

Ул шаярганда, кисәктән керсә җанаш каршына,
Гашыйкым җитдиләнә, шундук уеннан тартына;

Кып-кызыл төскә керә ул, үзгәрәдер йөзләре,
Әллә нинди көчтән астка салынадыр күзләре.

Ул түнә, хәлсезләнә шул, очраса үз хурына,
Хәзрәти Муса тәхәммелсез тәҗәлли нурына.

Нишләсен, җанаш хозурында аңар лазем намаз;
Бер азан әйткәч, колак каккач, мөселман уйнамас.

## Вакъты гаҗезем

*(Көнлек дәфтәреннән)*

Тапдисәм мәузугъ, язарга аптырыйм:
Кай төшеннән мин моны, дим, ләктерим?

Ул йозак төсле миңа, юк ачкычым,
Йә бөек сәд – юк менәргә баскычым.

Йә кимә ул – юк янымда ишкәгем,
Шул рәвеш эчтә кала күп хисләрем.

Яки уйга калдырадыр интикад,
Итмәсәм дә мин аңар күп илтифат.

Уйлыйсың син бер фикерне: раст кеби,
Шик төшә: юк, ул да раст булмас кеби.

Юк әле миндә хакыйкатькә вөсул,
Әллә нигә айрылалмый уң вә сул.

Йа Ходай! кайчан чыгармын шөбһәдән?
Кипми ник шөбһә тире бу җибһәдән?

Йа Ходай! кайчан бу золмәтләр бетеп,
Юл салырмын күкрәгем берлән этеп?

## Китап

*(Аз гынасы русчадан)*

Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;

Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь, –

Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам;

Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем
Була минем юл күрсәткүче йолдызым;
Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,
Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем;

Җиңелләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,
Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;
Ышанычым арта минем үз-үземә,
Өмид берлән карый башлыйм булачакка.

## Сөбханалла, сөбханалла

Сабый чакта укытканда мине хәлфә,
Рәхмәт аңар, өйрәтте бер яхшы нәрсә:
– «Сөбханалла» диеп әйтү тиеш, – диде, –
Бер мән яңа гына туган айны күрсә.

Шул заманнан бирле айның туганына
Һәм дә алтын көпчәк төсле тулганына
Карап, күңлем кайчан минем хәйран кала,
Диям шунда: сөбханалла, сөбханалла!

Бу әйтүем, хәер, минем гадәт кенә,
Бу бертөрле дини булган әдәп кенә;
Бер вактым бар – чын күңлемнән укыйм моны,
Хәлфәм! яусын сиңа һаман рәхмәт кенә.

Менә нәрсә: күрәм бәгъзан сөйгәнемне,
Көннәр, төннәр гыйшкы берлән көйгәнемне;
Хәлфә, шунда минем телем тотлыгадыр,
Эшкә кушам тагын шул ук белгәнемне.

Тулган айга охшаш йөзе, башы аның,
Яңа туган айга охшаш кашы аның;
Күңлем аңар карап торып хәйран кала,
Укыйм чынлап: сөбханалла, сөбханалла!

Әгәр күрсә шул матурны Гайнетдиннәр,
Гади генә Котбетдиннәр, Шәмсетдиннәр,
«Сөбханалла» дию кайда аларга соң! –
Укымаган алар, бернәрсә белмиләр.

Әгәр, хәлфә, мин дә шулай надан булсам,
Синнән гыйлем алалмыйча калган булсам,
Әйтер идем, шулар кеби, мин гыйрфансыз:
Әй-яй, бигрәк матур икән, чукынган кыз!

## Эш

Тынма, эшлә, и сабый! Бел, Тәңредән эшләргә – көн,
Эшләп аргачтан, бирелгәндер тыныч йокларга төн.

Иртә торгач та язарга, дәрсең укырга тотын;
Тынма, эшлә, торма тик, тынсаң тынарсың җомга көн.

Күр, ничек эшли кояш: иртә тора, таң аттыра,
Көнозын күктә йөзә һәм көн буенча яктыра.

Соңра, арган төсле, ул ирнеп кенә тауга бата,
Йоклый рәхәт, ял итә һәм җир йөзен дә йоклата.

Син кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһад итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың берзаман!

## Могъҗиза

Пәйгамбәрнең вафатыннан соң, асла могъҗиза булмас,
Ярылмас ай икегә, һәм кара таштан төя тугъмас,

Диләр безнең гыйлем әһле.– Ышанмаңыз, бу ялгандыр;
Үзем күрдем бүген, безнең заманда могъҗиза бардыр:

Бүген иртүк миңа шактый бурычлы иптәшем килде,
Ялындырмый, талашмый, вәгъдәсендә акчасын бирде.

## Чыршы

Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары;
Юк яшеллекләр хәзер, урман вә сахра сап-сары.

Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен;
Хәстә төсле, арта сары төс аларда көн саен.

Үз төсен үзгәртми саклаучы арада берсе бар:
Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.

## Туган авыл

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Ходай шунда җан биргән, мин шунда туган,
Шунда әүвәл Коръән аятен укыган;
Шунда белдем рәсүлемез Мөхәммәтне,
Ничек михнәт, җәфа күргән, ничек торган.

Истән чыкмый монда минем күргәннәрем,
Шатлык белән уйнап гомер сөргәннәрем;
Абый белән бергәләшеп кара җирне
Сука белән ертып-ертып йөргәннәрем.

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,
Билгесездер – кая ташлар бу тәкъдирем;
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

## Яңгыр илә Кояш

Кояш әйтте: «Һаман мин яктырырмын
Вә бер дә батмамын, янып торырмын».
Диде Яңгыр да: «Һәр көнне явармын,
Кара җирне юешләр, елгалармын».
Кояш каршы диде: «Син бик юешле,
Явасың былчыратып һәммә төшне.
Суыңнан анда баткак, монда баткак, –
Синең бар белгәнең җир былчыратмак.
Юешлектән иген, ашлык черидер,
Мужиклар яумасайде дип телидер».
Диде Яңгыр җавапта: «Син кызасың,
Игенне яндырасың һәм кырасың».
Ачуланды Кояш бу сүзгә, кызды,
Ачудан эсселектә хәдтән узды.
Диде: «Мин бит җимешләрне пешергән,
Нурымнан җанлы-җансыз файда күргән».
Диде Яңгыр: «Аларны син пешерсәң,
Ә мин бит үстерәм һәм су эчертәм.
Әгәр мин яумасам, багълар шиңәрләр,
Болынлыклар, яшеллекләр кибәрләр».
Кояш Яңгыр белән күп кычкырышкач,
Бере-берсен яманларга тырышкач, –
Татулашты, килештеләр ахырда –
Бу көннән сүз көрәштермәскә бер дә.
Шулай бетте боларда сүз вә тартыш,
Күрергә булдылар нәүбәт белән эш.
Кояш әйтте: «Кызам үз нәүбәтемдә,
Ә син яу рәхмәтеңлә нәүбәтеңдә».
Кояш, Яңгыр әле бу көнгә чаклы
Бозып эш кыйлмыйлар бу иттифакъны.

## Милли моңнар

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый,
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңлениләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр берлән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, диде, «Әллүки»!»

## Яратырга ярый

Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар,
Киемсез калтырап торган мәсакине, фәкыйре бар.

Яратырга ярый җәйне: матур ул, анда зур ямь бар,
Вәләкин таш бинасы юк фәкыйрьләргә җәһәннәм бар.

Яратырга ярый дөнья: матур кырлар, матур таулар;
Яратмыйм мин вәләкин һич, сәбәп шул: ибне адәм бар!

## Киңәш

*(Позняковтан үзгәртелгән)*

Чикмә гамь шул нәрсәгә: синнән гомернең еллары
Алган аны бер дә бирмәскә – очырган җилләре.

Тормышыңның агымында инде ул киткән агып;
Кайгырудан файда юктыр – булмый инде кайтарып.

Түкмә күз яшь: ярдәмеңдә һәр заманда Алла бар;
Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!

## Япон хикәясе

*(Буренинннән)*

Электә бер Ташчы торган бу дөньяда,
Безнең җирдә түгел – ерак Япунъядә.

Үзе булган таза гына бер яшь кеше;
Ялыкмыйча эшли икән ул таш эше.

Ризыкланган ачы тирләр һәм көч белән,
Көн буена ташлар ватып чүкеч белән.

Булганлыктан һаман да эш, һаман да эш,
Күрәлмаган бу яшь егет рәхәт тормыш.

Беркөн шулай эшләп-эшләп каты аргач,
Күңле кайткан эштән тәмам хәлдән тайгач,

Тотынган ул үз-үзенә тарланырга,
Мондый начар көн күрмештән зарланырга:

«Ходаем, ник фәкыйрь иттең мине болай?
Рәхмәтең киң, мин бәндәңне кыйлсаң да бай;

Бүтәннәрдәй мин дә рәхәт сөрер идем,
Тынычлык һәм бәхет йөзен күрер идем».

Шуннан гына очып үткән бер Фәрештә
Әллә ничек моның моңын, зарын ишттә.

Һәм әйтә ул: «Ярар, яхшы, шулай бул», – ди,
Ягъни: «Үзең теләгәнеңчә бай бул», – ди.

Безнең Ташчы шул минуттук зур бай булды,
Азапланган читен тормыш уңай булды.

Инде хәзер авыр эшләр муенда юк,
Рәхәт ята, һичбер нәрсә уенда юк.
Шул вакытта Ташчы күрә: зур урамнан
Үтеп бара гаскәр берлән олугъ бер Хан.

Киемнәре, баш өстендә чатырлары
Ялт-йолт килә көнгә каршы – алтын бары.

Ташчы әйтә: «Зур эшмени бу – бай булу?
Насыйп булса менә шушындый Хан булу, –

Булыр иде шул вакытта бәхтем минем:
Аһ, булсачы вәзирләрем, тәхтем минем!»

Тагы шуннан очып барган шул Фәрештә
Бу Ташчының сөйләгәне сүзен ишттә:

«Теләгәнең булсын синең – син Хан бул», – ди,
Үзе китә очып: «Хәзергә сау бул!» – ди.

Ташчы карый: шулук хәлдә ул Хан булган,
Һәр ягына вәзирләр һәм гаскәр тулган.

Уенчылар матур көйләр көйләгәли,
Баш өстендә алтын зонтик күләгәли.

Шулай да бик рәхәт түгел: Кояш эссе,
Гаҗиз калды Хан эсседән, тәмам пеште.

«Кирәк түгел, – ди, – Хан булу һәм баш булу,
Насыйп булса икән миңа Кояш булу!»

Шул Фәрештә тагын шунда җитеп килеп,
Китте очып: «Ярар, булсын синеңчә», – дип.

Шул минутта Ташчы егет Кояш булып
Күктә тора, бу дөньяга нурлар коеп.

Бераздан соң әллә кайдан чыга Болыт,
Җир һәм Кояш арасына пәрдә булып;

Каплап тора әллә нинди гайрәт берлә,
Күренмидер Кояшка җир, Кояш – җиргә.

Егет әйтә: «Кирәк түгел Кояш булу,
Болыттан да кимсеттереп, юаш булу.

Тәңрем, ирек бир син миңа, Болыт булыйм,
Болыт булып, җиһанга баш булып торыйм».

Фәрештә дә шул вакытта җитеп килеп,
Китә күккә: «Ярар, булсын синеңчә», – дип.

Шул ук вакыт Ташчы егет Болыт була,
Җир йөзенә яңгырларын коеп тора.

Чиләк-чиләк булып яңгыр яуганыннан,
Сулар артып, ташып чыкты ярларыннан.

Сахра, болын, игенлекләрне су басты,
Һәрнәрсәгә урын булды дулкын асты.

Бу дулкыннар кубарса да шау-шу, гауга,
Һөҗүм итеп килсәләр дә, охшап яуга, –

Шунда үсеп тора торган олугъ Таш-тау
Зәррә хәтле зарарланмыйча калды сау.

Егет әйтә: «Кирәк түгел Болыт булу,
Артык миңа Болыт булганчы юк булу!

Гайрәтемнән күрсәтмичә һичбер какшау,
Минем көчтән көлеп тора шушы Таш-тау!»

Шунда тагын Фәрештәсе килеп җитә:
«Ярар, яхшы, шулай бул син», – диеп китә.

Ташчы егет шул ук минут була Таш-тау;
Гомерлеккә торырмын, ди, мин шунда сау.

Һәр яклардан килсәләр дә сулар ташып,
Дулкыннары бәрелсәләр дә шып та шып! –

Кибаранә күтәреп баш, безнең Таш-тау
Селкенми дә, кузгалмый да тора сап-сау.

Шул вакытта әллә кайдан чыга Инсан,
Кулларына балта берлән чүкеч тоткан.

Килә дә ул, бу Таш-тауны вата башлый,
Таш артыннан ташны ватып ата башлый.

Егет әйтә: «Мин күп нәрсә булып үттем,
Һәрберсеннән галилек һәм бәхет көттем;

Күрдем хәзер: эшкә һичнәрсә тиң түгел,
Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел.

Кирәк түгел, мин яңадан Ташчы булам,
Әүвәлгечә иҗтиһадлы эшче булам!»

Кодрәт берлә шунда егет Ташчы була,
Әүвәлгечә иҗтиһадлы эшче була.

## Күңел йолдызы

Тәнәфферләр, тәхаттырлар,
 тәрәххемләрлә дөньядан
Гөзарым, захмедар васле бер һиҗрә
 мөкәүкәбдер.
 *Габдулла Җәүдәт*

Ничаклы изсә дөнья, ирке бар – куркытмыйдыр безне;
Елар җирдә көләм мин, һич чытып тормыйм аңар йөзне.

Минем гомрем караңгы төн. Кояшым һәм аем тугъмас;
Шуңар да шөкер итәм мин: бу төнем йолдызлы, йолдызлы.

Озаттылар миңа кул төрле мәлгунь көч, кара көчләр,
Теләп сүндермәгә күңлемдә янган изге йолдызны.

Вәләкин сүнмәде ул: йолдызым якты, һаман нурлы;
Гаҗәпме, юлга салса, ичмасам, бер данә юлсызны?

Күзеннән канлы яшь түксен иде барча шәятыйным,
Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Раб, гүзәл эзне!

Минем күңлем мөкәүкәбтер өмид, хәсрәт, тәәссерлә;
Зарар юк, барча кодсиятебез дә айлы, йолдызлы!

## Сәрләүхәсез

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Караңгыдыр, күңелсездер гомер юлы.
Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,
Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә
Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тулы.

Мискин адәм! Тыштан уйный, тыштан көлә,
Ямьсез якны уйлап куя эчтән генә.
Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,
Һич кайгысыз кеше булса – адәм түгел!

Бераз вакыт шатлык таба исрек кенә,
Үз-үзенә ачы агу эчреп кенә:
«Әмма дөнья нинди кызык, нинди хозур,
Бу дөньяда кемнәр бар, дип, миннән дә зур!»

## Теләү бетте

*(Пушкиннән мокътәбәс)*

Теләү бетте хәзер миндә теләк соңра теләкләрне;
Кире сүттем хәзер күп эшкә сызганган беләкләрне.

Күралмыйм мин азатлык бер дә чиксез ихтыярымнан;
Гаҗәп ләззәтле, тәмле булса да, туйдым хыялымнан.

Фәкыйрь калдым хәзер: тормыш үзенең биргәнен алды;
Күңел буш: анда калды тик авыр хәсрәт, ачы кайгы.

Бетердем шиңдереп төрле гүзәл чәчкәмне барсын да
Явыз тәкъдир, каты тәкъдир, суык тәкъдирем астында.

Өмидсезмен: фәкать актык дәкыйкамне көтәм инде,
Көтәм: кайчан тавыш-тынсыз гына беркөн бетәм инде?

Мисал бу: көз көненең кышка каршы, соңгы чагында,
Туңып беткән агачның яп-ялангач бер ботагында

Төшәр-төшмәс торадыр соңга калган бер генә яфрак, –
«Төшәм» дип калтырый,
   җил сызгырып киткән саен чак-чак.

## Ана догасы

Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,
Көмешләнгән бөтен өйләр вә сахралар тора балкып.

Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган
Халык йоклый – каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.

Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;
Авыл кыръенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.

Әнә шулай өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

## Таян Аллага

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;
Ул – рәхимле: әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең –
барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

## Бабай

Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе,
Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе.
Яңак, маңлай җыйрылмаган, тешләр дә сау,
Яшьләрчә саф, ачык чыга аның сүзе.

Җитеп килә инде аның җитмеш яше,
Җем-җем итә җитен сакал, көмеш чәче.
Бабай, мискин, бу дөньяда күпне күргән,
Үлеп беткән инде аның күп яшьтәше.

## Кышка бер сүз

Кит әле син, аксакал кыш! Күр, әнә таудан туры
Тәгәридер ул матур кыз – язның алтын фәйтуны.

Тиз югал, и кыш бабай, син ал да тиз кач карт башың,
Барыбер, күрсәң, качарсың, язны – гөлләр патшасын!

Бер дә юк ул патшаның мылтык-кылыч, алмаслары,
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре.

## Уянмас йокы

Фатыйма күрде үзенең бүлмәсендә бер рәсем:
– Әнкәем, бу кем? – диеп сорды, кочаклап әнкәсен.

Әнкәсе бирде җавап: – Әүвәлге угълым бу минем,
Дөньяда юк ул хәзердә, бертуган абзаң синең.

– Әнкәй, әнкәй! Нишләгән ул, кайда соң ул? Әйтсәнә!
Мин аны күрмәк телимен, зинһар, әнкәй, тапсана!

– Юк, җаным, юк, күз нурым, абзаң хәзердә йоклаган;
Ул каты йоклый, вөҗүден кара туфрак каплаган.

– Ә, алайса, син агамны, бар, уят, торсын, әни;
Бергә уйнарбыз, үзенең сеңлесен күрсен, әни!

– Юк, җаным, син белмисең, юктыр уятырга мәҗал,
Ул уянмас бер йокыдыр, аһ, аның исеме – әҗәл!

## Ай һәм Кояш

Һималая тау өстендә алтын бишек,
Кояш йоклый һәр кич саен шунда төшеп;
Җил төн буе йоклаганын саклап тора,
Тирбәтә һәм өстен-башын каплап тора.

Йокысыннан Кояш ничек уяндисә,
Җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә;
Исә-исә бөтен дөнья буе китә:
– Торыгыз! – ди, – уяныргa вакыт җитә!

Торып чыккач шул бишектән Кояш агай,
Анда кереп йоклый инде энесе Ай;
Йоклый шунда йолдызлар да өелешеп,
Оядагы йоклап яткан кошчыклардай.

Каты йоклап Ай бишектә мәгърибкәчә,
Торып чыга, көлеп җиргә нурын чәчә;
Кояш һәм Ай – ике туган агай-эне –
Менә шулай дустлык берлән нәүбәтләшә.

## Җир йокысы

Кырга ак кардан
Юрган ябылган;
Җир язга чаклы
Уйкуга талган.

Ул тормас, йоклар,
Кышлар үтмичә, –
Кыйбладан кошлар
Кайтып җитмичә.

Язның айлары,
Апрель, майлары,

Бик матур сызлып
Аткан таңнары;

Урман шаулавы,
Кошлар сайравы,
Күкләр күкрәве,
Яңгыр аннары.

Коену көн саен
Кояш нурында;
Аннан соң тагын
Төшкән чык төндә.

Бу хәлләр җиргә
Барчасы бергә
Калган тик инде
Төштә күрергә.

Җир йоклый тыныч,
Күреп тәмле төш.
Уяныр әле,
Тукта, үтсен кыш!

## Кошларга

Куркъмагыз, кошлар, күреп сез яныгызда мин барын;
Мин тимәм сезгә, фәкать сайравыгызны тыңларым.

Җырлагыз сез күңлегезгә Тәңре нәрсә салганын;
Мылтыгым да юк янымда, юк шулай ук ауларым.

Бик тынычлап сайрагыз сез, мин тимим, сезгә тимим;
Әллә иркендә торуның кадрене белмимме мин?!

Куркымагыз – яхшы беләм, мин һич тә сезне ауламам;
Сайрагыз, тыңлап торырмын, тын да алмам, шауламам.

## Сабыйга

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз – аларның булганы юктыр гомер.

Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле – шагыйранә ялган ул.

Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк.

Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

## Карлыгач

Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын

Оя итте минем сөйгән Карлыгачым.

Ул көн буе аузы берлән балчык ташый,
Балчык берлән матур итеп оя ясый.

Күп эшләде иренмичә; бара-бара
Чыгарды ул матур-матур балалар да.

Ачыксалар Карлыгачның балалары,
Чебен-черки тотып кайта аналары.

Карлыгачым ямьсез озын кара төндә
Каты йоклый оясында, алмый тын да.

Бер канатының астына тыга башын,
Уянмый ул, – бөтен кеше тавышлансын.

Күк күкрәсен, ялтыр-йолтыр килсен яшен,
Төн буена нинди каты җил исмәсен, –

Ни булса да, бары да бер аның өчен, –
Уянмый ул, селкетми дә борын очын.

## Кышкы кич

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, тезелешеп, –
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми һич тә.

Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең озынлыгын сизмисез дә
Әнкәгезнең сөйләгәне әкият берлә.

Тышта иссен ачы җилләр, тузсын карлар,
Өй түбәсе саламнары килсен тар-мар,
Суыклыктан очар кошлар очалмасын, –
Сезнең урын җылы, әйбәт, – ни кайгы бар?

Төшсен ләкин исегезгә кайсы вакыт:
Һәркемгә дә бирелмәгән мондый бәхет;
Ятим калган сабыйлар бар, бәхетсезләр,
Ата-анасы вафат, җирсез һәм йортсызлар.

Мондый кышкы кичтә сыгъныр урыннары
Аларның юк, өши бите, борыннары;
Үлми калса яхшы алар салкынлыктан,
Кайберсенең шуннан була үлемнәре.

Очрый калса сезгә шушындый ярлылар,
Яшьле күзле, моңланганнар вә зарлылар, –
Яшь балалар! аларны сез яратыгыз,
Җылы сүзләр әйтеп, сөеп юатыгыз!

## Кошчык

Кичә мин читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым,
Күңелсез тоткынымны киң яшел урманга кайтардым.

Аңар бирдем азатлык мин, үземдә шул вакыт күрдем:
Тынычлап калды никтер һәм тәмам иркенләде күңлем.

Күзем берлән озаттым: кошчыгым урман таба очты,
Югалды күк йөзендә тиз вакытта, бер дә юк төсле.

Очып киткәндә ул шундый матурлап сайрады моңлы:
Миңа санки азат иткән өчен изге дога кылды.

## Бәхетле бала

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олугъ күрсә, белергә кушканын белсә.

Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас – менә бәхте аның шунда.

Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә!

## Бишек җыруы

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

## Бала белән Күбәләк

Бала:

Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек?

Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын
Якты көн булганда.

Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;
Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә, –
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

## Мәктәптә

Менә көз барча кырларны вә урманны ялангачлый,
Менә ак тун киеп инде күңелсез кыш килә башлый.

Игеннәр тулган ындырга, халыкның эшләре беткән,
Вә көньякның вакытча безгә килгән кошлары киткән.

Урамнарда күңелсезлек, авылда сизлә бер кайгы,
Тереклекләр вә шау-шулар, кызыклар кайда ул җәйге!

Күңелсез һәм дә ямьсез булса да шулчак табигатьтә,
Кызык ләкин, күңелле бик авыл кырыенда мәктәптә!

Укулар кычкырып анда! Бөтен мәктәп килә шау-шу!
Кызык җәй айрылып торган укуга көз көне каушу!

## Эш беткәч, уйнарга ярый

Бик матур бер җәйге көн: өстәл янында бер Сабый
Ян тәрәзә каршысында иртәге дәрсен карый.

Чын күңел берлән укый ул, кат-кат әйтеп һәр сүзен;
Бик озак шунда утырды, бер дә алмастан күзен.

Шул чагында бу Сабыйны чакыра тышка Кояш:
«И Сабый, – ди, – әйдә тышка, ташла дәрсең, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман;
Чыкчы тышка, нинди якты, нинди шәп уйнар заман!»

Бу Кояшның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Тукта, сабрит, уйнамыйм, – ди, – уйнасам, дәрсем кала.

Көн озын ич, ул уенның мин һаман вактын табам,
Чыкмамын тышка уенга, булмыйча дәрсем тәмам».

Ул, шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап ябышты дәрсенә.

Өй түрендә шул заман сайрый ботакта Сандугач,
Ул да шул бер сүзне сайрый: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман,
Чыкчы тышка, нинди һәйбәт, нинди шәп уйнар заман!»

Сандугачка каршыга биргән җавабында Бала:
«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәрсем кала.

Туктале, бетсен дәрес, – ди, – әйтмәсәң дә уйнарым,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың тыңларым!»

Ул, шулай дип, һич зарар бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап кереште дәрсенә.

Шул вакытта өй түрендә бакчада бер Алмагач
Чакыра тышка Сабыйны: «Әйдә тышка, күңлең ач!

Бик күңелсездер сиңа эштә утырмак һәрвакыт,
Әйдә, чык син бакчага, җитте хәзер уйнар вакыт!»

Алмагачның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Юк, сөекле Алмагачым, уйнасам, дәрсем кала.

Тукта, сабрит аз гына, – ди, – и кадерле Алмагач,
Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач».

Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәрсене,
Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны – барсыны.

Чыкты йөгреп бакчага: «Йә, кем чакырды, – дип, – мине?
Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер мин дәрсеми!»

Шунда аңгар бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңгар кып-кызыл зур алма бирде Алмагач;

Шунда аңгар шатланып сайрап җибәрде Сандугач,
Шунда аңгар баш иделәр бакчада һәрбер агач.

## Арба, Чана, Ат

Берзаман бер төшкә килгән Ат белән Арба, Чана;
Бу өчәү һәрберсе дә үз тормышыннан зарлана.

Арба әйтә: «Җәй көне мин һич тә рәхәт күрмимен:
Көн-төн эштә йөрим, һичбер җигелми тормыймын».

«Әмма соң бу кыш көне бигрәк уңайсыз!» – ди Чана,
Ат та, сүзгә кушылып, үз нәүбәтендә зарлана:

«Юк ла, и Арба, Чана! – ди, – сезгә тормыш бик уңай,
Эшләсәгез алты ай сез, ял итәсез алты ай.

Күпме зарлансам урын бар, мин каты мәзлум менә:
Хәл җыймыйм ел тәүлегендә, ичмасам, бер көн генә!»

## Кярханәдә

Көндез эш, кичен эш,
Бер минут юк тыныч,
Аждаһа-машина! –
Карарга куркыныч.

Җәһәннәмдәй эссе,
Кайнаган җиз, бакыр.
Эшлидер, тик эшли
Эшче мискин, факыр.

Аргайгандыр үзе,
Саргайгандыр йөзе;
Бөкрәйгәндер биле,
Нурсызланган күзе.

Ул төтен, ул төтен! –
Алып та булмый тын!
Көпчәкләр дөберди,
Чыгарырлык котың.

Качасиде моннан,
Бу ямьсез тәмугтан!
Әллә кай җирләргә,
Ямь-яшел кырларга;

Шул җирләргә: кайда
Сайрый кошлар, анда
Арыш, богъдай үсә,
Җир җиләкләр пешә.

## Кәҗә белән Сарык хикәясе

Борын заман бер Ир белән Хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер Кәҗә берлә бер Сарык, –
Болар булган берсеннән дә берсе арык.

Әйтә беркөн Ире: «Кара монда, Хатын! –
Үзең яхшы беләсең бит печән хакын, –
Китсен бездән чыгып Кәҗә белән Сарык,
Ашап ята бушка гына алар азык».

Хатын күнде, диде: «Ирем, ярар, ярар,
Бу икене кумаклыкка булсын карар;
Кәҗә белән Сарык хәзер китсен бездән,
Аларны соң асрап торып ни файда бар?»

Нишли инде мискин Кәҗә белән Сарык?
Булмый хуҗа кушканына каршы барып.
Икесенә бер зур гына капчык тегеп,
Китте болар кырга таба сәфәр чыгып.

Китте болар. Бара, һаман бара, бара, –
Күренмидер күзләренә ак һәм кара.
Бара болар. Күпме баргач, Алла белә,
Юл өстендә үлгән Бүре башын таба.

Курка башны кузгатырга Кәҗә-куркак,
Күптән инде куркаклыкка Сарык уртак, –
Баш янында болар икәү тора куркып,
Әйтешәләр бер-берсенә: «Син тот, мин тот!»

Кәҗә әйтә: «Сарык абзый, син көчлерәк».
Сарык әйтә: «Син, сакалбай, гайрәтлерәк».
Бүре башын кулга тотып кузгатырга
Юлдашларның берсенең дә җитми йөрәк.

Озак торгач шунда Кәҗә белән Сарык,
Бүре башын тоталмыйча, куллар барып,
Башны икәү тотып ике колагыннан,
Юнәлделәр, капчыклары эченә салып.
Бара болар. Тукталмастан һаман бара.
Күрә болар: ерак түгел бер ут яна.
Утны күргәч, иптәшенә әйтә Сарык:
«Әйдә, Кәҗә, куныйк бүген шунда барып.

Ут янына бүреләр дә килалмаслар,
Безнең анда кунганлыкны белалмаслар».
Сарыкның бу киңәшенә Кәҗә күнде:
«Әйдә, иптәш, ярар, барсак барыйк инде».

Кәҗә, Сарык ут янына якын барса,
Мискиннәрнең күз алдында менә нәрсә:
Өч-дүрт Бүре утырганнар каршы утка,
Тыршып-тыршып пешермәктә алар бутка.

Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны,
Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны.
«Исәнмесез, дустлар, Бүре әфәнделәр!» –
Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле.

Куаналар өч-дүрт Бүре, моны күргәч,
Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч:
«Ашыйбыз, – дип, – бу икәвен тотабыз да,
Менә ничек ит таптык, – дип, – буткабызга!»

Кәҗә әйтә: «Кайгырмагыз, бездә ит күп;
Ул ит берлән һәркайсыбыз булырбыз тук!
Ни карыйсың? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык!
Капчыктагы Бүре башын китер алып!»

Сарык шунда капчыктагы башны ала, –
Барча Бүре куркуыннан шашып кала;
Өч-дүрт Бүре хәйран калып торган чакта,
Кәҗә һаман гайрәт чәчә, ачулана.

Кәҗә әйтә: «Микикики! микикики!
Капчыктагы Бүре башы бит уники!
Ах, уңмаган, җүләр Сарык, надан Сарык,
Моннан зуррак Бүре башын китер табып!»

Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,
Капчыктан ул алып килә шул ук башны.
Өч-дүрт Бүре чынлап инде куркыштылар,
Бер-берсенә күзләрене йөртештеләр.
Түгел хәзер Бүреләргә ашау кайгы,
Тиз-тиз генә бу урынны ташлау кайгы.
«Ничек качыйк? Ничек табыйк качу юлын?» –
Һәрбер Бүре шуңар салган бөтен уен.

Торып әйтә шул арада өлкән Бүре, –
Картайган һәм күп эшләрне үткән Бүре:
«Туктагыз, – ди, – мин тиз генә су китерим,
Суы бик аз, безнең бутка пешәр коры».

Шулай итеп, өлкән Бүре суга китә.
Кайтмый ләкин, озак кына заман үтә.
Кайтмый Бүре – эзе дә юк, исе дә юк,
Мәҗлес халкы арып бетә көтә-көтә.

Бүреләрне тагы каты курку басты,
Чөнки хәзер башлыклары китеп качты.
Тагын берсе суга таба китте торып:
«Туктагыз, мин эзләп кайтыйм», – дигән булып.

Мәгълүм инде, бу Бүре дә кача шулай,
Хәйлә берлән качарга юл ача шулай.
Кайтмый бу да, әллә ничә сәгать үтә,
Мәҗлес халкы көтә һаман, көтә, көтә.

Өч-дүрт Бүре берсе соңра кача берсе,
Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе.
Болар качкач, Кәҗә белән безнең Сарык
Китә инде рәхәтләнеп, ирек алып.

Утыралар аяк бөкләп каршы утка,
Болар инде тәмләп кенә ашый бутка.
Ашап туеп, рәхәт кенә, тыныч кына
Кәҗә, Сарык бу төннәрен шунда куна.

Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук, –
Кулларында Бүре башы салган капчык, –
Тагын болар урман буйлап сәфәр итте.
Нәрсә языйм?.. Хикәям дә шунда бетте.

## 1910

## Татар мөхәрриренә

Яз, ни язсаң да, синең бар – язганыңның нашире;
Ашлыгың үстисә – бир, тайярдыр аның гашире.

Тик онытма: берзаман гүргә керер ялгыз башың;
Һичберәү булмас яныңда: иптәшең һәм кардәшең.

Барча әгъзаң чиркәнеч һәм куркыныч хәлгә керер;
Уйлаган башың, каләм тоткан кулың бергә черер.

Дөньяда булган кеби язганнарыңның наширe,
Монда да кортлар –
синең үлгән тәнеңнең «нашир»е.

## Нәсихәт

Ихтыяҗын гарз итеп килсә теләнче капкаңа,
Каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама.

Син кеби һәм ул теләнчеләр дә – Алланың колы;
Кул суза, мискин! – бәхетсезлек вә ачлык аркылы.

Күрмәгез бер яклы дип сез бу вафасыз дөньяны;
Ул ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.

Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә:
Син бүген бай, бәлки, шәйтаннан да ярлы иртәгә!

Булса – бир, булмас исә,
җайлап сөйлә булмаслыгын, –
Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын!

## Кәҗә тугърысында

Берзаман йорт кошлары, хайваннары
Хуҗаның каршына килделәр бары.

«И Хуҗа, безгә ризык биргән Хуҗа! –
Дип, сакалын селкетеп сөйли Кәҗә. –

Үзеңә мәгълүм, сиңа мин сөт бирәм:
Күп ашатсаң, аз да бирмим, күп бирәм.

Син, дөрест, ачтан мине үлтермисең,
Ни өчен җимне туярлык бирмисең?

Туймагачтын, мин караклыклар итәм,
Чит кешеләр бакчасын таптыйм, тетәм.

Урлаган чакларда, бик күп мәртәбә
Көчкә ләкми калды сыртым тәртәгә».

Бар кеше дә: «Ул Кәҗә залим, – диләр, –
Ул Кәҗәме? Ул Кәҗә!» – дип тиргиләр.

*

Китмәсен хак сүзгә һич кәйфең синең,
Күргәнең бармы Кәҗә бәйтен синең?

Әмма соң анда каты теткән мине,
Бер дә кызганмастан эт иткән мине.

Ул китапка мин ничек тәкать тотыйм?
Тыңлагыз, Хуҗам, хәзер бәйтен укыйм.

Укый:

«Ул Кәҗәнең ике исме булыр, имеш,
Берсе Кәҗә, берсе Каза булыр, имеш,
Ул Кәҗәне ярлы кеше асрар, имеш,
Сыер урнына сөтен савып эчәр имди.

Ул Кәҗәнең айрылыдыр тояклары,
Бакчачендә гизәр аның аяклары;
Калмас аннан кәбестә, суган кыяклары, –
Һәр суганның башын кыркып йөрер имди.

Игътибар юк ул Кәҗәнең сакалына,
Кыйнамыйча килмәс асла гакылына;
Ул Кәҗәне кайда күрсәң, шунда кыйна, –
Язык булмас, бәлки, савап булыр имди».

## Җәйге таң хатирәсе

*(Федоровтан мокътәбәс)*

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата;
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.

Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә;
Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.

Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм япан;
Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан.

Тын гына яткан, ялыккан, төн буенча көн көтеп,
Ялтырап, җәйлеп ята күлләр, сихерле көзге күк.

Шат үләнлекләр, тәбәссемдә чәчәкләр, лаләләр;
Сандугачлардан ява, яңгыр кеби, мәдхияләр.

Туктаганнар күрмәгә иртүк табигать күркене
Күктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.

Каршыларга иң сәза чак, иң матур чак җәйге таң;
Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң.

## Күңелле сәхифәләр

Бакчы аучыга,
Кош аулаучыга:
Шактый читен эш –
Арый, талчыга.

Йөгрә дә чаба
Кич-иртә бердәй;
Маңлайдан ага
Тирләр яңгырдай.

Очадыр үрдәк, –

Тизрәк бул, тизрәк:
Китмәсен ерак,
Ат мылтыкны, ат!

Атты, шарт итте,
Каты җил чыкты,
Эшләпә җилгә
Очты да китте.

Үрдәк югалды,
Эшләпә калды;
Мескен эшләпә
Җәрәхәтләнде.

Аттым мин кошка,
Китмәде бушка:
Алып кайтамын
Мәҗрух эшләпә.

Көлсә көләрләр
Кешеләр, күреп;
Тишекләреннән
Җил торыр өреп.

## Имтияз алган бала

Тырышты бу бала, чын ләззәт алды инде тәхсилдән;
Югары булды урны «афәрин»нән һәм дә «тәхсин»нән.

Ни кушсаң да укый алды, ни әйтсәң, шуны язалды;
Балаларның арасында үзенә «Имтияз» алды.

Беренче кәррә мөмтаз булса бер инсан туганнан соң,
Фәхерле имтиязларны алыр үскәч тә аннан соң.

## Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи –
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

## Һәр ялтыраган алтын түгел

Төнлә берлән бакчада бер аллы-гөлле Күбәләк,
Очкалап йөргәндә уйнап, анда-монда чүгәләп,

Күрде кырда: бик матур бер әллә нәрсә ялтырый,
Нурлана, җем-җем итә йолдыз шикелле, калтырый.

Күбәләкнең бер дә чик юк һәр матурга гыйшкына:
Тиз генә ул барды да кунды матур зат өстенә.

Ул матур зат юлчылардан сүнми калган ут иде:
Күбәләк булды һәлак шунда кунып – янды, көйде.

## Гали белән Кәҗә

Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,
Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.

Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

## Фатыйма белән Сандугач

Фатыйма:

Ни өчен син сайрамыйсың, Сандугач?
Шат була күңлем минем син сайрагач.

Читлегең әйбәт, яныңда бар ашың.
Ник күңелсез син болай, бөктең башың?

Сандугач:

Аһ, минем сайрар җирем урман иде,
Анда һәртөрле кызык тулган иде.

Мин бу җирдә нигә шатлык күрсәтим?
Анда өч баш кошчыгым калды ятим!

Һәм мине анда тагын дустым көтә,
Сагына ул, саргая ул, ут йота.

Белмисеңме син: читен мәхбүслек ул,
Булса да алтын, һаман да читлек ул.

Фатыйма:

Йә, алайса, мин ишек ачтым сиңа:
Бар, азат бул, кыйл миңа изге дога.

Бар, җаным, инде яшел урманга оч,
Тиз ятим кошчыкларың берлән кавыш!

## Һәркемнең ашыйсы килә

Урман буйлап Черки очып бара иде,
Бер-бер нәрсә ашарга уйлана иде.
Шул урындук, гөнаһ шомлыкка, бер Чыпчык
Йөри иде азык эзләп, пыр-пыр очып.

Инде Черки бичараның гомре бетте:

Теге Чыпчык сиздермәстән килде тотты.
Чыпчык күптән ашамаган, бик ач иде,
Черкине ул азык итте – капты йотты.

Шул ук җирдә оча иде бер Ябалак,
Азык-фәлән юкмы, диеп карангалап.
Төште аның үткен күзенә бу Чыпчык;
Ул Ябалак бу Чыпчыкка төште очып.

Инде хәзер Чыпчыкның да гомре тәмам:
Үзе хәзер Ябалакка булды тәгам.
Ябалагым бер-ике рәт чукып ертты,
Күз ачканчы Чыпчык та бетте, вәссәлам!

Булды пәйда әллә кайдан бер зур Бөркет,
Җил-җил иткән канатларын селкеп-селкеп.
Тотты да ул безнең батыр Ябалакны,
Тәгамлады чукып-чукып, йолкып-йолкып.

Әллә кайдан шунда килеп чыкты Аучы, –
Урманнардан ул да бер кош-корт эзләүче, –
Аучы килеп якынлашты Бөркет белән,
Атты Бөркеткә тугърылап мылтык белән.

Җәдрә тиде тугъры төзәп аткан җиргә:
Авып төште Бөркет җәдрә берлән бергә.

## Ялкау маэмай

Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә,
Җитезләнә, уйный һаман йөгрә-өрә;
Карый миңа мәхәббәтле күзе белән,
Гүя «уйныйк» дигән була, гүя көлә.

Кайвакыт ул ята тәмле ашап туеп,
Ал аяклары өстенә башын куеп.
Аны шунда чебен халкы тынычсызлый;
Ялкау маэмай! Ул аларны тормый куып.

Чебеннәрне астан гына карап ята,
Ярты йомык күзен генә ялтырата;
Бервакыт ул колак артын торып кашый,
Чебен халкы шунда тиз-тиз кача башлый.

## Шаян песи

Күрче, бик чынлап керешкән эшкә безнең Ләмига:
Бар уе – бер бик матур күлмәк тегү курчагына.

«Күлмәгем кайчан бетәр?» – дип, курчагы яткан, көтә;
Көтми хәл юк, бер тәти күлмәк кирәк – бәйрәм җитә.

Ә песи яшьрен генә яткан, кәтүкне күзлидер;
«Тукта, селкенмәсме?» – ди ул; бер дә җаны түзмидер.

Ул хәзер сикрер менә, хәзер тотар, хәзер басар;
Ул кәтүкне уйнатыр, уйнар, үзенә шар ясар.

Кайгысы юк ул песинең, тик һаман уйнау уе;
Бик шаян! Ай-һай, наян! Уйнарга хәзер көн буе!

## Кызыклы шәкерт

– Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

– Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә.

– Ах, җүләр маэмай! тырыш яшьләй,
зурайгач җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар, эш белү уңгайсыз ул!

## Ак Бабай

Бөтен дөнья аппак булып кар яуганда,
Ишегалды, урам, түбә агарганда,
Ап-ак булып кайтып килә безнең Бабай,
Безгә төрле-төрле уенчык алган да.

Шатланышып без әйтәбез: «Рәхмәт, Бабай,
Сиңа тагын күп ел гомер бирсен Ходай!»
Бабай, мескен, кар-яңгырга карамыйча,
Безне шатландырмак өчен йөри шулай.

## Ана илә бала

– Җавап бирсәң икән, әнкәй, минем әйткән сөәлләргә,
Гаҗәпләндем бу дөньяга вә анда барча хәлләргә:

Ничек булган, ничек үскән хисапсыз да бу урманнар?
Бу һәйбәт ямь-яшел кырлар каян килгән вә булганнар?

Бу һәртөрле үсемлекләр, бизәнгән чәчәкләр берлә,
Вә төрле күбәләкләр дә күңел ачкан алар берлә?

Агар су, татлы, салкын, саф гаҗәеп чишмәләр, күлләр,
Куаклыкларда сайрар сандугачлар һәм дә былбыллар?

Суда йөзгән балыклар һәм үсеп торган бу зур таулар,
Чебен, черки вә ерткычлар, кәҗә, ат, барча җанварлар?

– Яраткан, әйләгән мәүҗүд боларның барчасын Тәңрең,

Җиһанда барча эшләр, барча хәлләр Тәңредән, бәгырем.

## Бичара Куян

– И Куян, куркак Куян, йомшак Куян,
Моңланасың нинди хәсрәт, кайгыдан?

– И җаным, син яшь бала шул, белмисең;
Төште зур хәсрәт, ничек моңланмыйсың.

Без икәү: Әткә куян, Әнкә куян,
Яшь куянчыклар янә бездән туган.

Барчабыз бер гаилә булган идек,
Күп заман шатлык белән торган идек.

Яшь балаларны ашап китте Бүре,
Бик усал ерткычтыр ул, мур кыргыры!

Күп тә үтми куйды дөнья Әнкәсе;
Тулды күңлем, ничек итеп әйтәсе:

Килде дә бер явыз Аучы Эт белән,
Атты, үлтерде аны мылтык белән.

Шул вакыттан бирле аш булмый ашым,
Моңланам ялгыз башым, агъзам яшем.

## Кичә һәм бүген

Йа Ходай, көн кичә ямьсез, ә бүген, аһ, нинди көн!
Кичә сынды һәм боекты, ә бүген күңлем бөтен.

Әй кояш нурлы – ачылган бакчаларның гөлләре;
Яктылык! рәхәт! бәхет! Сайрый Ходай былбыллары!

## Ике иптәш арасында

– Җәле, иптәш, ни ишеттең, бер хәбәр сөйләп җибәр:
Кайда, кемнәр нишләгәннәр? Юкмы яңа бер хәбәр?

– Китсәнә, иптәш, йөдәтмә, эшләрем бит бар минем;
Юк хәбәрләрне сөйләп тормакка вактым тар минем!

– Сөйлә инде, ни хәбәр бар, иптәшем, назланмачы;
Әллә нидә бер соравымны да җиргә салмачы!

– Кит, димен, иптәш, йөдәтмә!
мин беләм тик: син – җүләр;
Нәрсәсен сөйлим моның мин – инде бу иске хәбәр!

## Катиле нәфескә

Котылмакчы булып татсыз хәяттан,
Гомергә җан авырттыргыч газаптан,

Гакыл бу дип, үзеңнүзең үтердең,
Тынычлык эзләдең дә гүргә кердең.

Вәләкин, и карендәш, алданасың,
Үзеңне мәңгелек утка саласың.

Синең тик сурәтең китте җиһаннан,
Һаман да калды рухың яки мәгънәң.

Синең бар дөньяда күргән газабың,
Гөман юктыр, бозык булганга җаның.

Әгәр рухыңны ислах итми үлсәң,
Барыбер син газапта, яхшы белсәң!

Кирәк черсен, кирәк торсын – ни ул тән?
Чыдамсыз бер кием ул җанны өрткән!

Әгәр син катле нәфситмичә торсаң,
Җаныңны изгелек берлән тутырсаң,

Ачар ирде Ходай бәхтеңне, шаять,
Ашыктың, эшләдең бик зур җинаять!

Газап китми кабердә тән черүдән:
Бүрек ташлап котылмыйлар бүредән!

## Газаптан соң

*(Майковтан мокътәбәс)*

Мин бәхетле бәндә, чөнки тормыш алдымда һаман
Барча шау-шу һәм дә барча күрнеше берлән тәмам.

Алдагы михнәтнең урнын әллә истикъбаль ала?
Тормыш инде яктырадыр, кузгала һәм җанлана.

Таң атып, чәчсә кояш нурлар – шулай ук кузгала,
Яктыра, шаулый ерак җирдән күренгән зур кала.

Үземә сөйнеч бирәм инде, бәхет, гыйззәт белән;
Уйлыймын үткән газапларны хәзер ләззәт белән.

Булмадымы шул газаплар бәхтемең ачкычлары!
Җитмәкемнең изге максудка ләгыль баскычлары!

## Ачы тәҗрибә авазы

Сөям кайчакта бер-бер иптәшемне,
Аңар мин күрсәтәм күздә яшемне.
Кыйлам изһар аңар кайгы, моңымны,
Сөйлим бер-бер барымны һәм югымны.
Күренә ул мәхәббәтле күземә,
Куяр төсле бәһа һәрбер сүземә.
Алалмыйча теким күзне күзенә,
Чыгадыр балкыган нурлар йөзенә.
Килә шунда бер аваз әллә кайдан:
«Ышанма, дөньяда һәркемдә ялган!
Аның тик тышкы ягын син күрәсең,
Мәхәббәтле әһәмият бирәсең.
Тышыннан кызгану күрсәтсә дә ул,
Эчендә нәрсәләр ятканы мәҗһүл.
Әгәр күрсәң аның йөзендә нурны,
Бу нурга мәгънә бир син башка төрле:
Аңар син саф күңел берлән ышандың,
Эчеңдә кайгы, хәсрәттән бушандың.
Бушанды, пакь вә саф күңлең әчелде,
Тирә-якка шуның нуры чәчелде.
Йөзендә күргәнең нур иптәшеңнең
Нурыдыр саф күңел һәм күз яшеңнең.
Кара йөз ул, кара эч ул һаман да,
Мәхәббәт һәм кешелек юктыр анда!»
Менә шулчак тәмам мин аптырыйм да,
Аваз килгән тарафка бер карыйм да:
«Аваз! – дим, – ишteләсең,
                    әйтче, кайдан?
Фәрештә кычкырамы яки шәйтан?!»
Җавабында аваз: «Син рәнҗемә, – ди, –
Минем исмем – ачы, карт тәҗрибә», – ди.

## Җәй көнендә

Каты эссе. Һава бөркү. Кыза дөнья, сабыр җитми,
Җил исми аз гына да, бер генә яфракны селкетми.

Корылык һәр урыннарда. Кибә вак-вак кына күлләр,
Шиңәргә йөз тота кырда үләннәр, чәчкәләр, гөлләр.

Агачлар астына сыгъна балалар барчасы бергә,
Алай да булмаса, барсы төшәләр сикрешеп күлгә.

Алар ап-ак балыклар күк йөзәләр иртәдән кичкә
Кадәр шунда, туңып бетмичә ярга чыкмыйлар һич тә.

Менә шунда кисәктән йөзгә бернәрсә тиеп китте;
Сабамы, нәрсәдер, салкынчарак бер җил сөеп китте.

Якын урманның артында яшеннәр ялтырый аз-аз,
Ерактан, әллә кайдан, ишетелә күк күкрәгән аваз!

## Кайчакта

Була кайчак бөтен уйдан күңел буш,
Туза уйлар, мисале гыйһне мәнфүш.

Күңелдә яткучы изге хәзинә

Вакытлыча китә үз мәәхәзенә.

Бушап күңлем, була рухымда тәгътил,
Ителми берни дә тәхкыйк вә тәхлил.

Менә шулчак кешеләр шелтәлиләр:
«Нигә син язмыйсың һичнәрсә?» – диләр.

Җавабымда: «Вакыт юк, – дим аларга, –
Бушамыйм бу арада язгаларга».

Шулай, кайчак кесәгезнең төбендә
Беләсез юклыгын ярты тиен дә,

Сораучыга дисез бит: «Миндә вак юк!»
Шулай ук мин дә әйтәм, дип: «Вакыт юк!»

## Гомер юлына керүчеләргә

Беләм инде, сабыйлар, сезгә мәктәптә күңелсездер,
Аның тоткынлыгыннан сез бигүк разый түгелсездер.
Сабый чакта күңелсезләнгәнем бар мин дә, һәм шунда
Очып эзли иде фикрем азатлык анда да монда.
Заман үтте. Азат булдым. Теләгем алдыма килде.
Күрәм: мин дәү кеше булдым вә мәктәптә түгел инде.
Ачылды юл, ирек алдым. Эчемнән нәрсәләр уйлыйм:
«Менә шатлык миңа, дим, мин хәзер тормыш белән уйныйм.
Шаярырмын, теләрсәм нишләрем, уйнар, көләрмен, дим,
Бөтен мәктәптә тоткынлыкларым бурчын түләрмен», – дим.
Кереп киттем гомер юлына... Әллә мин йөри белмим?
Нидәндер анда мин шатлык, азатлыкларны һич күрмим.
Барып булмый. Ирексез тукталамын юлда кайчакта, –
Каты сызлап, бу юлымда аяклар йөрмидер хәтта!
Йөреп мин, шатлык эзләп бу гомер юлында акрынлап,
«Гомер итмәк» димәкнең мәгънәсене аңладым чынлап:
Гомер итмәк – тырышмактыр ялыкмый, һич тә ял итми,
Гаталәт хурлыгын асла үзеңә ихтыяр итми.
Тиеш, имеш, үтәргә изге юлда бу гомер барсы
Түләү берлән бурычны Тәңремә һәм халкыма каршы.
Бәхетлемен шушы хәлдән, бүтән бер хәл дә көтмимен,
Шушы юлдан ризамын, башка төрле юл да тотмыймын.
Әгәр кайчак гомер сахраларында мин гизеп арсам,
Гомер юлында бер мәүкыйф ясап алмакны уйлансам,
Итәм дәрхаль тәвәкъкыф мин сабыйлык хатиратында,
Очам мәктәп таба нурлы тәхаттырлар канатында.
Күңелдән сагынам «тоткын»лыгымны, мәктәбемне мин,
«Нигә соң үстем инде һәм нигә «дәү» булдым инде, дим.
Нигә, дим, изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым?
Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зуп-зур Тукай булдым?»

## Өмидсезлек

Тәндә җаным, чык та Тәңреңә юнәл, бар, кайт кире!
Китте җаннар азыгы, һәм кайтты истибдад кире.

Көлмә син дә бу бозык дөньяга каршы та әбәд,
И кояш! мәңгегә чыкма, бул кара тап, бат кире.

Яз башы дип, башны калкытмагыз, и гөл-гонҗәләр!

Бел, янарсыз: җир хәзер ялкынлы истибдад җире!

Калмасын дустлык, мәхәббәт, чын сөешмәк дөньяда,
Бу җәһәннәмдер, түгел Ширин илә Фәрһад җире.

Тәрке хезмәт әйләгез, үткен гакыллар, сез дәхи,
Бер дә тугъмаслык булып бет син дә, истигъдад, кире.

Сез дә, и мөһлик мәрыйзләр, урныгызны ташлагыз,
Барчагызны мөштәмилдер кайтты истибдад чире.

Сез дә, мәзлумнәр гөруһы, хак өчен кул сузмагыз,
Тик кыямәт көнгә калды хаклар истирдад кире.

Гыйше-гыйшрәтләр, музыка, тансалар, уйнау-көлү –
Барчасы бетсен хәзер, җир чөнки тик фөрьяд җире.

И каләм, син хакны язма, күз буя, юк-барны яз,
Бумыни соң тугъры әшгарны язып иншад җире?!

## Үкенеч

Электән белгәнем хәлдә кешенең
Тышы яхшы, бозыклыгын эченең.

Ничек соң мин адаштым изге юлны,
Биреп мәлгунь, Ходайсызларга кулны?!

Нигә мин, алданып ялган көлүгә,
Нифакъ иттем үземдәге голүгә?!

Нигә булды зыя сөйгән азат баш
Монафикълар караңгысында хәффаш?!

Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз –
Ничек күктә яна бер данә йолдыз?

Шулай янсам, ни булды, төшми җиргә,
Якынлашмыйча һәр мәгърур сәфилгә!

Янып ялгыз шулай, күп еллар үткәч,
Сүнәр идем, Ходайдан вәгъдә җиткәч.

Әсирмен, ычкыналмам инде мәңге,
Күңелсез һәрьягым – нурсыз, караңгы!

Монафикълар камап һәр дүрт ягымны,
Күрәлмим мин кояшым һәм аемны.

Кырылды алда изге эшкә вәгъдәм,
Караңгыда күренми чөнки кәгъбәм!

Һава юктыр, алалмый рух сулыш та,
Кабахәт бөркү уң, сул, астта, өсттә.

Читен хәл: гайрәтең җитсә – ерып чык,
Әгәр җитмәс исә – бет, шунда тончык!

## Яшьләр

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.

Кичә якты вә милли бер күңелдән

Бүген тычкан утыдай нур табылмас.

Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,
Көмеш, алтын санәмнәргә табынмас?

Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.

Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңлен дә салмас.

Сатучылык итә бездә мөхәррир,
Әдип исме аңар тагълыр-тагылмас.

Яралганмы бу яшьләр күңле әллә
Мөрәүвәт маддәсе ягълыр-ягылмас?

Ышанабыз халык көчсезлегенә,
Бабайлар шөһрәтен сагъныр-сагынмас.

Тотып милләт ливасын, юлга чыктык:
«Бу куллар мәңге, – дип, – җиргә салынмас».

Җыгылдык без икөч чакрым да китми, –
Җегетләр! бездә көч юк, – ахры, булмас!

## Баскыч

Сөялгән, өй түрендә бар иде гаять тә зур баскыч,
Кырыклап басмасы бар – бик авыр һәм дә озын баскыч.

Кирәклектә бәрабәр булсалар да басмалар бергә,
Югаргы басма тиңләшми түбәнге басмалар берлә.

Югаргы басма мәгърур:
«Мин югары, сез түбәнсез, – ди, –
Ничек гали минем урным, түбәнгеләр, күрәмсез?» – ди.

Бер адәм килде дә шул чакта әйләндерде баскычны:
Түбәнге басмалар менде, югаргысы түбән төште.

## Актык тамчы яшь

Бик юашлатты мине яшьрен сөюдән җан көю,
Бар иде булган чагым хәтта арысланнан кыю!

Һәр теләккә килде тәкъдирем белән бәхтем кире,
Мондый хәлгә сабриталмас, булса да адәм дию.

Инде күңлем касәсеннән яшьне түкмәккә җитә,
Уйлаган вакътымда аңсыздан килеп тә «һай!» дию.

Үлде рух яшьрен мәхәббәттән, – хафа юк үлсә дә, –
Нишлим, иркәм кәйфенә килгәч шулай бер җан кыю!

## Бер мән

Итәм кайчак бөтен инсанга нәфрәт,
Бу нәфрәттән туа күңлемдә хәсрәт.

Тула күкрәк ачы, яшьрен зәһәргә,
Ачу зәһре ага җан берлә тәнгә.

Сөеп тә алданып бер мәнне җандай,
Чәчә зәһрен күңел мәҗрух җыландай.

Бөтен инсан вә җир, күккә, нөҗүмгә
Күңел башлый, котырган күк, һөҗүмгә.

Өмидсезлек, усаллык, вәсвәсәләр
Зәгыйфь җанны теләләр һәм кисәләр.

Өзеп барлык хәятымнан өмидне,
Димен: «Аһ! бар да бетте, бар да бетте!»

Димен: «Җирдә мәхәббәткә урын юк
Вә булмас, булмагандыр ул борындук!»

Менә шулчак керешеп эшкә, гакълым
Кушадыр тикшерергә хәлнең аслын:

«Кара, – ди, – әйлә син дөньяга дикъкать,
Бөтенләй сүнмәгән анда мәхәббәт.

Кара эзләп, табарсың син җиһаннан,
Бөтенләй китмәгән кодсият аннан.

Җәмигы әнбияның мәһде – дөнья,
Вә барча әүлияның ләхде – дөнья!»

Фәкать бу сүзгә күңлем һич ышанмый
Вә нәфрәт вәхшәтен һич ташлый алмый.

Менә шул чакта һич ис итмәгәндә,
Явызланган күңел хис итмәгәндә,

Ничектер табыла дөньяда бер мән,
Тулы күңле мәхәббәт хисе берлән.

Мөҗәссәм бер кешелек ул җылы җан,
Аны тәкрим вә тәкъдисне тели җан.

Аның берлән, итеп сохбәт, сөйләшсәм,
Яшермәстән бөтен күңлемне ачсам,

Бетәдер ярасы рухның вә хиснең,
Тигәндәй куллары гүя мәсихнең.

Сөйләшкән сүзләре гөлдәй тамадыр,
Сулаган сулышы баде сабадыр.

Тисә киеме генә яңлыш тәнемгә,
Туадыр бихисап шатлык җанымда.

Була җанга хозур бу ултырышта,
Сөйгән төсле канат берлән фәрештә.

Менә шунда ачы яшьләр түгәм мин,
Дәсисә, вәсвәсәләрдән чыгам мин.

Тибәр күңлем моңарчы бер ләгыйньчә
Тибәдер «рәхмәтән лил-галәмин»чә.

## Елның дүрт фасылы

*(Русчадан)*

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде;
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,
Төннәр кыскара.
Бу кайсы вакыт? –
Йә, әйтеп кара.
*(Яз көне)*

Ашлыклар үсте,
Башаклар иеште;
Кояш пешерә,
Тиргә төшерә.

Халык ашыга,
Китә басуга,
Урагын ура, –
Бу кайчак була?
*(Җәй көне)*

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, –
Бу кайчак була?
*(Көз көне)*

Һәр җир карланган,
Сулар бозланган;
Уйный җил-буран, –
Бу кайчак, туган?
*(Кыш көне)*

## Төш

*(Гётедән)*

Мин төш күрдем. Гүя мин бер зур шаһ, имеш,
Таҗма тезгән энҗе, мәрҗән, ахак, имеш;
Сине сөеп, шигырь сөйләп, шагыйрь булып
Йөрүләрем бөтенләй үк нахак, имеш.

Таҗлы башым хозурыңда иям, имеш,
«Җанашым, мин сине сөям», – диям, имеш;

Нәрсә генә әйтер инде сөйгәнем дип,
Эчемнән бик янам, имеш, көям, имеш.

Әтрафымны чолгап алган гаскәрләр дә
Гөл йөзеңә күзләрене теккән бар да;
Минем өчен синнән шәфкать булырмы дип,
Бөтен гаскәр тын да алмый интизарда...

Төш шул төшкә җиткәч, шагыйрь уянды да,
«Явыз язмыш!» – диеп, азрак уйланды да,
Уйларга да өлгермәде, мискин гашыйк,
Кайнар яшькә ике күзе чыланды да!

Бераздан соң килде аңар шатлык янә:
Егъласам мин, егъладым, ди, шашып кына;
Мәхәббәтем һаман иске мәхәббәт ич,
Югалтсам мин, югалттым, ди, шаһлык кына.

## Өзелгән өмид

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урнында анда тулган айның яктысы.

Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.

И мөкаддәс моңлы сазым! уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барсы корган – бер генә юк җанлысы, яфраклысы.

Булмадың алтын ярым – салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

## Өйләнү – түгел сөйләнү

*(Иванов-Классиктан)*

– Кара, иптәш, сиңа килдем киңәшкә:
Күз аттым мин бүген бер шәп кәләшкә.

Ни дирсең син, әгәр дә мин өйләнсәм,
Кеше төсле урынлашсам, көйләнсәм?

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,

Матур, якты гомер бирсен Ходаем.

– Шулай димсең? Шулаен ул шулай да,
Ярый ла эш барып торса уңайга.

Хатын алмак читен бит һәм мәшәкъкать,
Бер алгач, булмый бит шәйтанны ташлап.

Бөтенләй бәйләнә анда аяк-кул,
Җүләрлек ул – өйләнмәк, гайре мәгъкуль.

– Алайса, көчләми һичкем, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә!

– Шулай димсең? Шулаен ул шулай ла,
Әгәр дә охшаса ул тулган айга!

Фәрештә күк көлеп алдыңда торса,
Вә, туптай, киң кочакка ул атылса!

Шулай булгач, ничек алмый түзәрмен, –
Алам мин, бәлки, рәхәттә йөзәрмен.

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Сәгадәтле гомер бирсен Ходаем.

– Шулай димсең? Шулаен ул шулай да,
Ярый ла эш барып чыкса уңайга:

Хатыннарны сөюче бер матур яшь
Минем ярны сөюдә булса көндәш;

Сөеп китсә хатын һәм ул җегетне,
Читен тормыш: бер айда бар да бетте!

– Алайса, көчләмәс һичкем, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә.

– Өйләнмим, – дим, – «өйләнмим» –
ул матур сүз,
Читен шул дөньяда тормак хатынсыз.

Ятасың боз кебек салкын түшәктә,
Гүя син бу җиһанга килмешәк лә!

Бүленми эш тә бер мәгълүм вакытка,
Бу хәлләр бик ерак, иптәш, бәхеткә!

Кәләшкә мин бүгеннән яучы салсам,
Озак үтми аның куйнына барсам,

Җылы куллар белән ул тәнне сарса! –
Бәхет шул, эзләмим мин башка нәрсә.

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Җылы, якты гомер бирсен Ходаем.

– Шулай ла ул әгәр дә иркә булса?
Тәкәббер бер кабарган күркә булса?

Риза булмый минем тапкан табышка,
Сәбәп булса һаман юк-бар тавышка?

Риза булмый минем алган киемгә,

Төшерсә ул кесә якны кыенга?

Ире кем? Баймы, юкмы, белми хәлен,
«Китер!» – дип дауласа зәңгәр вә алын?!

– Шулай, иптәш, алай куркъсаң, өйләнмә,
«Киңәш бир дә киңәш бир», – дип сөйләнмә.

– Шулай да бит ата булмак күңелле,
Бөтенләй шат итә ул хәл күңелне.

Балаң йөгреп менә алга «әти!» дип,
«Китер, әткәй, миңа мәммәм! тәти!» – дип.

Бу хәл, иптәш, җуатмасмы күңелне,
Бөтен рәхәт, хозур шунда түгелме?

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Әти булмак насыйп итсен Ходаем.

– Шулай да соң балаң булса биш-алты,
Өең тулса шулардан һәм каралты?

Шуларны туйдырамын дип тиреӊ түк,
Иел җиргә, дуга төсле, билең бөк.

– Алай булса, хатынсыз тор, өйләнмә,
«Киңәш бир дә фәлән бир», – дип сөйләнмә.

– Шулай да ул балалар үссә бар да,
Әгәр дә җир җиләктәй пешсә бар да?

Таянып яшь гакылга һәм дә көчкә,
Керешсә һәрбере бер яхшы эшкә;

Баеп китсә алар шул эш юлында? –
Итәрләр тәрбия картлык көнемдә.

– Алай булгач, өйлән, дуст, чикмә ваем,
Тыныч картлык насыйп итсен Ходаем.

– Шулай, ләкин кирегә ишсә язмыш?
Үлеп китсә хатын, күп тормый, яңлыш?

Биш-алты яшь бала калса кулыңда, –
Менә инде чокыр тормыш юлында!

Тынычлык юк аларның борчуыннан,
Колагың тык аларның чыр-чуыннан!

Менә, иптәш, бу эшкә аптырыйм мин,
Бу уйны уйлагач та калтырыйм мин!

– Алай булгач, куша чорт, һич өйләнмә,
«Киңәш бир», – дип йөдәтмә һәм сөйләнмә!

Диим бер сүз, бүтән бер сүз дә катмам:
«Хатын алсаң, кирәк ит көн дә батман!»

## Тәләһһеф

Мәлганәт, пычрак вә ялган белә тулган безнең эч;

Бар начарлыктан, бозыклыктан гыйбарәт безнең эш.

Шаккатабыз тышкы зиннәтләр, киемнәргә карап;
Җан сатабыз әллә нинди вак «тиеннәргә» карап.

Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк;
Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә – мунча,
җанга – юк?!

## 1911

## Борын

*(Русчадан)*

Электә бер кешедә бар иде киң бит, зур ындырдай,
Аның нәкъ уртасында бер борын һәм зур чөгендердәй.

Тәкәббер бу борын, китми исе һич башка мәхлукка;
Олугълыкны сөя торган, чөя торган үзен күккә.

Борын тәхкыйрь итә торган иде бигрәк аякларны,
Диеп: «Сез бик түбән җирдә, ерасыз былчыракларны».

Борынның сахибе беркөн чыга яңгырлы көн юлга,
Каядыр ул бара, һич тә борылмый уңга һәм сулга.

Егылды ул кисәктән, чөнки баткактан аяк тайды, –
Тәкәббер зур борын бик шәп кенә баткакка капланды!

## ...га

Шома тормыш юлында гизгәнеңдә яңлышып тайсаң,
Йөзеңнең дәфтәренә син хатаән кер вә тап салсаң,

«Кабахәт», «бәдбәхет», «җүнсез» кеби күп ямьсез ат алсаң,
Сине ташлап бөтен дөнья, үзең ялгыз фәкать калсаң, –

Белеп тор: мин чыгармын таш күңелләләр арасыннан,
Көлеп тормам, карап читтән, синең бәхтең карасыннан.

Бүләрмен, бергәләрмен барча кайгы, моң вә аһыңны,
Сиңа дошманлык итмәм мин, алып күзгә «гөнаһ»ыңны.

Халык ләкин сиңа иткән үзенең хөкмене бозмас,
Егылганнарга кул бирмәс, батып барганга җеп сузмас.

Җәза бирми халык һич тә гөнаһ эш, яшьрен эшләргә,
Куша анчак кеше сизмәс рәвештә яшьрен эшләргә!

Җәзалау камчысын биргән гөнаһлы ул халыкка кем?
Түгел, юк! Бирмәгән һичкем; Ходай – гадил,
Ходай – хаким!

Икәү без, бер дә тилмермә халыкка, сөймәсен барсын,
Аның күк тиз сүнә торган сөюдә ни хәер бар соң!

Оныт барсын – бөтен хәсрәт вә моң-зарыңны тын эчтән,
Хозур да эзләмә инсаф вә вөждан кушмаган эштән.

Моны яздым, киңәш бирдем, юаттым һәм тыйдым, куштым;
Шулай булмыйча хәл юк, инде калган мин генә дустың!

## Мияубикә

Йокы

Ал аякларга башын куйган да йоклый, төш күрә;
Төштә дә тычкан, күсе халкы белән ул эш күрә.

Бер күсе йөгрә, имеш тә, бу куган төсле була
Һәм куып җиткән дә муйныннан буган төсле була.

Читтәрәк өч-дүрт песи чыпчыклар аулыйлар, имеш;
Өй түбәсендә җыелганнар, мыраулыйлар, имеш.

Һич бозучы юк кәефне, эт тә куркытмый өреп.
Бик тынычлык. Тик ята ул, төрле тәмле төш күреп.

Уяну

Торды, исни инде ул, бик зур итеп аузын ачып,
Арт аяк һәм ал тәпиләрне идәнгә нык басып.

Тырпаеп киткән мыеклар һәм югарырак башы;
Нәкъ дуга кук бөкрәеп киткән песинең аркасы.

Күз йомык, тынлык бөтен як, бер дә ул-бу юк әле;
Башта да яхшы-яманнан һич тә бер уй юк әле.

Бу – йокы ялкаулыгыннан киерелеп иснәү генә,
Бар песиләр һәм кешеләрчә бер эш эшләү генә.

Акыллыбашланып уйлану
һәм әсәрләнү

Ул утырган бик матурлап һәм акыллыбашланып;
Уйга чумган, җиргә күз теккән җиһаннан баш алып.

Һич белер хәл юк ниләрне уйлаганын гакълының, –
Әллә уйлыймы тәрәккъыйсен песиләр халкының?

Үз-үзеннән нигә ләкми кулга тычканнар, диме?
Тәмле кошларга канатлар нигә чыкканнар, диме?

Әллә инде, ник тиялмим йортта үрдәк, казга, ди?
Сөт эчәргә кайсы чакта төшкәлим ич базга, ди?
Әллә инде кич ашаган тәмле ашын уйлыймы?
Әллә бу көнгә үзенең карны ачын уйлыймы?

Тукта, чү, шунда якында әллә нәрсә селкенә, –
Бетте уй, инде песинең ауга күңеле җилкенә.

Әллә тычканмы мич астында чыелдап кычкыра?
Бер күсе мәллә идәннең тактасын кимреп кыра?

Үрмәкүч сузганмы әллә шунда бер төшкә җебен?
Тибрәнә, чыр-чыр итәме шунда ләккән бер чебен?

Белмимен ни булганын, белсен песиләр үзләре,
Мин күрәм тик: ялтырый инде песинең күзләре.

Нечкәләп карау

Нинди күзләрне зурайткан, ачкан инде шар кеби,
Шул тирәдә бик кирәкле бер кызык хәл бар кеби.

Бер кирәкле эш песигә шунда бар, чынлап та бар;
Ни була инде хәзер: шатлык вә йә кайгы аңар?

Ут алынган өй эчендә, яктылык алган залын;
Бай хатыны көзге алдында төзәтә калфагын.

Кайдадыр, кемнәрдә бардыр бу кичә парлы кунак;
Ул күренмәкче буладыр шул кунакта яхшырак.

Йә оныткан ул хатын, яки песине күрмәгән, –
Ни сәбәптәндер песигә кичке ашын бирмәгән!

Кайгысы безнең песинең тик бары шул нәрсәчөн,
Күзләре булган тишәрлек һәр караган нәрсәсен.

Шатлыклы уй, хәсрәт һәм кайгы

Нинди елмайган авызлар! Күрсәнә, ул нинди шат!
Килсен асты өсткә дөнья, һич тә итмәс илтифат.

Тел очында бар бугай бер бик кызык, үткен сүзе;
Ни сәбәптәндер яшергән, әйтәсе килми үзе.

Нәрсә булган соң песигә? Үзгәрә шундук рәсем:
Аз вакытта кайгыру алган чыраен, чәһрәсен.

Ул берәүне, кемнедер, алдарга булгандыр көлеп,
Шул көлүгә каршы бер калҗа бирерләр дип белеп.

Бушка киткән көлгәне дә, бирмәгәннәр калҗаны;
Шул сәбәптән кайгыра ул, рәнҗи шунлыктан җаны!

Зарлану һәм гаҗәпләнү, намәгълүм
бернәрсәдән әсәрләнү

Карны бик ачкан песинең, бирмәгән һичкем дә аш,
Кызганыч, моңлы мияулый, егълый, мескен, күздә яшь!

Карны ачлык хәсрәте, инде хәзер үзгәрде төс;
Төскә хәсрәт билгесе чыккан хәзер нинди дөрес.

Нәрсәдер читтә, ерак, шунда шытырдый башлады,
Инде онтылды песинең егълавы һәм яшьләре.

Шул шытырдау нәрсә? дип тыңлый, утырган яхшылап,
Күзләре читкә акайган, һәм дә бик торган колак.

Ни икән соң ул шытырдаучы вә нинди җан икән?
Ул әле яшьрен: песигә дуст микән, дошман микән?

Юри генә исе китмәгәнгә салышу

Куйдылар инде шикәр каткан җылы сөтне аңар;
Күрсәтә шундый кыяфәт: ул исе китми аңар.

Бик ашыйсы килсә дә һәм барса да ачтан үлеп,
Сузла ул ашка ашыкмый, бик суфиланган булып.

Ул күренмәкче була инде тамагы тук кеби;
Күп ашау, ачкүзлелек бер дә үзендә юк кеби.

Чөнки ул ачкүзлелектән күп кыен алган иде,
Шул кыен күңлендә онтылмас булып калган иде.

Һөҗүмгә хәзерләнү,
туклык ялкаулыгы

Артка салган ул колагын, җиргә яткан ау өчен –
Ни генә селкенсә дә, сикреп барып аулау өчен.

Әллә тычканның оядан күрдеме койрык очын,
Мондый тайярлык вә саклык нәрсәгә һәм ни өчен?

Өстериләрме шаяннар җепкә таккан бер кәгазь?
Нәрсәдер бар, ул һөҗүмен бер дә юкка эшләмәс!

Күрсәгез күз алдыгызда бер песи рәсме шул ук,
Ул ята ялкауланып, аштан соң инде карны тук.

Хәл җыя рәхәт кенә, ирнеп кенә һәм тын гына,
Күзләре йомлып бара инде аның әкрен генә!

Йокласын ул, и шаяннар! Сез аңар сүз катмагыз;
Торгач уйнарсыз, йокысын бүлдереп уйнатмагыз!

Аналык шәфкате!

Нинди шәфкать! Өстенә баксаң, күңелләр нечкәрә,
Мондый хәл күргәч, күңелләрдә мәхәббәт көчләнә.

Үз баласын ул юа, пакьли, теле берлән ялый,
«Бәбкәем! – дип, – күз нурым!» – дип,
яшь баласын иркәли.

Ул җитез, йөгрек песилектән чыгып, инде ана,
Һәр ике җанны күңел инде сөя һәм кызгана.

Рәхәт кенә калыгу, гаҗәпләнү

Дикъкать иткән, күзне теккән әллә нинди нәрсәгә,
Ни гаҗәп булган песигә? Башта нинди мәсьәлә?

Башта тулган төрле уйлар, зиһне эшли бик каты,
Күзләрен күргән кешегә билгеледер дикъкате.

Ул гаҗәпле мәсьәләне уйлый-уйлый баш арып,
Калды ул инде тынычлыкка вә рәхәткә талып.

Ачу аралаш курку, чын курку

Бу ике баш өстенә әллә күтәрелгән таяк?
Кайсы чакта ул таяк тормый песиләр дип аяп!

Бик кәеф киткән песиләрнең, икәүләп куркалар;
Тик бераз бу куркуларның бер-береннән фәркы бар:

Бер песи дошманга азрак каршылашмакчы була,

Берсе һич тә каршы тормый, читкә качмакчы була.

Ләззәтләнү һәм хозурлану,
куркыныч һәм каһәрләнү

Аркадан, баштан сыйпыйлар, и күңелле! и хозур!
Инде ләззәт, иркәлекләр, күр, песидә нинди зур!

Зур бәхетлелек вә шатлык аңлата көлгән төсе,
Бик хозурлыктан ачылган аузының да яртысы.

Кәйфенең бик шәплегеннән кәкрәеп киткән башы,
Күзгә дә килгән олугъ шатлык вә рәхәттән яше.

И кызык соң бу җиһанда! Шәп торамын, ди, бугай;
Ни кирәк булса, шуңарга аптырамыйм, ди, бугай.

Ул шулай инде, вәләкин бер көе тормый җиһан:
Ул җиһан шатлык белән хәсрәтне бер җиргә җыйган.

Басты аңсыздан, килеп, койрыкка шунда әллә кем,
Орды камчы аркага һич юкка гына әллә кем.

Инде һәртөрле зәһәрләр һәм каһәрләрдән эче
Туп-тулы булды песинең, кайраладыр һәр теше.

Һәм үрә торды, кабарды бар тәненең һәр төге,
Үч алу дәртендә гүя һәр төгенең бөртеге!

Барсы да бетте!

Фани дөнья! Нинди эшләр эшлисең син – шак та кат!
Шундый шат уйнап, көлеп йөргән песи инде вафат!

Бу хәбәр тизлек белән читкә җәелгәндер хәзер,
Һәм идән астында шатлыклар вә бәйрәмдер хәзер.

Ул йөриләрдер күселәр шатланып, җырлап, биеп!
«Бәдбәхет, залим песи, син тар кабердә ят!» – диеп.

Мәрсия

Күчтең инде дөньябыздан ахирәткә, хуш, песи!
Байлыгы берлән иманның, изгелектә күч, песи!

Сау чагында күп золым кыйлсаң да тычканнарга син,
Бик тыныч бул, ярлыкар Алла гафур һәм гафве киң.

Дөньяда иттең зарарлы нәрсәләргә сакчылык,
Шул сәбәпле дәфтәреңдә, бәлки, күптер яхшылык.

Шунда да бик кызгана, мәрхүм, сине инде күңел,
Инде синнән куркъмыйлар кортлар да –
тычканнар түгел!

Кайвакыт ялгыз чагымда зур юаныч син идең,
Һәм шаярып көлдерә торган куаныч син идең.

Мич башында йоклаган чакта бабай гыр-гыр килеп,
Син дә йоклыйдыр идең бер читтәрәк мыр-мыр килеп.

Көн буе уйный идек без; һич тә тик тормый идең,
Кулларымны һич авырттырмый юри тырный идең.

Кайвакыт урлап ашасаң син бәлешләр, сумсалар,
Һәм сине: «Ник урладың?» – дип орсалар йә суксалар, –

Шәфкатемнән мин җылап йөгрә идем тиз әнкәмә,
Ялварып: «Әнкәй, песигә сукма һәм, зинһар, тимә!»

Һай, гомерләр үтте китте, кайда китте ул заман?
Бу җиһанның дустны дусттан айруы бигрәк яман.

Булсын инде якты кабрең, бирсен Алла яхшы хәл,
Һәм кыяматтә мине күрсәң, мыраулап каршы ал!

## Эшкә өндәү

*(Плещеевтән)*

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
Аһ! оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.

Булса калдырмак берәү ушбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад.

Һәр олугълар эшләгәнлектән олугълыклар таба,
«Уйнады» дип бирмиләр ушбу җиһанда мәртәбә.

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкаддәс нәрсә – эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.

Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч
һәм бик җиңел.

## Иртә

Иртә. Дөнья җанлана,
Мәшрикъ ягы аллана,
Кояш чыгып, нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

Яктыра кала. Урамнар,
Кырлар, якын урманнар,
Таулар, багълар, бакчалар
Нурга гарык булганнар.

Торды халык, уянды:
Шау-шу һәрбер төшләрдә;
Көтү-көтү менмәктә
Күккә җитез кошлар да.

Шушы вакыт балалар
Мәктәп таба баралар;
Букчалары артында,
Алар гыйлем дәртендә.

## Иһтида

**1**

Әгәр булса «сөю» ләфзы кочаклау куллар арганчы,
Үбү булса әгәр чут-чут, ирен һәм бит кабарганчы, –

Гомер дә сөйгәнем юк һәм сөям дип әйтмәмен һич тә;
Сөюнең мәгънәсе, минчә, бигүк гали, бигүк нечкә.

Кешеләрчә сөюне белмәдем, хис итмәдем, асла;
Сөю идеалдыр ул, ягъни гарәпчә: максады әкъса.

Табындым, сәҗдә кыйлдым мин
сөйгән җанашның алдында,
Өмид иттем вә куркътым да, кызардым һәм оялдым да.

Миңа ул бер вә бар, көчле вә һәйбәтле санәм булды;
Аңар хәмдем, салатымны ирештергән каләм булды.

Мәхәббәттән эреп шәмдәй үзем, күңлемдәге гөлләр
Янып җиргә сыгылдылар, һавага очтылар көлләр.

**2**

Гарәп халкы кабул итмәстән әүвәл дине исламны,
Илаһ урнында тотканнар агач, таш, төрле әснамны.

Бераздан соң килеп хак дин, тәмам батыйль булып ялган,
Гарәпләрнең күзеннән дине ислам пәрдәне алган.

Алар бар үткән эшләргә пәйгамбәрдән оялганнар:
«Ничек соң без табындык потка?» –
дип хәйранга калганнар.

**3**

Килеп чыкты хәзер фикрем кояшы золмәт артыннан,
Түгел инде вакытлы, мәгънәсе юк хискә мин корбан.

Шөкер булсын, хәзер алдымда бер нурлы хәят инде,
Теге мәзкүр пот алдында табынганнан оят инде.

Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр,
сезгә мең ләгънәт!
Яшә, тугъры караш, төпле гакыл, меңнәр яшә, хезмәт!

## Читен хәл

Ни була тугъмак сыйратын кичмәсәм?
Бу ачы гомрем шәрабын эчмәсәм?!

Әйләнә бит, үтми, бетми гомре дә! –
Җәй килә утлар чәчеп, син кышласаң.

Ардым инде, кайда актык мәүкыйфем?
Җилкенәмен – бер басарга өч басам.

Каршыма чыкма, кояш, син, канлы тап!
Ак кәфендәй син җәелмә өсткә, таң!

Катле нәфситсәм, Ходайдан куркамын,
Ләкми чир, аурып та булмый, ичмасам!

## Кадер кич

*(Сурәи кадердән)*

Бу кадер кич елда бер кич – барча кичләр изгесе;
Сафланыр таптан бу кич мөэмин күңелләр көзгесе.

Сафланыр ул, пакьләнер, – бик зур Ходайның дәүләте;
Һәм төшәр ул көзгеләргә күк капугы шәүләсе.

Шул капугъдан күндерермез Тәңремезгә без теләк, –
Бер кадер кич Тәңре каршында мең айдан изгерәк.

Җон, мамыктай әйләнер җирдә бу кич әрвах вә рух;
Һәм фәрештә сафлары җирдә йөрер меңнәр гөруһ.

Ул мәлаикләр җыярлар тол, ятимнәр яшьләрен,
Барча көчсезләр, зәгыйфьләрнең аһын, каргышларын.

Күз яшеннән, төрле рәнҗештән ясап зур энҗеләр,
Ул мәлаик гарше-көрсине бизәр һәм энҗеләр.

Таң сызылганча йөрерләр, әйтмичә һичбер кәлям;
Тик диерләр: «Барча мөэмингә, мөселманга сәлям!»

## Сайфия

*(Иделдә сәяхәтем хатирәсе)*

Килсә байның ач халыкны күзгә-күз мыскылласы,
Яллый ул, әлбәт, пароход, ансы – байлар юргасы.

Ярда торган ач халыкка йөз дә бормый, туп-туры
Юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сайфиясе.

Бу тупаслыктан көлеп торса кояш, күктән карап,
Нурны каплый «эссе!» дип бай – кулда бар шәмсиясе!

Бай киенгән франт-шикларча халык тиресе белән,
Батсачы шунда үзе һәм аләте нәкълиясе.

Ул хәзер туктар сиңа, и ач авыл, мохтаҗ авыл!
Җимрек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе.

Җаннарым, күз нурларым, сез бу мәһабәтне күреп,
Җан ачып, «во как!» дисез, мәзлум мужиклар семьясы.

## Тәүбә вә истигъфар

*(Пушкиннән үзгәртелде)*

Йа Илаһым! Падишаһым! Бер дә чик юк иркеңә,
Әмритәсең син кызыкмаска кешенең милкенә.

Мин кызыкмыйм һич кешенең малы, милке, бәхтенә;
Кайда ул, хәтта кызыкмыйм падишаһлар тәхтенә.

Көнче күз салмыйм кешенең йорт-җиренә, нигзенә,
Бер дә янмый күзләрем атлар, сыер һәм үгзенә.

Һич кызыктырмый мине шәп фәйтуны һәм арбасы,
Әйдә тик сөрсен сафа! дим, иткәч ихсан Алласы!

Йа Ходай! Нишлим, әгәр күрсәм кешенең зәүҗәсен?
Торса ул яд иттереп җәннәт сарае раузасын?

Ул Зөләйхаләр вә Ләйләләр кеби булса матур?
Көнләшәм... (әстәгъфирулла!) йа Шәкүр вә йа Гафур!

Дөньядук нишләп ача ул сигез оҗмах капкасын?!
Ник тәнавелли гүзәл, тәмле, матур оҗмах ашын?

Ярлыка, мәүлам, мине, мин инде көнче күбәләк,
Ибне адәмме түзәр, җирдә әгәр күрсә мәләк?!

## Көзге җилләр

Яктырак йолдыз янадыр,
 төн кара булган саен;
Ядыма Тәңрем төшә,
 бәхтем кара булган саен.

*Русчадан*

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

– Иң сөекле эшче әүладым быел ач калды, – дип,
Изге, шәфкатьле анабыз – мәрхәмәтле җир җылый.

Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,
Бер телем икмәк, дип, анда назлы нечкә бил җылый!

Бер сынык юктан гына үлгән таза ирләр күреп,
Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый.

Тилмереп торса бу ачлар, безгә бәйрәмнән ни ямь?!
Мәркадендә чөнки Ибраһим вә Исмәгыйль җылый.

Көлсә монда тук вә ихлассыз халык тәкбирләре,
Һәр ишеткән жан җыларлык – андагы тәкбир җылый.

Көзге төн, ямьсез, караңгы... Өй түрендә җил җылый,
Җил – хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый!

## Золым

Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа иман таккан?
Тәзкирәңә мөслим диеп игълан таккан?
Кемнәр сине, намаз диеп, сәҗдә диеп,
Юкка тузанлы мәсҗедләрдә аунаткан?

Тагып сиңа иярченлек сәфаләтен,
Корал итеп йөретәләр җәһаләтең.
Гуаһлыклар бирәсең син, «әшһаде» дип,
Син ни белдең? Кемгә мәкъбүл шәһадәтең?

Мискин фәкыйрь, иркен сулыш та алмыйсың,
Аһ-ваһыннан һичбер вакыт бушанмыйсың;
Көчләү сине сарих золым иман белән,
Иртәгә ач үлмәм дип тә ышанмыйсың!

## Кечкенә музыкант

Уйга баткан, утырмакта шагыйрь язып,
Язадыр ул бар дөньяны онта язып;
Каләм белән кайчак чәчен актаргалый,
Чыгаргандай төрле уйлар баштан казып.

Яза шагыйрь, каләмене кулдан куймый,
Бер юл язып ташлый, тагын берне уйлый.
Шулай тыныч утырганда безнең шагыйрь,
Өй турында кемдер исә быргы уйный.

Тынычлыкны боза аның әче тавышы,
Килә аннан, бер тыңласаң, мәче тавышы,
Бер тыңласаң – чинау, бер тыңласаң –
Майламаган арба тәгәрмәче тавышы.

Китә кәйфе, шагыйрь тәмам хәйран кала:
Кайдан чыкты бер дә уйланмаган бәла?
Кычкыра ул ачу белән тәрәзәдән:
– Тиз кит, малай, өй турымда тавышлама!

Йөгреп качып китте тизүк шаян малай,
Беразга туктаган булды юрамалай.
Шагыйрь тагын ихлас белән эшен эшли,
Тавышлардан котылдым дип, әйа Ходай!

Җыеп торган чакта гына шагыйрь хәлен,
Ходай орган! быргы уйный башлый тагын.
Нишләргә дә белми шагыйрь, ачуыннан
Идәнгә ыргытып ташлый язганнарын.

Уйный быргы, һичбер вакыт туктап тормый,
Мескен шагыйрьнең күкрәген, җанын тырмый.
Шагыйрь инде нишләргә дә гаҗиз калгач,
Булмас, ахры, диде, бер-бер хәйлә кормый.

Кычкырды ул: «Килче монда, чибәр бала!
Йөгреп кил дә менә минем кулга кара:
Бирәмен мин быргың өчен унбиш тиен,
Акыллы син, шул быргыңны сатчы миңа».

## 1912

## Сабитнең укырга өйрәнүе

Сабит алты яшендә, инде гакълы башында;
Ялгыз, иркә бала ул әткәләре кашында.

Шуңа күрә шаян ул, бик күп уйный, наян ул;
Күңеллелек, көлкеләр таба әллә каян ул.

Фәһме үткен, ул зирәк, андый балалар сирәк;
Һәрбер әйберне сорый ул: бу ни нәрсә? ник кирәк?

Сабит сорый җентекләп, һәрнәрсәне бөртекләп,
Әти белән әнисе җавап бирә бик иплəп.

Бөркөн Сабит әткәсен күреп әйтә әйтәсен:
«Әти, миңа әлепби кайчан алып кайтасың?

Мине укырга өйрәт, миңа укырга кирәк;
Үзем укыйм мин китап, үзем сөйлим һәм көйләп».

Атасы хәйран булды, китапчыга йөгерде,
«Бүләк» атлы әлифба алып кайтты ул берне.

«Бер адым, – дип, – гыйлемгә» өйрәтә ул Сабиткә;
Салган Сабит ихласын, кош бәбкәседәй җимгә.

Монсы «әлиф», монсы «ба»,
                    бу хәреф «җим», монсы «та»,
Бусы «дал» хәрфе була, бу хәреф «зат», монсы «та».

Салган Сабит муенны, оныткан ул уенны;
Тыршып укый «Бүләк»не, белми көнне һәм төнне.

Әткәй алган китапны тапты Сабит бик татлы;
Тиздән белде бик яхшы: нинди хәреф ни атлы.

Беркөн чәй эчкән вакыт, укый Сабит шартлатып;
Әти белән әнисе торышалар шаккатып.

Укуы өзек аның, – балачарак баланың:
«Бу ә-лиф-ба – бүләге Харитонов бабаның».

Хәйран булды әнкәсе, гыйлем булгач бәбкәсе;
Чәй катында елмая куанычлы әткәсе.

Күрсәң иде әнкәсен: кочып алган бәбкәсен,
Үбә-үбә бихисап битен, күзен һәм кашын.

## Валлаһи

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!

Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
Җир яшел; кошлар да сайрый, валлаһи!

Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!

Аз гына бер җил исү берлән, үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

## Хөрмәтле Хөсәен ядкяре

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби.

Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма,
Күрмәмен дип уйлыймын бер якты йөз ул йөз кеби.

Көчле, көчсез, ярлы, бай булды һаман да бер аңар;
Һәр караштa ул иде чын «керпегеннән гөл тамар».

Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөҗдан белән;
Аз гына кер кунганын да кай җиреннән кем табар?

Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп,
Үткен акълы шул көрәшкә пакь көмештән юл булып.

Ул көрәште, язда елмайган кояш төсле бәләнд:
Карны-бозны ул ничек эртә көлеп һәм нур коеп.

Күрмәде гами, табигый, буш куыклар атмагач,
Һәм кәмиттә бер батыр да җирдә егълып ятмагач.

Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!

Янә бер хатирәм

Мин – кунакчыл бер җыручы, миндә – бар ярлы-гидай,
Ханәмә яшьләр килә, һәм сәүдәгәр, бай угълы бай.

Ул бәләнд мәрхүм дә килсә, мин сизә торган идем:
Күктән иңгән, ханәмә килгән шикелле тулган ай.

## Аң

Без Бишенче елны беркөнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән.

Эшкә ябшыр чак җитеп, ямьсез озын төн үткәнен
Күз ачып белдек без, үлчәп күктәге Чулпан белән.

Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел.

Шул сәбәпле дустны, дошманны дөрест фәркъ итмичә,
Күп саташтырдык рәзил шәйтанны чын инсан белән.

Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек, булсын кабул;

Җәбраил ачкай ул эшләргә сигез кат күккә юл.

Үтте инде, дустларым, ул үткән эш, ни булса ул;
Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын аң белән.

## Үтенеч

Яшь вакытта яшьнәдем, көчле вакытта күкрәдем;
Яшьнәмим дә, күкрәмим дә – утсыз инде күкрәгем!

Килде тоткынлык, түбәнләнде уемның куллары;
Хөр заман ак кул белән күкләрдә йолдыз чүпләдем.

Ак күгәрченне кулымнан алдылар, козгын биреп;
Ак кирәк, дип, пакь кирәк, дип, күпме күз яшь түкмәдем!..

Ул – түгел күңлем эшеннән, тик ялан кулның эше,
Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем.

## Бала оҗмахта

Мин хәзер оҗмах түрендә – бер матур хур иркәли;
Мин җуанмыймын, җылыймын, син түгелсең, дим, әни!

Ай төсендә нурлы гыйльманнар миңа ташлый тәти,
Егълыймын, алмыйм аларны, сез түгелсез, дим, әти!

## Дошманнар

Күп «җыланнар» сызгырып читтән карыйлар бәхтемә,
Борла-сырла, бәдбәхетләр, үрмәлиләр тәхтемә.

Аз кеби баскан бу золмәт тормышым йортын минем,
Түзмиләр бит бер генә яктан ачылган яктыма!

Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән;
Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.

Дөньядан туйдым, өмидем юк, алар күпсенсә дә;
Тик мин үлгәчтән, карагыз, типмәсеннәр нәгъшемә!

*

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна;
Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля.

Якты йөз берлән алам каршы авырлык, ауруын;
Чүпкә дә саймыйм йөрәккә кап-кара кан саулуын.

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем.

## Кичке теләк

Мин язам, шунда күрәм: лампам эчендә май кими;
Алда кәгазьгә ташыйлар – күңлемә уйлар сыймый.

Якты беткәнчә языйм, дип, сызгалыйм тиз-тиз генә,
Кәгазь өстендә кала тик кәкре-бөкре эз генә.

Нокталар да төртмимен, керсә ярар, дип, киртәгә –
Мин үзем сызганны бик яхшы таныйм, дип, иртәгә.

Күп тә үтмәстән, утым ялт-йолт итә һәм селкенә,
«Гөлт!» итеп актык нурын бер күрсәтә, аннан сүнә.

Нишлисең? Һәр якта золмәт. Ихтыярсыздан ятам;
Мин, ятып, яткан җиремдә төрле уйларга батам.

Мин, караңгылык эчендә уйланып яткан көйгә,
Нечкәреп күңлем, җылыйм да бер сүз әйтәм лампага:

«Ни бәхет! – дим, – иртәгә кич син тагын да янмасаң,
Бу ятыштан мин дә мәхшәр җитмичә кузгалмасам!»

## Ваксынмыйм

Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа,
Әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа:

– Бу заман шундый заман, – дип, – бу вакыт мондый вакыт,
Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.

Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вакътына,
Башны бөксәм – зур җинаятьтер олугъ җан хакына.

Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга, мәңгегә,
Мәңгелеккә – мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!

Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;
Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.

Вакътыны йөртер кешеләр ул заман миннән күреп,
Файдалансын шунда миннән сәгатен һәркем борып.

## Сагыныр вакытлар

Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, –
Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын.

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!

Юк гамең бернәрсәдән дә, барча эшләр ал да гөл;
Күк тә күк төсле зөбәрҗәт һәм дә баскан җир – ләгыль.

Очрамый юлда җиһанның кайгы-хәсрәт, аһына,
Тик бирәсең ул вакыт бәйгать табигать шаһына.

Һәр чәчәк – сеңлең, апаң; абзаң – үсеп торган агач;
Син сабыйдай нечкә аваз берлә сайрый сандугач.

Чәчмәгән җир күк – күңелнең һәр гүзәлгә бушлыгы,
Тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы!

Бар күңел хәдсез, хисапсыз мәрхәмәт, шәфкать тулы,
Санки күңлең җиргә күктән иңгүче рәхмәт юлы.

Бер теләнче керсә йортка, син бирәлсәң бер телем, –
Әй була җанга хозур! Шатлыктан әйләнми телең.

Кич белән кайчак укыйлар, тыңлыйсың төрле китап,
Кайсысы көйсез була һәм кайсысы көйле китап.

Бер кызык көйле китапның моңлы таушы тирбәтеп,
Күз йомылгач, ихтыярсыз йоклыйсың шундук ятып.

Йоклыйсың рәхәт кенә; төнлә уянсаң берзаман,
Як-ягың тып-тын – әле юк яктылык, таң атмаган.

Шул вакыт яшьләр күзеңдә: җан ачып, җан сызланып
Егълыйсың, Җан-Зөһрә берлән Җан-Таһирны кызганып.

## Авылда авырып яту

Мин әле аурыйм авылда, монда кайттым кыш көне;
Ял итә монда агайлар, җәйдә калган эш көне.

Сызганып мин дә агайлар берлә ялкаулык итәм;
Туйдым инде хәстәлектән, яз көтәм, саулык көтәм.

Язганым – кышның буранлы һәм караңгы уйлары,
Һәм дә хуш исле ипи, майлы бәрәңге уйлары.

И бәрәңге! Син, бәрәңге! Кил, бәрәңге, җан ашым;
Син генә тәмләртәсең бар ярлылар, байлар ашын.

Күп җәфа күрдең бу җиргә син килеп Америкадан,
Нишлисең, тәкъдир шулайдыр, халкыбыз шул бик надан.

## Әхлаксызлык

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

Тик хәзер, йөз сумны урлап килгүче угъры кеби,
Күз салабыз чын сүз әйтердән элек як-якка без.

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

## Буран

Тик кенә торганда капланды томанга бар һава;
Кар оча, кар себрелә, кар котрына һәм кар ява.

Кар бәрә йөзгә рәхимсез, күз ачып булмый карап;
Һәр кара нәрсә – бүре һәм һәр маяк булды карак.

Карны җиңгән күк, төшә җиргә тонык ай яктысы;
Ай да куркынган шикелле: бер сары, бер ак төсе.

Көн буе яткан иде, үлгән җылан күк, юл тыныч;
Чыкты соң кайдан адаштыргыч буран – бу куркыныч?

Әллә ычкынганмы баудан Каф тау арты җеннәре?
Йә тишелгәнме Ходайның бихисап зур мендәре?

Кар булып җирдә очамы ушбу мендәр җоннары?
Йөгрешеп җан аулый мәллә Каф тау арты җеннәре?

Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә,
Мин фәкыйрь михнәттә – гүя чарлагыннан бай көлә!

## Көтмәгәндә

Кар-томаннан көтмәгәндә килде чыкты Шүрәлем.
Дәшмимен. Тып-тын торам. Нишләр икән, дим, күрәлем.

Иң элек төртте озын бармакларны ул бүркемә;
Бармагы үтми аның, күрде, башымның күркенә.

Сузды шуннан соң кулын, биттән минем эзләп кытык;
Кайда ул көлмәк, кытыкланмак миңа – йөзләр чытык.

Муйныма сузды, кытыкlargмын дип, ул тырнакларын;
Мин шарыф берлән аны куйган идем чорнап калын.

Белде капшап соңра инде арканың да ул хәлен;
Җәйге күк күлмәк түгел шул: үтми бармак – тун калын.

Бик кирәкле эш кеби күкрәкләремне капшады:
Ул кытык эзләп маташты; булмагачтын – ташлады.

Мин бөтенләй бер кәбестә: бар кием ун кат минем,
Бу киемнәр йөклеген икърар итәрлек ат минем.

Ул, алып кулларны күкрәктән, минем билдән тота;
Һич тә бер шәйтан чишалмаслык минем билдә пута.

Ул, табан астын кытыклыйм дип, аякка кул ата;
Бармагын сизми аның, әлбәттә, җансыз ул ката.

– Әмма бәйләнчек тә син урманда, кырда, Шүрәле!
Йөрмә монда булмаганга, бар, эшеңне күр әле!

Син түгел, тәнгә тиялми китте инде күп суык,
Төлке эчле тун җибәрде күп суыкларны куып.

Кертмәгәч тәнгә, суык абзаң миңа дошман әле,
Миннән үч алмак өчен эшкә буран кушкан әле.

Шул сүземнән соң томанга батты, гаиб булды ул,
«Чи-и-и!» итеп бер әллә кайда, бик еракта көлде ул.

Ул көлә, һәм көлке эзләүдә үтә кич, иртәсе;
Кем кыеп әйтсен аңар сүз, ул – табигать иркәсе!

## Көлке түгел

Көлке булса кайвакыт шигъриятемнең кыйссасы,
Анда бар бер җанлы хәсрәт, канлы ләгънәт хиссасы.

Уйлый торгач, мин үземнең җан ачымнан да көләм,
Чөнки инде кайгыралмыйм, кайгырып арган булам.

Хәсрәтем – әллә минем нурлы кабыклы бер җылан?
Куркынырда җылмаялар, ни бәхетледер җылан!

Юк, түгел, һәрхәлдә дә, хәсрәт язу рәүшем шулай,
– Нәрсәгә шиблит киясең? –
Мин димен: кәүшем шулай!

## Сабыйлар җыруы

Каз канатлары ак булыр,
Ир канатлары ат булыр.
Сабыйларның канатланыр вакъты
Мәктәпләрдә укыр чак булыр.

## Монафикъка

*(Сюжет русчадан)*

Җиһанның эссесен, салкын, бозын күрдем, карын күрдем;
Ниләр күрсә бөтен үксез – барын күрдем, барын күрдем.

Хәзер шатлык, уен-көлке телим инде җитәрлек күп;
Сабый чакта гариб башым җәфа чикте, җитәр, бик күп.

Сөрәм, котрып, тәмам тилреп, фани дөнья сафасын мин;
Кире алсын явыз тәкъдир үзе салган хафасын, дим.

Теләп шөһрәт вә хөрмәт, күккә бер чаклар очу күрдем,
Һава юктан көчем беткәч, тагын җиргә төшү күрдем.

Аяклымын, канатлымын – чабыш күрдем, менү күрдем,
Сөбатлымын, хәятлымын: үземдә бер голү күрдем.

Шаярма, дошманым, пешкән, җитешкән пәһлеван берлән;
Монафикъ! яхшы саклан! Аударым беркөн аяң берлән!

## Ни кирәк тагы?

*(Экспромт)*

Алкаларың якты бриллиант ич, –
Җанкисәгем, ни кирәк тагы?
Һәрнәрсәдән миңа син кыйбат ич! –
Җанкисәгем, ни кирәк тагы?

Син теләк ич миңа, син салат ич, –
Җанкисәгем, ни кирәк тагы?
Син хәят ич миңа, син мәмат ич, –
Җаным, бәгърем, ни кирәк тагы?

## Мәхәббәт шәрхе

Мин: «Мәхәббәтсез», – дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә:
Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә.

Тугъры килгән урны чүплеккә, тиреслеккә аның:
Каплап алган төрле шакшы, төрле пислек һәрьягын.

Шунда кыткылдый әтәч, мыркылдый шунда дуңгызы;
Шундый хурлыкта, хәкарәттә мәхәббәт йолдызы.

Йоклый йолдыз шул түбәнлектә, озын төшләр күреп,
Һәр төшенә бакчалар, гөлләр, гүзәл исләр кереп.

## Мөнтәкыйд

*(Кыйтга)*

Күп сөйләндем. Яхшы инде, мөнәкъкыйдләр сукмәсә,
Берсе барлык язганымны читкә себреп түкмәсә.

Ул кавемнән булмыйдыр тәхрирчедән һичкем тыныч,
Берсе бар, дустым минем, һәрбер сүзе үткен кылыч:

Җил тегермәнен күрә дә: «Аһ, суы юк!» – дип куя,
Су тегермәнен күрә дә: «Пар, буы юк!» – дип куя.

Ул тота ат койрыгын да: «Бу – озын сач!» – дип куя,
«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ!» – дип куя.

Ул сукачыны күрә дә: «Җир боза бит!» – дип куя,
«Шундый зур эшкә каләм әһле түзә бит!» – дип куя.

Ул күрә куй койрыгын да: «Нинди шешкән!» – дип куя,
«Рус табибкә бу татарлар нинди дошман!» – дип куя.

## Интикадка мөтәгалликъ

Булса ялган, тик кәгазьләрдән ясалган бер чәчәк, –
Билгеле, үз өстенә яңгыр явардан куркачак.

Чөнки яңгырда җебеп беткәч вә киткәч төсләре,
Һичберәүнең чәчәккә инде китмәс исләре.

Куркъмый яңгырдан, әгәр булса табигый, чын чәчәк,
Чөнки ул яхшы белә: яңгыр аны яхшыртачак.

Ушбуның күк, куркыталмый чын талантны интикад:

Нык үзенә игътимады һәм сүзенә – игътикад.

Тик китә кайчакта кәйфең, хакимең булса ишәк,
Бер татарга ят, мәхәббәтсез күсәк һәм килмешәк!

## Казан вә Казан арты

И Казан шәһре, торасың тауда зур шәмдәл кеби,
Мәсҗедең, чиркәүләрең, һәр часларың шәмнәр кеби.

Син, үзеңне чорнаган һәрбер өязгә нур чәчеп,
Бик мәһабәтле торасың, барчага юл күрсәтеп.

Нур ала синнән бөтен як: Чистополь, Спас, Тәтеш
Һәм Чабаксарга, Мамадышларга Чар, Малмыж катыш.

Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:
Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.

«Үз төбенә төшми, – ди, – шәм-лампаның һичбер нуры», –
Шул мәкаль монда дөрес шул, ах, аны җен оргыры!

## Яңгыр

*(Русчадан)*

Былчыракта яңгыр артыннан балалар йөгрешә,
Кычкыралар: «Җиргә, – дип, –
алтын төшә! алтын төшә!»

«Шауламагыз, и балалар! Без җыярбыз барчасын,
Тиз ул алтыннарны амбарга төярбез барчасын.

Тик җыярбыз юл буе шыгрым тулы йөкләр көе,
Бар келәтләр туп-тулы хуш исле орлыклар көе!»

## Татар яшьләре

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый, мәгърифәт, хикмәт белән

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.
Мондый күрнеш сөйнеченнән инде мин алдан беләм:

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гаувaслары.
Өсттә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары.
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек, –
Без аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!

## Өч хакыйкать

*(Майковтан)*

Бар иде әүвәл заман бер Бай кеше,
Күп ашап тулган биек таудай эче.

Берзаман аулак урамнан барса Бай,
Әллә ни чыр-чыррр килә, – Чыпчык бугай.

Чыпчык ул, Чыпчык! Менә очты хәзер,
Ул очып Бай өстенүк төште хәзер.

Ул чырылдап кунды Байның бүркенә,
Чын-чын илтердән генә баш күркенә.

Кошчыгым чиксез кыю, чыр-чыррр килә,
«Нинди куркъмас кош!» – ди, абзый селкенә.

Абзыйның һәрбер көрәктән зур кулы,
Тотты Чыпчыкны, сузып кул, берьюлы.

Шул вакыт Чыпчык сөйләргә башлады,
Сүз сөйли, чыр-чыррр итүне ташлады.

Инде Чыпчыкта хәзер Адәм теле,
Хам белән Яфәс, тагын да Сам теле.

Абзыйга ул ушбу сүзләрне сөйли
(Кош, ирексез, дикъкатен Байның били):

«Мин сиңа, абзый, булырмын файдалы,
Сәүдәгәргә андый файда кайдәле?!

Тик мине, абзый, син ит әүвәл азат,
Шуннары байрак булырсың һәм дә шат.

Син азат иткәч, башымны, чөнки мин
Файдасы күп өч дөрест сүзне сөйлим.

Өч дөрест сүз ул сиңа бик файдалы,
Сәүдәгәргә андый файда кайдәле?!»

«Яхшы, яхшы, тиз булырсың син азат,
Эш алай булгачтын, итмәм мин азап».

Чыпчык әйтә: «Өч дөрест сүз шул була:
Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, җыла.

Һичвакыт алма көчең җитмәслек эш,
Хәл җитәрлек, булдырырдайга тырыш.

Бик ышанма һәр сөйләнгән сүзгә дә,
Күп таянмас бул үзеңнән үзгәгә».

Тыңлагач, Бай әйтә: «Моннан файда юк,
Андый буш сүз кемдә юк һәм кайда юк.

Сүзләрең тормый синең тыңлауга да,

Йөрми торган акча нәрсә сәүдәдә!»

Ушбу сүздән кош бераз хәсрәтләнә,
Бай учыннан башлый ул сүзгә янә:

«Үткән эш кайтмый» дигән сүзнең, җылап,
Мәгънәсен әйтим, колак сал яхшылап:

Бер кабып куйсаң биш, ун, йөз мең белән,
Син җылап чыкма, җә эчмә төн белән.

«Алма көч җитмәслек эш»тән шул морад:
Кермә Мәскәүгә, «бирә» дип, син ерак.

Хирсы берлән тәңкә артыннан куып,
Азмы калганнар тиен кулдан шуып.

«Төрле сүзләргә ышанмаска» кушам,
Чөнки һәркем үз уенча – зур ишан.

Дәгъвасы: мин күп беләм, алдан беләм;
Эчләре тулган хата, ялган белән.

Кемдер әйткән: «Күктәге торна өчен
Күп очырганнар кулында бар кошын».

«Сүзләрең иске. Шулай да бул азат,
Бар, югал күздән, сине итмим газап!»

Тукталыштан абзый шул чакта туеп,
Китте юлдан, кулларын артка куеп.

Тиз-тиз атлый күпкә Бай өстендә эш,
Тик оча, калмый аның өстендә кош.

Абзыйның ул җә колагыннан үтә,
Ул ягыннан җә бу ягыннан үтә.

Абзыйның бәрлеп китә дә борнына,
Шунда булган бер якын йортка куна.

Абзый әйтә: «Мин азат иттем сине;
Нәрсә бу? Мыскыл итәмсең син мине?»

«Синдиләрне ап-ачык, шәрран яра,
Һич зарар юк, күпме кылсаң мәсхәрә.

Эзләмим читтән мисал мин, син менә,
Бәрфараз булса бик аз фәһмең генә,

Булмага мөмкин идең бит бай кеше,
Сәүдәгәрләрнең күгендә ай кеше.

Әмма вакътың үтте тыңлап әкиятем,
Тыңлаганга, билгеле, күп «рәхмәт»ем.

Син мине тоттың. Беләмсең, шул чагын
Тиз генә ярсаң иде син корсагым,

Күрер идең зур асылташ ятканын,

Мәңге байтырга кәфил шул тапканың.

Бер дә ялгансыз, күкәйдән зур таш ул,
Дөньяда юк, булса да тик бер таш ул!

Син үләр чакта бу байлыкка батып,
Тик гакыл юктан карап калдың катып».

Мондый сүздән абзыйның үзгәрде төс,
Ул песи күк булды әйтелгән «прес!»

Алга, артка атлый алмый ул кыеп,
Һәм баса никтер аяклар да кыек.

Аптырый, ботка суга, «ах» дип куя,
«Ах, җүләр мин, ах, мин ахмак!» – дип куя.

Шунда да уйлап таба бер хәйләне, –
Хәйләле дөнья, диләр, бит файдалы.

Ләктереп булмас микән, дип, бер тагын,
Бай чәчәргә башлый юк сүз борчагын.

Ул килә кошка таба җылшып кына,
Алдалап тотмаммы дип, тыршып кына.

Йөртә, урнында тоталмый күзләрен
Һәм үзенчә башлый хәйлә сүзләрен:

«И кошым, син мескенем, син Чыпчыгым,
Мин сөйлим, тыңла сүземнең чып-чынын.

Мин карыйм һәм дә күрәм: кош халкы сез,
Валлаһи, дим, мин сиңайтим, жалкы сез...

Йорт-нигезсез, анда оч һәм монда оч,
Шәпмени, җә, бу чегәннәрчә тормыш?

Җәй көнендә – анда яхшы, ичмасам;
Куркыныч бит, кышны сезчә кышласаң.

Ул кара көзнең кыраулы кырлары!
Чиркәнеч һәм вак, суык яңгырлары!

Кыш тагын да: кар, яман салкын, буран!
Очмыйлар кошлар өшүдән куркудан.

Әмма йортларда минем соң улмыни?!
Анда бар: ни-нәрсәне күңлең тели.

Мич ягабыз, булса салкын, эсситеп,
Җәй көнеме дип торырсың, ис китеп.

Һич исәп юк, бездә бик мул аш та су,
Һәр заман күрнеп тора артып ташу.

Син очып йөргәнче, кошчык, «прррр» да «прррр»!
Ташла иске тормышыңны – бездә тор».

Билгеле, кош алдавын Байның белә,
Абзыйдан ул каһкаһә берлән көлә:

«Абзый! Абзый! Булмаган син, пешмәгән,
Корсагың үскән, ә гакълың үсмәгән.

Дәгъвалыйсың, сүзгә шәп тә телгә шәп;
Эш гакылга килсә, нәкъ син бер ишәк.

«Үткән эш кайтмый» дигәнне аңладың,
Син мине тоттың да саклый алмадың.

Син җылыйсың, һәм дә күңлең кайгыра,
«Үткән эш кайтмый, үкен син, үл, җыла!»

Һәрвакыт чиксез пошар инде эчең,
Хәсрәтеңнән, бәлки, ташларсың эшең.

Һәм хәзер «алма көчең җитмәслек эш».
Мин тотылмыйм – хәйләлә син һәм җылыш.

Сездәйләргә сезчә: «Чыпчык баш», – диләр,
Әмма бездә сездән артык баш, миләр.

Мин: «Ышанма төрле юк-барга», – дидем,
Син минем юк әкиятемгә баш идең.

Син түгел адәм, ышандың кошка да,
Инде ләкмәм җәйгә дә һәм кышка да...

Аңладыңмы? Өч хакыйкать шул иде,
Һәр өче мәкъбуль иде, мәгъкуль иде.

Соң, җүләр, азрак кына уйлап кара:
Ул минем эчтә асылташлар кая!

Җитмәсә, ул таш күкәйдән зур тагын,
Ул сыярлыкмы минем соң корсагым?

Син үзең учлап тотып тордың мине,
Иң-буемны үлчәдең, күрдең мине:

Бер күкәй хәтле бөтен гәүдәм дә юк,
Бәс, синең хәтле җүләр адәм дә юк!»

Сүкте Чыпчыкны, төкерде җиргә Бай,
Көлкегә калганга хурланды бугай.

Бай бу эшне әйтмәде һичкемгә дә,
Ачмады серне хатынга, иргә дә.

Булган эшне чәчми йөрде ул һаман,
Торды яшьреп нәкъ егерме ел тәмам.

Тик фәкать беркөнне «башка ис тигәч»,
Азрак эчкәч, башка киткәчтән «пирәш», –

Кемгәдер ул иске серне итте фаш,
Бәлки, шагыйрь шуннан иткән икътибас.

**1913**

## Шиһаб хәзрәт

Һәрбер имам бездә койрык булган чакта,
Койрык сүзе безгә бойрык булган чакта,
– Фәлән сәләф фәлән әйткән,
фәлән бул, – дип,
Җаһил мулла әмер бойрып торган чакта, –

Чыкты, ахры, бездән дә бер бөтен кеше,
Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше;
Татарда да гыйрфан уты кабынганны
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.

Кирәк булса, әйтеп бирәм: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһаб хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.

Ул итсә дә хәдис, аятьне күп нәкыль,
Булып бетми аның гакълы нәкыльгә кол;
Инсан дигән шәрәфле бер мәхлукта ул
Бар дип белә хаким гакыл вә хөр гакыл.

Дәлил итә «Тәзәккәрү!» аятьләрен,
Раушан итә шул аятьнең һәрьякларын;
«Тәфәккәрү!» аятьләрен таяк итә
Тик белгүче муллаларга тамакларын.

Аңлангачтын Коръәндәге бик күп серләр,
Үз-үзеңнән агаралар дини керләр;
Бу эшләргә Шиһаб хәзрәт сәбәп, диеп,
Даһи кулын үбә башлый күп мөнкирләр.

– Кемнән алдык дин фикрендә истикъляльне?
Кем ташытты ушбу бәхет, бу икъбальне?
Ничек өздек «уйлауда да» коллык җебен? –
«Хәзрәт»тән ул безгә мирас булып калды.

Чыкты, әлбәт, бу даһигә сәфил дошман;
Чыккан дошман мәгълүб булып чыкты эштән.
Олугълыкта, өстенлектә Шиһаб хәзрәт
Этләр буе җиталмаслык җиргә кичкән.

Бер җан белән тиздән милләт итә бәйрәм,
Шәрафәтләп, туган көнне бу мөхтәрәм;
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтне
Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм!

## Йокы алдыннан

*(Русчадан мокътәбәс)*

Гафу әйлә, кичер мине, Ходам җаным,
Бик еш була кәҗәләнеп җылауларым;
Кайсы чакта артык шаян булып китеп,
Берчак юктан гына ямансылауларым.

Кичрелсәче, Тәңрем, бәгърем әти, әни,
Дәү әнием, апайларым, бабай, әби;
Хозурында гәүһәр яшем түгеп телим,
Кабул әйлә, Тәңрем, әле мин бик «нәни».

Йокымда да күрсәтмәгел яман төшләр
(Аннан куркып уянгалыйм һаман кичләр);
Иртә белән мин торганда, матур булып,
Гөрләп торсын шытыр-шытыр янган мичләр.

Һәм бер эшне әнкәемнең иснә төшер,
Дисен аңар бер фәрештәң: «Коймак пешер!»
Иртә белән коймак ашап чәй эчкәчтән,
Тәңрем, сиңа кыйлырмын мин меңләп шөкер.

Иртәгә көн матур булсын һәм бик аяз,
Бакчабызда төрле кошлар бирсен аваз;
Шаян энем курчакларга тимәсен лә! –
Бигрәк монсын изге ләүхелмәхфузга яз!

## Суык

**1**

Рус мәүлүде үтеп китте, көннәр суык,
Колакларда, борыннарда өрлә куык;
Җылы мичсез кибетләрдә сатучылар
Малын сата, бии-бии кулын уып.
Байлар кигән тиен толып, төлке толып,
Үз фикеренчә, Печән базар күрке булып;
Куллар сузу, ялангачлык, ертык җилән
Күрнә аңар кызык булып, көлке булып.
Хулиганнар груһлана казенкага,
Суык чөнки – сызлый арка һәм җилкә дә;
Ушбу халык, кабак ничек ачылгач та,
Бик нык суга гөнаһы юк бутылкага, –
Диеп аңар: «Эчеңдәге суың чыгар,
Аның белән безне җылыт, безне сугар;
Эчтән безгә бишмәт киерт, чикмән киерт,
Көчле хәмер! Синең кулда зур ихтыяр».
Шәкерт белән школьниклар тиз-тиз атлый,
Йөгрә алар, колакларын саклый-саклый;
Дошман шәкерт, школьниклар арасында
Бу хәл – суык мәҗбүр иткән иттифакъ, ди.

**2**

Юлга чыксаң – җилләр каршы, туры була,
Буран чыкса – адаштыргыч юлы була;
Кинәт кенә җиккән атың туктап кала,
Җаның курка: карак очрый, бүре була.
«Монда кара, явыз, усал, мәлгунь бүре!
Тамагыңа күсәк белән лом кергере;
Мужикларның тырма теше кеби тешең
«Мәгыйшәтче» мие мислендә чергере!

Нигә соң син мискин мәҗбүр мужикларны
Талавыңда белалмыйсың хәд-чикләрне?
Мужик әллә сиңа азык булып туып,
Җирән атын сиңа булсын дип җиккәнме?!»

**3**
Суык инде; Кабан күле чынлап катты:
Юргаларга башлар инде байлар аты;
Көн юргала, төн юргала, тик юргала, –
Узалмассың «акыллы баш» Ишморатны.
Әүкатлене тешли алмый салкын, суык,
Черек күлдә, берсен-берсен куып-куып,
Җегет белән кызлар йөри шаркылдашып,
Боз өстендә тимераяк берлән шуып.

**4**
Никтер кичә озак йөрдем урамда мин,
Гаҗиз булдым эчем-тышым туңганга мин;
Җылныр өчен берәү белән сугышыйм, димен,
Юлда торып, кеше сайлыйм сугарга мин.
Күрдем шунда: берәү бара таза гына,
Өсте-башы чибәр генә, яңа гына;
Читкә генә карап барган чагы иде,
Мин «чалт!» итеп менеп төштем яңагына.
Сиздем шунда: тәнем җылнып китте, кызып,
Дөп! дөп! итә мине сыйлап төшкән йозрык;
Явыз тагын артык җылтып куймасын дип,
Без бәндәгез бик тиз генә торып «сыздык».
Читкә киткәч, гайрәтләнәм мин абзыйга:
«Тукта әле, бирермен, – дим, – мин аузыңа!»
Тагы килеп абзам берне бирмәсен дип,
Атлыйм үзем артка һаман аз-аз гына.

**5**
Рус кардәшләр бигрәк каты кыйлды бәйрәм,
Бик күп семья башы эчеп улды әрәм;
Былтыр, хәер, безнең кайсы бәйрәмдәдер,
Татарлар да үлде эчеп берән-сәрән.
Эчә халык – суык дип тә, бәйрәм дип тә,
Эчә халык – хәләл дип тә, хәрам дип тә;
«Кытайский әфлисуннар яшьнектә», – дип,
«Эчми үткән яшьлек гомре әрәм», – дип тә.

Халык җыры

Кытайский әфлисун
Килә, диләр, яшьнектә;
Картайгачдин үкенерсең,
Типтереп кал яшьлектә!

## Хәстә хәле

Көн туа. Һәр көнне хикмәт, мәгънәдән буш эш күрәм;
Күз йомалмыйм төн буе, йомсам – коточкыч төш күрәм.

Юк янымда чын кеше, булганда да – мин чит күрәм;
Белмәдем капшап, фәкать һәр йөздә кәгазь бит күрәм.

Бетте иман, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәткә тәмам;
Бәйле корбанлык кеби, алда кызыл кан, ит күрәм.

Бар хәятым салкынынннан туңды җан, катты күңел;
Һәр ягында бар җиһанның зәмһәрирдән чик күрәм.

Кышта очкан күбәләк төсле гүзәл кызлар миңа;
«Ник йөриләр?» – дим, кирәксез бер чуарлык дип күрәм.

Җиргә нык басмыйм – аяк астымда йомшаклык күрәм;
И үлем! мин синдә бер хәсрәт вә бер шатлык күрәм.

Акмый тышка мәгънәләр – кипкән күңелнең чишмәсе;
Калган урнында һәлакәт чокры, баткаклык күрәм.

Юк нәҗат, фикрем чөерсәм дә үземнән үзгәгә;
Козгын – ислам гәүдәсендә, кәгъбәсендә пот күрәм.

Тик болай бер аурумынмы? Әллә Обломов тамы?
Көн саен йөз сулса сулсын, җанда ник кытлык күрәм?!

Ауру җанның бишмәте-тәнне дәваның төрлесе
Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм.

Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым;
Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм!

## Даһигә

Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн;
Киттең эзләп син аны яктыртмага идеал утын.

Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син,
Чын сөбатлә алга бардың, бакмый уңга-сулга син.

Мин әле хәйран һаман да, белмәдем ни булганын;
Нәрсәгә артка карыйсың, утка калгач бер адым?

Ялтырау күрдеңме артта? Ут түгел ул – алтын ул;
Юк мөкаддәс нур да анда, юк җылылык – салкын ул.

Изге юлны һәрвакыт алдап шулай кыскарта ул,
Син сатылмассыңмы дип, фикрең үзенә тарта ул.

Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса – Алла ул!

## Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре

### 1

Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «Мөнафис» нам канат.
Җыйла халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.

### 2

Һәр күренгәндә шимальдән ак болыт,
Без көтеп тордык өмидләр, шат булып, –

Дип аны: «Ул падишаһ һәм тәхтедер»,
Дип: «Шушында без татарның бәхтедер»,
Дип: «Гариб башларга энҗүләр төшәр.
Мәңге михнәт, мәңге рәнҗүләр кичәр».

**3**

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Бергә тормыш, бергәлек чиктән ашып,
Без шаярыштык, вакытлар алмашып.

**4**

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.
Без сугышта юлбарыстан көчлебез.
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!

**5**

Падишаһ, бу көнге парлак бәйрәмең
Котлыйдыр йөзләрчә мильон адәмең.
Җыйла халкың ак канатың астына,
Ихтирамән затыңа, зур нәслеңә, –
Төшсен әзрәк, дип, күләнкә безгә дә,
Бәлки, кипмәсме бу яшь, дип, күздә дә.
Һәрвакыт: «Юкмы мөнафис?» – сүзләре
Тилмерә эзләп җиңеллек күзләре.
Бер сүзең – мең канлы коллар гафведер,
Бер ишарәң – мең җинаять мәхведер.
Зур «Мөнафис» берлә җанлансын халык,
Бар моңын, барлык зарын өстән салып.

*

Кардан ак, сөттән дә аграк, актан ак
Падишаһ ачты «Мөнафис» нам канат.
Җыйла халкы шул канатның астына,
Тулды өч йөз ел Романов нәсленә.

## Кыйтга

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә чөнки ак ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

## Тәфсирме? Тәрҗемәме?

Һәр заман кем насры берлән фәтхе килсә Алланың,
Һич тә бер көч туктаталмый, манигы булмый аның.

Син күрерсең тугъры юл тапканны күп төркем халык,
Хәмд-ү-тәсбих өннәре берлән гөрелдәр урталык.

Мәккәдә ачты бүген якты иманга баб Ходай,
Ярлыкау эстә, шөкер ит, тәүбә кыйл, тәүваб Ходай!

## Шөһрәт

Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт шөһрәткә син;
Бик төренмә, иртәгүк артык булыр чүпрәккә син.

Тапмасам шөһрәт, сизәлмәсләр димә күңлемдәген,
Зур тәрәзә бар дип аңла дөньяга күкрәктә син.

## Толстой сүзләре

Һичвакыт булмый пәшиман садә тордым дип кеше;
Кан җылый күп чакта фәүкыльгадә тордым дип кеше.

Җан тынычланды димә, булганга малда артыгың,
Артык ул – алганга намәгълүм гарибләр актыгын.

Эстәмимсең буй бөгәргә? Ирнәсең эшләргә эш?
Йә телән син, йә фәкыйрь кардәшне көчләргә кереш!

Тәмле булганга гаҗәпләнмә бу байлар ашлары,
Күп вакыт борчы, тозы – мискин гидайлар яшьләре.

## Мөхәрриргә

*(Кыйтга)*

И мөхәррир! Кайсына биргән яшен күз кибриа!
И мосаувир! Кемгә биргән пакь вә чын сүз кибриа!

Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмәле!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!

Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилях,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.

Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.

Алты ел торды чупансыз, айрылышты яшь көтү;

Карт бүре күк, бары корган айрым-айрым бер оя.

«Ул Гомәрдән курка шәйтаннар» дигән төсле Рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя...

## Буш вакыт

Безгә ят-чит телдәге изге фикерне тәрҗемә
Биш вакытта биш намаз күк керде инде фарзыма.

Бу «Толстой сүзләре»н дә хасладым буш вакътыма,
Күп вакыт моңлы күңелнең саф, аяз, хуш вакътына.

Әйтмәгез: «Ул – иске сүз, «Гайнел-гыйлем»дә күп иде»,
Әйтсәгез, сездән сорыйм мин: бездә нәрсә юк иде?!

## Казан

Ут, төтен, фабрик-завод берлә һаман кайный Казан;
Имгәтеп ташлап савын, сау эшчеләр сайлый Казан.

# Чәчмә әсәрләр

## Мәкаләләр

## Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?

Һәртөрле мөхәррирләр вә ярты мөхәррирләр милләтемез үлгән вә яки йоклаган дип язалар. Вакыйгъда безнең милләт үлгән үкме, әллә йоклаган гынамы? Әгәр милләтне йоклаган дисәк, дөнья көпчәгенең бу кадәр дөбердәп әйләнүенә, вә башка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлануларына уанырга кирәк иде.

Чөнки йокының, әлбәттә, әлбәттә, бер чиге булырга кирәк. Бәр тәкъдир милләтемез үлгән булса, без, үлгән милләтнең башы очында бер кәгазь кисәге булган гәзитәләр шытырдатып, аны уята алырмызмы? Болай булгач, безнең гәзитәләр укымакымыз үлгән милләт, рәхмәтуллаһи галәйһи, рухына ясин шәриф укуга гына охшап калмасмы? Әллә милләтнең йокысы Гозәер пәйгамбәр йокысы кеби микән? Әллә Мәксәлмина, Мәслина, Дөбернуш, Шаднуш, Кәфәштатыюшлар йокысы кеби микән? Соң ничек икән?

Минем уемча, болай булырга кирәк: борын заманда безнең милләт үзенең иптәшләре вә аркадашлары булган башка милләтләр илә фәкыйрь генә, тыныч кына, күңелсез генә яшәгән. Берничә гасырлар безнең милләт алар илә казандаш һәм чәйдәш булып, барчасы бергә, ачлы-туклы гына булса да, тыныч кына, тату гына гомер иткәннәр. Шулай тыныч кына торганда, ни хикмәттәндер башка милләтләр, һәрберсе бер Сөләйман мөлкен алып, үзләренә җилләрне, парларны, утларны, һаваларны хезмәтче иткәннәр; һәртөрле җан-җанвар, кош-кортларны мөсәххәр иткәннәр, хәтта тәхеткә утырып, күкләрдә очып, су төпләрендә балыклар илә бергә йөри башлаганнар. Безнең милләт, мискин, шул вакытта йоклаганмы, ни эшләгәндер, мин анысын белмим, ләкин безнең милләт баягы иптәшләренең кисәктән генә болай ук югары китүләренә тәкать тота алмаган, дәрхаль һушы китеп егылган; «Сагълүк» китабынча әйтсәм, мөгаммә галәйһи булган. Менә шул ятудан безнең милләт һаман да ятадыр.

Соң инде аны ничек һушына китерик?

Бу тугърыда минем фикре касыйрем болай дип әйтә: без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифак сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын; шундин соң бу вәгазьләрне сөйлик: «И бичара милләт, син ул иптәшләреңнән курыкма. Аларның хәленә исең китмәсен; әгәр алар эшләгән-

не эшләсәң, алар күргәнне күрсәң, алар белгәнне белсәң, син дә алар дәрәҗәсенә менә аласың; Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һичкемгә хас түгелдер, һәм бу галәм – галәмел-әсбабтыр. Һәм дә ялан сөйләмәси мөхаль вә мәмнугъ булган мөхбире садыйк әфәндемез дә: «Кеше тырышса, табар», – боермышлардыр. Тырышкан вә тырмашкан вакытларыңда синең бабаларың булган Багдад вә Әндәлес әһалисе бик каты тәрәкъкый иттеләр. Аларны күргәндә, башка милләтләр, синең кеби, һушлары китеп егылалар иде...»

Менә бу сүзләр илә милләтне җуатып, милләтнең һушы китеп, гакылсыз ятканда, милләтне ашаган, кабыргаларын тишкән оятсыз ак башлы каргаларны, кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле Бохара козгыннарыны куып җибәрик. Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвештә ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырыйк, чәчләрен аягүрә торгызыйк; борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен; каргаларны муеныннан кысып, борынгы ашаганнарын карылдатып чыгарсын; шулай бит! Андин соң Бохара чапаны эченә төрелгән хәйләкәр төлкеләрне чапан җиңеннән өстерәп, көзге каршысына китерик; көзгегә каршы авызларын каерып ачыйк та милләткә көзгедән канлы авызларын күрсәтик; милләт күрсен, ашаганнарына инансын, икенче мәртәбә та кыямәт алданмасын.

Бәс, безнең милләт үлмәгән дә, йокламаган да, һушы гына киткән. Мәзкүр рәвешләр илә һушына китерсәк, дуст кем, дошман кем – милләт үзе аерыр.

## Хиссияте миллия

Көз җитте. Мәдрәсәләремездә укулар башлана. Уку дигәч тә, чын уку дип уйланмасын. Безнең бәхетсез мәдрәсәләремез, һаман шул укытучы битлеген киеп, култык астына китаплар кыстырган булып, 25 җирдән аш ашагач, абыстай янына корсагын күтәреп кайтып җиту авыр булганлыктан гына мәдрәсәгә туктап, бераз хәл җыяр өчен генә бер чирек сәгать 5–6 кабат мендәр өстендә утырып, бераз хәл җыйгач чыгып китә торган мөдәррисләр кул астыннан һәмишә чыкмагандыр.

Шәкертләремез, хөррият кояшы туып дөньяны яктырткач, борынгы истибдад караңгылыгында кеше төсле булып күренгән мөдәррисләрнең кем икәнлекләрен таныдылар. Шул мөдәррисләрнең, укытамыз дигән булып, шәкертләрне һич чыга алмаслык наданлык урманына кертеп адаштырганнарын аңладылар. Һәм шәкертләрнең тәхсиле кәмалəт вә гыйлемнән максудлары бер такым сыра мичкәсе булган байларның этләре хөкемендә бер хайваннары булу булмаенча, азат, сәрбәст, һәр байдан бай, үзенә-үзе һәр падишаһтан артык падишаһ була алулары икәнлеген төшенделәр.

Инде ул шәкертләрнең шул аңлауларын вә үзләренең хөр икәнлекләрен белү хисләрен күңелләреннән кисеп ташланмаган тәкъдирдә, алар һаман бөтен көчләре, тешләре вә тырнаклары илә үзләрен шул залим мөдәррисләрнең вә надан, зур корсаклы байларның кулларыннан коткарырга тырышачаклардыр. Шәкертләр бу көннән алып үзләренең милләт эчендә иң кадерле, иң дәрәҗәле бер затлар икәнлекләрен аңлап вә аңлатып, үзләренең иң түбән, теләнчедән дә түбән бер мискиннәр түгеллекләрен күрсәтәчәкләрдер. Инде шәкертләр бер саран байның күз карашларын тәгъкыйб итеп: «Безгә ничек карар икән, мәрхәмәтле карармы икән, мәрхәмәтсез карармы икән, алафранка киенгәнемне күрсә, ашка чакырырмы икән?» – дип калтырап тормаячаклардыр.

Алар, бу хурлыкларны күргәнче, нинди кәсеп итсәләр дә, үзләрен үзләре кул көчләре берлә туйдырачаклардыр.

Милләт образауный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мөрәббиләргә вә мөрәббияләргә, чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятьләренә мохтаҗ. Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәлҗаэсез, фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәкъкыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаҗ.

Бу әйтелгәннәр булмаганда безнең тормышымыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз-тавышсыз, рәхәтсез булачактыр. Болардан башка безнең гомеремез бер дә бәйрәмсез, гомерлек мәшгулият яки бер дә җәйге кояшсыз мәңгелек көз көне төсле үтәчәктер.

Яшьләргә, баягы хәзрәтләрнең мендәр өстендә ял иткәннәренә генә канәгатьләнмәенчә, уку кирәк. Бу аларның иң мөкатдәс, иң беренче вазифаларыдыр.

Бу – безнең һәртөрле чалмалы бурлаклар тырнагыннан азат булуымызга вә бюрократия золымыннан, башка милләтләр илә берлектә, безнең дә котылуымызга иң беренче вә иң тугры юлдыр.

Укымак – дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак – фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак – үз

янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак – үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр – истикъбальләр тугърысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак – хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү угърында ташламак, димәктер. Укымак – бүгенге дустлардан киләчәктәге кара көннәр өчен аерылмак, димәктер. Укымак – үзеңне һәрнәрсәне белергә, вә һәр максудка ирешергә, вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. Укымак – «иҗтиһад мөнкарыйз» кеби сүзләрдән ха-ха-ха илә көлеп, гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер.

Укымак – утыз ел мәдрәсәдә ятып, бер татар баеның эштән чыккан кызы илә бер аулак бүлмәгә кереп яту, соңра шул байның бер асрау малае булып тору дигән сүз түгелдер. «Укымак» ләфзы астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр. Укымак – халыкның бәлешен ашап, канын эчеп, үзеңне симертеп, ел саен бер бай кызы үтереп яки аерып, хайванлык итеп яту дигән сүз түгелдер.

Беләмен ки, безнең шәкертләремез бу мәгънәләрнең барчасын аңлаганнардыр, алар шуңгар күрә үзләрен теләнче ясап чыгара торган, тугрысын әйткәндә, теләнче фабрикасы булган мәдрәсәләренә ләгънәт укып чыгып киткәннәрдер.

Шәкертләремезнең бу хәрәкәтеннән милләт әллә нинди зур өмидләр вә сәгадәтләр көтсә дә – урынлыдыр; яшьләремезне кайда укытырга вә ничек укытырга икәнен белсәк, милләт өчен җаннарын корбан итүчеләр вә үзләренең бил бәйләп керешкән юлларыннан, әллә нинди куркынычлар, әллә нинди хәвеф-хәтәрләр очраса да, кайтмый торганнар һәм шулай булырга сәляхиятьлеләр дә анчак яшьләремездер.

Без, шәкертләргә, үземезгә кирәк кадәре динемезне вә әдәбиятымызны аңлагач, вакыт кичермичә, хөкүмәтнең реальныйларына вә гимназия казаннарына кереп пешеп, кеше булып чыгарга кирәк. Русларның үз балалары кайсы мәктәпләрдә укыса, безгә дә шуларның итәкләренә ябышып керергә тырышырга тиештер.

Хәзер дә милләткә чынлап, риясыз, нифаксыз хезмәт итүчеләр шул мин теләгән юл илә укыган яшьләремездер.

Без яшьләремезне Бохарага җибәрсәк – ишәк, Истамбулга җибәрсәк – полицейский вә шпион булып кайтачаклары моңгарчы кайтканнары илә сабит вә мөдәлләлдер.

Әле Мәкәрҗә базарында да җыелышлар, шураи өммәтләр булып үтте. «Мөсадәмәи әфкярдән барыйкаи хакыйкать зоһур идәр» дигән шикелле, шул җыелышларыннан берәр төрле файда чыгып китсә, шаять, без шәкертләргә дә гомеремездә, элек дәфга уларак, чын гыйлем илә сәламләшеп, гыйлемнең алдына тез чүгеп, кулларын үбеп, моңарчы гыйлем дип, гыйлемгә табан-табанга зыйд вә кире нәрсәләр берлән баш катырып йөргәнемез өчен гафу үтенер көннәр җитәр.

Тырышыңыз, карендәшләр! Шәкертләр, тырышыңыз! Муллаларның мендәр өстендә корсак шиңдереп утыруларына гына канәгать итмәгез. Бөтен өмидемез, бөтен риҗаэ вә илтимасымыз анчак сезгә гаиддер.

## Җәмгыяте хәйрия

Адәмнәр диңгезенең тормыш дулкыннары арасында бер йомычка төсле, җил кайда иссә, шунда таба селкенеп йөргән кешеләрнең һәммәсе дә йомшак кына вә сөйкемле генә бер бәхет җиле илә бер сәламәтлек җәзирәсенә чыгулары мөмкин түгелдер.

Бик күп кешеләр шул мохтаҗлык, фәкыйрьлек дулкыннары арасында күмелеп, һич төпсез-нисез тирән диңгез астына төшеп киткән яки, диңгездә агып йөргәндә, ярлары гаять тә текә вә биек һәм шома булган бер коры җиргә очрап, шул ярдан менәм дип тырмашып, тырнаклары каерылып бетеп, актыкта ике дошман арасында аптырап калып изелгәндер.

Заманымызның мәдәният вә образованиесе тудырган мохтаҗлык туфаны арасында һичбер кешенең ялгыз башына гомер итүе мөмкин булмыйдыр.

Һәр мохтаҗлыкка каршы – тырышу вә эш эшләү; күкрәгең киереп кенә рәхәт вә тыныч, азат торып булмыйдыр.

Аңсыздан йә бер авыру яки башка бер бәла-каза ирешеп, адәмнең хәятын әллә ничәгә бөгә вә сындырадыр.

Һич кеше һичбер кешенең ярдәм соравына колак салмыйдыр; гүя кыямәт көнендәге кеби, һәр кеше үз нәфсе илән генә мәшгульдер.

Һәркемнән бернәрсә сорасаң: «Ул минем үземә кирәк, сине кызгансам, үзем кызганычка калам»,– дип җавап аласың.

Фәкыйрьлек, мохтаҗлык бик авыр. Аны җиңеләйтүче юк. Вакыйган, мәдәният мәркәзләре һәммәсе үзенә бертөрле шатлык илә шат, бертөрле күңеллелек илә күңелләләнеп торадыр.

Мәдәнияттә торучыларның бер кыйсьме мәдәниятлек ләтафәте вә матурлыгы илә кәефләнеп тора-

дыр, ләкин бер кыйсьме мәдәниятнең зәһәре илә агулангандыр. Менә шул сәфаләт зәһәренең актык тамчысына кадәр эчеп, фикрән вә бәдәнән авыру, вә хәстә булган бер кеше шәфкатьле вә хәерхаһ бер кулның үзен сөюенә, вә башыннан мәрхәмәт илә сыйпавына мөзаһһәр булмаса, билгеле инде, ул кешенең китә торган җире мискинлек вә хурлык зинданы яки юклык вә бетмәк мәзарыдыр.

Бер дә шиксез, бу бичараларның бәхетсез хәлләреннән ушбу күз алдымыздагы һәйьәте бәшәрия, ягъни инсаннар җыены тоткын ителәдер.

Бу күз яшьләренә, бу гөнаһсыз адәмнәрнең хурлыклы хәлләренең барчасына шул һәйьәте иҗтимагыяләрнең һиммәтсезлеге вә инсаниятсезлеге сәбәптер.

Мөтәрәккъый милләтләр бу мәсьүлиятне, бу тоткынлыкны күптән сизгәннәр. Алар, һич булмаса, үз милләттәшләренең аянычлы хәлләрен бөтенләй бетерү булмаса да, бераз җиңеләйтү өчен, җәмгыяте хәйрияләр ясап, милләт эчендәге байларның лотеф вә гыйнаятьләренә махсус бер хөрмәтле акча сандыгы хәзерләгәннәрдер.

Инсаният хисләренең иң киң мәгънәсе илә сахәи хәергә чыккан бу җәмгыяте хәйрияләр шул җәмгыяте хәйрияне ясаган милләтнең өмид кәгъбәләредер.

Хурлык, фәкыйрьлек тавышы шунда барып туктар, ярдәм сорау фөрьядлары шул урында кабул ителер.

Авыру түшәгеннән яңа гына баш күтәргән, ләкин мәгыйшәт дәрте берлән күңеле тырналган бер балалар атасына эш табып бирмәк яки эш тапканчы аның мохтаҗлыгыны үтәп тормак һиммәтле кешеләр өчен тәгърифе мөмкин түгел бер рухани рәхәт вә ләззәттер.

Ул нинди гали күңелләрдер ки, бу мәгънәви зәвык вә ләззәтне сизеп, үзләренең тырышып тапкан байлыкларыннан бер ярдәм өлеше аерып чыгаралар. Бу затлар нинди гали затлардыр ки, милләтләрнең шөкер вә сәнасыннан ясалган бер хөрмәтле көрсигә утырып торалар.

Менә инсан дип, шул рәвешчә үзенең тырышып тапкан яки бәхетле бер очрау (тәсадеф) аркасында тапкан бер байлыгыннан үзенең милләтенең фөкара вә әйтамә сыйнфына да өлеш чыгарган кешеләргә әйтәләр.

Безнең татар халкы моңа кадәр дә бөтенләй садакасыз-нисез тормадылар, муллаларга, мөәзиннәргә, шәкертләргә, мәдрәсәләргә, ишаннарга, Мәдинә габдессәттарларына вә гайре урыннарга бер дә кызганмыйча, садакалар сачтылар. Алар мәсҗед алдындагы теләнчеләрне дә күздән ташламадылар. Әлхасыйль, кулында хәерче капчыгы яки маңлаенда теләнчелек вывескасы, ягъни чалмасы булган һәр кешегә тиешле-тиешсез акча тараттылар.

Татарлар Коръәннең «Тәсаддык» аятеннән баш тарталар дип әйтер хәл юк. Әлхәмделиллаһи, баш тартмыйлар, ләкин үзләренең гаять наданлыкларыннан, хөрмәтле садакаларыннан күп-күп ялганчыларга өлеш чыгаралар иде.

Шуның өчен аларга, һәр милләттә булдыгы кеби, садакаларны бер җиргә җыеп, җәмгыяте хәйрия ясау лөзүме күптән хис ителмәктә иде. Һәр кеше аерым-аерым үзенең милләттәшләренә ярдәм итә иде һәм моны сөя-сөя эшли иде.

Ләкин шул һәр кешенең биргән акчаларын бер тәртип астына алып, бер җиргә җыеп, тагы да файдалырак рәвештә сарыф ителү күзгә алынмый иде.

Шөкер, мең шөкер булсын ки, мөселманлыкның өстенә салынган бу рәтсезлек, бу беспорядканы моннан соңра тәхәммел итәргә түземнәре калмаган берничә гайрәтле интеллигентлар вә сәүдәгәрләр чыгып, «Уральск мөселманнары җәмгыяте хәйриясе» исеме илә бер хәйрат сандыгы ясадылар.

Моның шикелле хәерле вә киләчәгемез өчен өмидле бер изге эш үзен мөселманмын дип йөргән һәрбер татарны мыек астыннан гына бер куаныч илә көлдергәне шикелле, таланган, ертылган киемле, саргайган йөзле бичара бер теләнченең: «Абзый, бер генә тиен бир инде! Әрвахлар хакы өчен»,– дип кычкырган кызганычлы тавышы да вөҗданлы, йомшак күңелле бер мөселманның күңелен җәрәхәтләми калдыруы мөмкин түгелдер.

Менә шул җан кискеч, аянычлы тавышларны моннан соң мөселманнар арасыннан югалтыр өчен, бер шәфкатьле ана шикелле, мәйданга чыгып, җәмгыяте хәйрия ясаган кардәшләремезне әүвәлән инсаният яки, хаслап әйткәндә, миллият намына тәбрик итәмез.

Шул кешеләр шикелле һиммәтле затларның меңнәр яшәвен теләгәнемез кеби, җәмгыяте хәйрия төсле мөкатдәс бер эшкә каршы торучы монафикъларның кадалуын яки тәүфикъка килүләрен телимез.

Әгәр җәмгыяте хәйрия безнең дуст вә дошманнарымыз арасында теләнеп йөреп, дошманнарымызны куандырган вә дустларымызның күз яшьләрен чыгарткан теләнчеләрнең бетүе өчен чынлап тырышса, мөселманнарның йөзенә сөйләп-язып бетерә алмаслык бер аклык китергән буладыр.

Җәмгыяте хәйрия, Алланың гыйнаяте илә капчыклы теләнчеләрне бетергән шикелле, мәдрәсә вә дарелфөнүн исемен пычратып, ала каргалар төсле, үләксә артыннан йөгерүче, бер бай мәсҗедтә колак какса да: «Мине ашка чакыра, ахрысы: кулын югары күтәрде», – дип, егыла-сөртенә йөгергән чалмалы теләнчеләрне – шәкертләрне дә бетерсә, татарлык исемемезгә ягылган караны тәмамән кырып, юып ташлаган буладыр.

Тота белүчеләр булса, милләтнең акчасы мәктәп вә мәдрәсәләргә дә, шәкертләргә дә, гәзитәләргә

дә – һәммәсенә җитәчәктер. Милләт акчасы ялгыз милләт файдасы өчендер.

Милләт акчасының ханәкаһ конюшнясендәге ялкау сыерларның авызына гына агып торуы дәвам итсә, без бетәчәкбез. Әгәр милләт акчасы илә шул ук милләтнең кирәкләрен карасак, бик тиз алга да китәчәкбез.

Бинаән галәйһи һәрничек җәмгыяте хәйриянең суммасын күбәйтергә, моннан соңра садакаларның урынсыз җирләргә акмавына һиммәт итәргә кирәк.

## Тәнкыйть – кирәкле шәйдер

Кеше бер әсәрне болай өсттән генә укып чыккан вакытта, шул әсәрнең иң яхшы вә мәгънәле сәтырлары илә мәгънәсез вә биһүдә сәтырларыны тәфрикъ итә алмыйдыр. Әгәр уртадан бер мөнтәкыйд чыгып, шул ук әсәрне иләктән сөзеп чыгарып, яхшысын бер якка, яманын бер якка аерып: «Иштә мөхәррирнең бу сәтырлары шулкадәр гүзәл вә лөзүмледер», яки: «Бу сәтырларны бу сәбәпкә бинаән язмамыш улса, гүзәл улыр иде», яки: «Бу әсәр бу сәбәпкә бинаән асла матбугат галәменә чыкмамыш исә, гүзәл улыр иде», – җөмләләре кеби сүзләр илә зарифанә вә битарафанә тәнкыйть итсә, табигыйдер ки, бу мөнтәкыйднең тәнкыйте дә әсәрне укымыш адәмнәрнең нәзарына тәсадеф итәчәктер. Бу тәнкыйтьне укыдыктан соңра, әсәрне моталәга итмеш адәм, никадәр хәйран улып тормыш итсә дә, фикере тугры бер мәркәзгә барачактыр.

Тәнкыйть, безем заманыбыз кеби, китаплар, рисаләләр, гәзитәләр, журналлар тагълар кадәр өелеп бармакта улан бер заманда, кирәкле генә дәгел, ләбеддә минһедер.

Һәр көн арамызда төрле-төрле яңа исемнәрдә рисалә вә китаплар таралмактадыр, һәрнәрсәнең дә хосуле хәдденнән тәҗавез итсә, табигый, зарарлыдыр. Шуңа күрә безнең дә үз тәнкыйтемез цензорыннан үтмичә, «тисә – тиенгә, тимәсә – ботакка» кабиленнән таралмакта улан әсәрләремез эчендә садәдил кариине кирам өчен зарарлылары улуы да ихтималдыр. Мәдрәсәдәге бер максады аслыйга восул өчен генә укылмакта улан нәхү, мантыйк гыйлемнәрен шәкертләремез, васита дия генә ышанмак җиренә, әллә ничәшәр еллар илә чуалып, шул гыйлемнәрнең үзләрен максады аслый дия белеп хәраб булдыклары кеби, безнең дә әдәбият галәмемезгә дә, зыялану вә нурлануны шул тагълар кадәр матбугъ рисаләләр өелүдән гыйбарәт дип белеп, максады аслыйдан мәхрүм калу куркусы бардыр.

Васитаны максудтан тәфрикъ итә алмау, кирәк кем генә өчен булса да, хәвефле бер бәладер. Атлар, арбалар, фәйтуннар инсанның хәрәкәтенә васитадыр. Өйләр, киемнәр дә һава үзгәрүдән сакланыр өчен генә васитадыр. Яхшы аш вә эчемлекләр дә инсанның бәдәненә хезмәтен вә сәламәтен саклар өчен генә файдалы булмаклә анчак васитадыр.

Әгәр инсан шул яхшы ат, яхшы арба вә фәйтун, һәм яхшы толып, вә туннарга, яхшы йортларга хуҗа булуның үзен яхшылык вә дөньяда торудан асыл максат дип белсә, бу вакытта ул нәрсәләр файдалы булу гына шулай торсын, бәлки, зарарлыдыр.

Китап вә рисаләләр таратуның да, нур вә мәгълүмат тарату җиренә, бәгъзан җәһел вә сүи әхлак тарату тарафы да бардыр. Китаплар вә журналлар таратыр өчен, заманымызда, әлбәттә, наширләргә, эшләренә көллән муаффәкъ булыр өчен, көллиятле акчаларга ихтыяҗ бардыр.

Китап, гәзитә вә журналларны соратучы халкымызның күбесе кара халык булганга, аларның да ләззәтләнә вә тәм таба торган нәрсәләре түбән вә тупас нәрсәләрдер. Әгәр гәзитә вә журналлар таратылуларында гүзәл нәтиҗәләргә муаффәкъ булыйк дисәләр, билгеле, аларга да түбән дәрәҗәле, тупас нәрсәләр язып, «мөхтәрәм мөштәриләр»нең тәләззезләренчә эш күрергә лазем буладыр. Мин үземезнең арамызда бер журнал, бер гәзитә beләмен ки, болар, тәмам-тәмам шул «мөхтәрәм мөштәриләре»нең теләүләренчә, әдәп таптап, яхшук акчаланып вә файдаланып торалар. Бәлки, алар үзләренчә милләткә файда итәмез ди торганнардыр: анысы табигый инде. Менә инде шул матбугатта аз булса да хөрриятне сүи истигъмаль итмәсәк, бәлки, эшемез алга китәр иде.

Безнең, мәсәлән, дарелголүмнән яңа укып чыккан бер яшемезгә иң ибтида уларак нинди әсәрләрне укымак кирәк? Моны сайлый белергә, тәнкыйть булмаса, мөмкин түгелдер. Чөнки аңар яхшы рисалә табу бөтенләй борчак басуы өстендә бер билгеләнгән борчакны табу кадәр читендер. Ул әгәр, мәсәлән, ун ел кадәр ни эләкте, шуны укып, зиһененә төрле-төрле рәвештә язылган файдасыз рисаләләрнең мәфһүмнәрен урынлаштырса, мондин соң аңар бер файдалы рисалә очраса да, ул аның мәгънәсен йә бөтенләй аңламас, йә һичнәрсәгә дә татбикъ итә алмас. Әгәр бер рисаләне укып та, тиз генә тәнкыйтен дә табып алса, аңар бик уңай буладыр.

Ләкин тәнкыйть итүченең дә кем очрады, шул булуы тагы ярамыйдыр. Мөнтәкыйд булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы матлубтыр. Юк исә бер гаразы шәхси илә дә тәнкыйть итүчеләр күптер.

Нә исә, тәнкыйть – кирәкле вә лөзүмле бер шәйдер. Әфкяре гомуми берлә уйнарга ярамый.

## Халык әдәбияты

### Язучыдан

Бу, хәзерге кулыңызга алдыгыңыз «Халык әдәбияты» моннан аз гына мөкаддәм мәйданга куелган «Халык моңнары» исемендәге рисаләмә тәмамән багълыдыр.

Бу ике рисалә бер-берсенә тәгаллекътә берсе ачкыч вә икенчесе йозак кабиленнәндерләр.

Шул сәбәпле бу рисаләләрнең берсен алып укырга тәнәззел боерган мөхтәрәм кариэләремнән икенчесен дә әлдә итмәкләрене үтенер идем.

«Халык әдәбияты» намендәге бу рисаләм Казанда «Шәрык клубы»нда, ушбу сәнә 15 апрельдә укыдыгым (итлакъ җаиз исә) лекциямнең мәзмуненнән гыйбарәттер.

Лекциядә җыруларымызның берничәсе генә, анчак лазем урында мисал өчен алынганнары гына зикер ителде. Анда, әлбәттә, «Халык моңнары» нам бөтен бер мәҗмуга тәшкил иткән җырларымызның барчасын укып чыгарга тугъры килмәде.

Менә хәзер җырларымыз хакында байтак мөляхәзәне җәмигъ булган «Халык әдәбияты»ны укыганда, шактый күп мөнтәхәб җырларымызны эченә алган «Халык моңнары»ны да алга ачып кую файдасыз булмаса кирәк дия, сүзне бетердем.

*Г.Тукаев*

### Игътизар

Халык әдәбияты хакында хәзер сөйләячәгем лекция сымак нәрсәм өчен мин алдан озак тәхкыйкат вә тәдкыйкат илә хәзерләнмәгән идем.

Көннәрдә бер көн бер иптәшемә, уйнап кына: «Мин халык әдәбияты тугърысында лекция укыйм»,– дип әйткән идем. Ул, шуңар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән, дип, могтәбәр гәзитәләремезнең берсенә язып та өлгергән.

Мин, ул иптәшем яныннан чыкканда, уйнап әйттем, ышанып калма тагы, дип әйтергә оныткanмын.

Менә шулай итеп, яңлыш, уеннан уймак чыгып куйгандай булып, мин, теге гәзитә хәбәрен тәкзибкә-фәләнгә керешмичә, чынлап та халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне сөйләргә җәсарәт итәм.

Бу эш миңа көтелмәгәндә генә килеп чыккан булганга, җырулар вә көйләремез тугърысында тарихи вә әсаслы мәгълүмат бирә алмыйм.

Безнең җырланмакта булган көйләремезнең һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган булса да, мәгаттәэссеф, аларның сәбәпләрен вә тарихларын тикшерергә кулымда материал булмады.

Җырларымыз вә көйләремезнең тарихын вә мәнбәгъләрен тикшерергә берзаман махсус хезмәт куярмын да, шаять, халыкка шул тугърыда әсаслырак мәгълүмат бирермен дигән өмидем бар әле.

Хәзер сөйләгән сүзләремнән исә бер-бер төрле тирән мәгълүмат көтүчеләр булса, бик каты алданырлар шикелле тоела.

Озын вә кыска көйләремез тугърысында халык авызында төрле сүзләр сөйләнә. Аның барчасын да җыеп язу шактый озак заман эстидер. Шулай да сүз арасында халык авызындагы сүзләрнең үземә ишетелгән кадәресен бераз язып китәргә ярый.

«Тәфкилев» көе

Борынгы Тәфкилев фамилияле бер мөфтинең урысча укый торган бик матур бер кызы француз җегетенә гашыйк була. Кыз француз җегетен, ата-анасы күрмәгән чакта, өенә дә китерә.

Бервакыт шулай, мөфти хәзрәт өендә кыз белән җегет күрешеп торган чагында, өстләренә мөфти хәзрәт үзе килеп керә.

Кыз, аптырауда калып, үзенең мәгъшукын зур пыяла шкаф эченә яшерә.

Алай да мөфти хәзрәт җегетне күрә. Таягын алып, җегетне кыйнарга килә башлый.

Җегет исә, тиз генә шкафны ватып чыгып, тәрәзәдән сикереп кача.

Шкафны ватканда, җегетнең битенә вә кулына пыялалар керә. Идәнгә җәелгән хәтфә паласлар өстенә каннар тама...

Минем исемдә шулкадәр генә калган.

Аннан соң җегет белән кыз арасында нинди маҗаралар булгандыр, миңа мәгълүм түгел. Ләкин «Тәфкилев» көенең моңлылыгына караганда, җегет белән кыз арасында мотлак бер фаҗига булгандыр дип, фикергә килә.

«Ашказар» көе

Гыйшык вә мәхәббәт сәбәпле кияүгә барган бер башкорт түрәсе кызының кияве Ашказар дигән суның буена ау ауларга китеп, шунда суга батып үлә. Моның вафат хәбәре мәгъшукасына ишетелгәч, ул бик кайгыра. Хәсрәтен ничек изһар итәргә дә аптырый.

Беркөнне бу кыз, башкорт кызлары арасындагы барча җырчы кызларны чакырып, алардан вафат булган кияве хатирәсенә бик моңлы бер көй чыгаруларын үтенә. Әгәр дә күңеленә муафикъ бер моңлы көй чыгара алсалар, аларга әллә ничә баш төяләр һәдия итмәкче була.

Кызлар төрлечә көйләр чыгарып карыйлар, ләкин берсе дә түрә кызының күңеленә ошамыйлар.

Бу җырчы кызлардан бернәрсә дә чыкмагач, түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге «Ашказар» көен җырлап җибәрә. Җырчы кызлар хәйран калалар.

«Сак-Сок» көе

«Сак-Сок» бәете вә көенең нидән чыкканлыгы Сак-Сокның үз бәетләреннән дә күренә.

Бәетләрдән аңлашылдыгына караганда, бер ана үзенең ике баласын: «Сез Сак-Сок булсагыз иде», – дип каргый. Шул ук минутта балалар, Сак-Сок дигән ике кош сурәтенә кереп, кара урманга очып китәләр.

Балаларны каргаганда, аталары өйдә булмый бугай. Ул, кайткач: «Балалар кайда?» – дип, хатынынnan сорый. Хатын: «Каргап очырдым», – ди дә үкереп җылый башлый. Ире шелтә итә.

Балалар исә искән җилләр аркылы гына аталарына үзләренең хәсрәтле сәламнәрен җибәреп торалар.

Менә бу – шуннан чыккан көй.

«Касимский Ибырай»

Бу – Касыйм шәһәрендәге чамадан тыш мөсриф бер байга чыгарылган көй. Касимский Ибырай гуләйт итә-итә дә актык тунын да сата. Ахыр гомерендә бик хосранлы рәвештә вафат була.

«Касимский Ибырай» көе шул сәбәптән чыга.

«Җизнәкәй»

Бу көй бер кияүнең балдызына гашыйк булуыннан чыга. Кияү, хилафе шәргы рәвештә, балдызын да никахлап алып, ике кардәшне бергә җыймакчы була.

– Агач башы базыктыр,  
Балдыз алу языктыр;  
– Язык булса ни миңа,  
Язык казык башына...–

җыруы шушыңар дәлаләт итә.

«Башмак» көе

Бу «Башмак» көе дә мөфти вә мирзаларымыздан зур фамилияле бер кешегә чыгарылган көй булырга кирәк.

Ләкин тәгъйин кемгә вә ни хосуста чыгарылганын, мәгаттәәссеф, тәфтиш итә алмадым.

Бу көй, зан идәрсәм, берзаман хөкүмәт тарафыннан җырланырга мәнгы да ителгән иде бугай.

Көйләр тарихы хакында бар белгәнем шушы кадәр генә булганга, хәзер мин аннан күчәм дә максудым булган халык әдәбиятына киләм. Шул тугърыда булган мөляхәзәләремне сөйләмәкче булам.

**Халык әдәбияты**

Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип инша итүче шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтеләдер.

Бу нәүгы әдәбият, әле дөньяда язу сәнгате булмаган чактук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан – атага, атадан балага ишетелеп, буыннан буынга калып килгән әдәбияттыр. Әгәр дә «су», «чиләк», «бүрек», «арба» дип әйткән сүзләрне иң әүвәл кем чыгарган дигән сөальгә җавап биреп булмаса, «Аклы ситса күлмәгеңне кигәнеңне күрмәдем» җыруын яки «Эт симерсә, иясен тешләр» мәкален иң элек кем чыгарган дигән сөальгә дә җавап биреп булмыйдыр.

Халык әдәбияты, бер дә кәгазьгә язылмаса да, буыннан буынга ишетелеп, халык күңелендә бер дә онытылмый торадыр.

Халык әдәбияты китапка керсә дә, язылса да, анчак бер, халык җырларын вә әдәбиятын җыеп, китап

рәвешендә таратуны теләүче бер кеше тарафыннан гына кертеләдер. Шул кеше үзе ишеткән вә тапкан кадәр җыр вә масалларны язып нәшер итәдер.

Халык әдәбиятының ничек булганын күрсәтер өчен, мин монда халык авызындагы кыска гына бер хикәяне алып яздым.

Бер авыл кешесе, төн буе ашасын өчен, урманга атын җибәрә икән. Иртә берлән эшкә җигәргә дип атны алырга барса, ни күзе берлән күрсен: атын, шапырма тиргә баткан, төн буе әллә ничә йөз чакрымнарны бер дә туктамастан чапкан кеби, тәмам хәлдән тайган көе таба. Бу кеше атны алып кайтып, ничек кирәк алай эшләтә дә, кич булгач, тагы шул ук урманга җибәрә. Иртә берлән урманга барса, атны тагын шулай эштән чыккан килеш таба. Атның бу хәлгә төшүенә һичбер сәбәп тапмый гаҗәпләнә. Бичара кеше, атының шулай газапланып арыгаюыннан тәмам гаҗиз калгач, авылда бер ак сакаллы карттан бу тугрыда сораша башлый. Карт бу кешегә киңәш бирә: «Син, – ди, – бүген кич атыңны урманга җибәргәндә, аркасына сумала ябыштырып җибәр», – ди. Теге кеше карт кушканча эшли.

Кеше иртә берлән атны алырга барыйм дип капкасыннан чыкса, күрә ки, ат үзе кайтып килә. Өстенә ат аркасындагы сумалага чытырдап ябышып каткан Шүрәле атланган. Беленә ки, атны төн буена чаптырып газаплаучы шушы Шүрәле икән. Дәрхаль авыл халкын чакырып, Шүрәлене ат өстеннән алалар. Шүрәлене күсәкләр белән бик каты кыйныйлар. Шүрәле үлми. Авыл халкы, бу усал Шүрәлене ни рәвешчә, ничек итеп үтерү тугърысында күп киңәштән соңра, аны базга салып, өстенә керосин сибеп, яндырып үтерергә карар бирәләр һәм шулай эшлиләр. Шүрәле, бичара, яна, кычкыра, фөрьяд итә, ахырында янып көл була. Ләкин җаны чykканчыга кадәр бу авылны каргый: «Ярабби, бу авыл 30 өйдән артмаса иде»,– ди.

Менә Казан артында бер авыл бар, ул авылның салына башлаганына йөз елдан артык бер заман булса да, һаман да 25–30 өйдән артмый. Теге Шүрәлене яндыручы авыл – шушы авыл, имеш. Бу авылга Шүрәленең үләр алдындагы каргышы төшкән, имеш.

Менә бу кеби хикәяләр халык хикәяте, халык әдәбияты дип аталалар. Чөнки моны сөйләүче кем? Гайнетдинме? Сәйфетдинме? Котбетдинме? – асла мәгълүм түгел. Бу – фәкать гомумхалык хыялы, халык хикәясе.

Ихтар: әгәр дә шушындый ук хикәя бер-бер мөхәррир вә шагыйрь тарафыннан бизәкләп вә матурлап язылса, инде ул «Халык әдәбияты»лыктан чыга. Бу җөмләдән Пушкинненң «Алтын балык» вә «Алтын этәч» кеби хикәяләрен санарга мөмкин. Мондый хикәяләрнең башта халык авызында сөйләнүе дә вә халык рухынча язылуы да аның «Халык әдәбияты»лыктан чыгуына манигъ була алмый. Чөнки, бая әйткәнемезчә, «Халык әдәбияты» дип, язылган вә мәзбут нәрсәләргә әйтелмичә, авыздан авызга сөйләнеп йөртелгән нәрсәләргә генә әйтеләдер.

Бу булды халык хыял вә хикәясенең бер нәмүнәсе. Яхшы.

Менә сезгә халык шигырьләреннән дә бер нәмүнә:

Минем сөеп җиккән атым
Кара берлән тимеркүк;
Сагынганда айга карыйм –
Ай да ялгыз минем күк.

Менә бу – шигырь, һәм дә хәкыйкатән шигырь. Ләкин кем моны инша иткән? Һич тә билгеле түгел. Моны инша итүче, сөйгәненең йөзен искә төшереп, айга карый да, соңра бик матур рәвештә, шагыйранә генә: «Ай да ялгыз минем күк!» – дип куя.

Сүз башында әйткәнемезчә, менә мондый шигырьләргә «Халык җырлары» дип әйтелә. Бу җыруның әүвәлендәге ике юлы, ягъни «Минем сөеп җиккән атым кара берлән тимеркүк» дигән сүзләренең соңгы ике юлга бик ябышуы булмаса да, соңгы «Сагынганда айга карыйм – ай да ялгыз минем күк» дигән мәгънәле вә хисле сүзләрнең астына нинди истигъдадлы шагыйрь дә кул куюдан тартынмас дип уйлыйм.

Аннан соң безнең халыкта җырлар өчен әүвәлге ике юлның күп вакытта бер дә әһәмияте дә булмыйдыр. Әүвәлге ике юл анчак, скрипкә уйнаганда, бер кәррә кыл тартып кую кабиленнән генә бер нәрсәдер.

Мәсәлән, гавамнан берәү җырлый: «Сандугачлар су ташый, кайда икән су башы!» Ул бу сүзләрен җыруга санамый, бәлки тыңлаучыга үзеннән бернәрсә көттерә.

Тыңлаучы: «Бу нәрсә әйтмәкче була икән?» – дип көтеп торган чагында гына, ул: «Безнең җанкай ялгыз башы, Хозыр булсын юлдашы», – дип куя.

Шулай көтмәгәндә генә килеп чыккан бу матур сүзләр тыңлаучының колакларына вә күңеленә, әлбәттә, хуш килә.

Бу тарыз җырлау табигый рәвештә сайланган булса да, бик муаффәкыятьле сайланган. Әүвәл юк кына сүзләр берлән тыңлаучының колагын торгыз да, аннан соң мәгънәле сүз әйт. Бик яхшы бит! Шулай көтеп алган кадерле була.

Бу сүзләр безнең җырларымызның күп тарафы шулай – әүвәлге ике юлы соңгы ике юлга ябышмаган булганлыктан гына сөйләнде.

Югыйсә безнең һәр дүрт мисрагы да бер-беренә ябыша торган җырларымыз да бар.

Мәсәлән:

Җаныем, җаныем, җанашым, авыртмыймы җанбашың?
Авыртсалай, ай, җанбашың, үзем түшәк, җанашым.

Мин сөямен үзеңне, кашың берлән күзеңне;
Мин сөйгәнне син шуннан бел: һич тә алмыймын күземне.

Ләкин болар мөстәсналар диергә ярый.

Инде халык җырлары вә халык әдәбияты дип нәрсәгә әйтелгәне, шаять, азрак аңлашылгандыр дип уйлыйм.

*

Халык җырлары – безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу – кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.

Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсун вә мәхфуз уларак калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле.

Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһад итәргә кирәк.

Белергә кирәк ки, халык җырлары – халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшан көзгеседер. Бу – бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр.

Менә шушы дәгъваны, ягъни халык җырларының сихерле көзге икәнен күрсәтер өчен, хәзер берничә җырлар җырлап күрсәтәмез.

Мәсәлән:

Байлар кияр каракүл, без киябез эшләпә;
Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә.

Менә бу җыру – халкымызның бу дөньядагы «байлык» вә «фәкыйрьлек» дигән ике нәрсәгә карашы. Аныңча, «Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә».

Кимим – бүркем булса да, җыламыйм – күңлем тулса да;
Ходай кушкач, нихәл итим, чыдыйм – авыр булса да.

Менә бу – халыкның Ходай тәкъдиренә чын күңелдән тапшырылуын һәм, никадәр авыр булса да, үзен-үзе чыдарга көчләвен күрсәтә.

Ак келәтнең тәрәзәсе сиксән сигез өлгеле;
Начар кызларга бәйләнсәң, хур буласың билгеле.

Менә халыкның «ак келәтнең тәрәзәсе» кеби юк кына нәрсә белән сүз башлап та, «начар кызларга бәйләнсәң, хур буласың билгеле» кеби чын хакыйкать сүзне шартлатып әйтеп тә бирә алуы. Монысын, мотлакан, халыкның әдәби икътидары диергә ярый.

Җөрмә монда, кайт иленә, илеңдә иген игәрсең;
Стаканыңны ат итеп, бутылкаңны җигәрсең.

Менә монысы халыкның үткен гакыллылыгын, русча әйткәндә, остроумиесен күрсәтә. Чынлап та, сукасын, сабанын, әвенен, хатын, бала-чагасын онытып эчеп утырган бер сала мужигына, шулай итеп, каладан китәргә киңәш бирмичә, ни дип әйтергә кирәк?!

Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына килгән бер авыру кеби, гаризи бер хәлдер. Фарсилар: «Гаризра игътибар нист», ягъни: «Вакытлы вә гаризи булган нәрсәгә игътибар юк»,– диләр. Хуш. Тагын бер җыру:

Әй тал үсә, тал үсә – башын киссәң, тагы үсә;
Тутасычөн кайгырмыймыз: сеңелләре тагы үсә.

Менә бу җыру чын-чын халык халәте руханиясен күрсәтә. Бу җыруны чыгарган кеше, әлбәттә, «апасы» белән мөнәсәбәттә булган булырга кирәк: ул аның өчен бер дә кайгырмый. Сөаль: «Ни өчен кайгырмый?» Җавап: «Сеңелләре тагы үсә». Күрәсез бит, бу җыруны җырлаучы гами: «Тутасычөн кайгырмыймын», – дип кенә туктамый, бәлки, үзен-үзе зурайтып: «Тутасычөн кайгырмыймыз», – дип куя. Зур кеше, имеш!

Әгәр санасак, мондый мисалларны хисапсыз күп таба алырмыз.

Бая әйткәнчә, сихерле күзгедән каралса, ягъни халык җырлары дикъкать белән укылса, халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын барчасын күреп буладыр.

Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер безнең халык – шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык. Чү, аз гына бернәрсә «шылт!» иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга. Мәсәлән, Гайнетдин дигән кеше үземе яки кызымы бер гаеп эшләгән икән – бетте инде, урамда бәетен җырлыйлар. Фараз итик: җәй көне авылда Гайнетдин абзый үзенең гаиләсе белән чәй эчеп утыра. Тәрәзәләре ачык, кояш төшкән. Бу гаилә бернәрсәдән хәбәрсез, тыныч кына утырган чакта, менә берзаман боларның тәрәзәсе төбеннән әллә никадәр үсмер җегетләр Гайнетдинне мыскыллап җырлап үтәләр:

Тау башында тимер бүкән, типкәләмә, Гайнетдин;
Без чыгарган бәет түгел, үпкәләмә, Гайнетдин!

Гайнетдин бичара вә гаиләсе кызарыналар, күзгә-күз карашалар, вәссәлам! Нишлисең, тегеләрнең авызларына тастымал тыгар хәл юк!

Кыргыз халкында булган кеби, бер-берсенә каршы җырлашу безнең халыкта әле һаман да бар. Ләкин, кыргызлардагы кеби, шома вә яхшы чыкмый. Кара-каршы җырлашканда, безнең халык бер-берсенең исемнәрен җырга катыштырып һәм һич кирәкмәгән, мәгънәсез сүзләр катыштырганлыктан, җырлары ямьсез чыга.

Мәсәлән, кара-каршы җырлашканда, болай җырлыйлар:

Аклы да гынай ситса, Закир абый,
Буй-буй ыштан, Җамалый кода;
Арага гына, Сәйфетдин абзый,
Төшкән дошман, Якуп агай-эне.

Ходай да гына кушкан, без кавышкан,
Җамалый кода, Закир абый, Якуп агай,
Нишләтер, ди, безне ул дошман!

Менә бу җыру булып чыкмый, бәлки шактый озын бер хат укып чыгу белән бер була. Ничек булса булган, әлхасыйль, халык һичкемгә мохтаҗ булмыйча, үз хиссиятен үзе мәйданга чыгарган, «җырның җыртыгы юк» дигән дә җырлый биргән, бәетләр дә чыгарган.

Халык җырлары, бөтен мөһмәляте вә җитлексезлекләре белән бергә, әлбәттә, үземезгә генә сөекле булырга тиеш һәм сөекле дә. Чит милләтләр өчен безнең җыру мәгънәсез вә хәтта көлке дә булса булыр. Мәсәлән, шушы җыруны русчага тәрҗемә итеп карыйк:

Калфагым бар, шәлем юк,
Шәл алдырмый хәлем юк;
Синнән башка сөйгәнем юк,
Сине алмый хәлем юк.

Русча:

У меня колпак есть, но нет шали,
Необходимо мне купить шаль.
По мне нет любимой, кроме тебя,
Необходимо мне жениться на тебе.

Шулай, һәрбер кош үз тавышы белән ләззәтләнә. Хәлне кире әйләндереп куйсак та, барыбер шулай булып чыга: мәсәлән, русларның сөеп җырлаганнары «Во саду ли в огороде девица гуляла» җырлары безнең колакка да ул кадәр хуш килми бит. Керпе үз баласын «йомшагым» һәм аю үз баласын «аппагым» дип әйтә, ди. Бу гарәпләр мәкале; гарәпләр моны: «Көлле тайрин ястәлиззе бисаутиһи»,– диләр.

Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр. Русларның Пушкин вә Кольцов кеби иң зур шагыйрьләре дә, халык җырларына тәкълид итеп, бертөрле «искусственныя песни», ягъни «сонгый җырлар» яздылар. Болай халык җырларына тәкълид итеп язган шигырь, тәкълид итмичә язылган шигырьләрдән хис, мәгънә, тасвир ягыннан һич тә ким булмавы өстенә, халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы илә язылганга, халык күңеленә бигрәк гүзәл тәэсир итә вә урынлашадыр. Бу җөмләдән Кольцовның «Ник йоклыйсың, мужик?», «Сукачы җыруы», Пушкиннең «Кызлар җыруы» саналалар.

Ә бездә халык җырларына тәкълид итүчеләр, билгомум, булдымы? Әлбәттә, безнең Кольцовларымыз, Пушкиннәремез булмаганга, мин: «Халык җырларына тәкълид итүчеләр, билгомум, булдымы?» – дигән сөальне тәкрар итәм дә: «Ник булмасын, булды»,– дип, үз сөалемә үзем җавап бирәм. Менә иң элек мәдрәсә шәкертләре тәкълид иттеләр:

Каләш-шәйхе фишшифа дип
Укыганың мантыйкмы?
Ма вәҗәдте, валлаһ, җаный,
Синнән гайре артыкны.

Гыйльме хикмәт укыр өчен

Бару кирәк Бохарга;
Ярның исе алышынмас
Мисек-ганбәр, җофарга.
Каля Рәсүллуллаһ дип
Укыганың «Мишкать»ме?
Имиең тотсам, кулым тими,
Әллә киемең биш катмы?

«Әл-хикмәтел-балига» –
Мин тәэлиф әл-Мәрҗани;
Филмәшрикый вә филмәгъриби
Ля нәзыйрекә, җаный.

Менә боларны «сонгый җырлар»ымыздан санарга ярый. Үткән сәнәләр нәшер ителмәктә булган бер көлке журналда, «Авыл җырлары» сәрләүхәсе астында шундый «сонгый җырлар» күренгәли иде.

Исемдә калган кадәресен язам:

Җомры тояк тайларда,
Матур кызлар байларда;
«Әхбар» тәэмин иткән байлар
Җөри икән кайларда?

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен
Рәмиевләр алтыны.

Башыңдагы чабатаңның
Сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды
Бәдигъ мәзин күркәсе...

Вә гайреләр.

Менә бу «сонгый җырлар» да вакытында бик оригинальный вә нәүзоһур нәрсәләр иде.

Чөнки көленергә тиеш бер нәрсәдән бер-ике юллык сүзләр белән тиз генә көленеп ташланыла иде. Бу озын-озын мәкаләләр хезмәтеннән артыграк эш күрә иде.

Башта әйткәнемезчә, халыкның бу тарыз җырлавы бик муаффәкыятьле сайланганлыктан, моның безнең һөҗүвиятемезгә – сатирамызга да файдасы тиде.

Халык җырларына билгомум тәкълид ителгәне язылды инде, ә шигырьләремездән халык җырларына тәкълид итүчеләр булдымы? Бу сөальгә дә: «Булды», – дип җавап бирергә тугры килә. Безнең шагыйрьләремез дә мәйданга «сонгый җыр» дип әйткән шигырьләр китерделәр. Әмма муаффәкыятьле чыктымы-юкмы, ансы тәнкыйтьчеләр нәзарына калдырыла.

Мисал өчен мин монда Миргазиз әл-Укмаси җәнабләренең бер «сонгый шигырен» вә башкаларның да берәр шигырен укып күрсәтәм.

Татар тормышыннан.

**Килен**

Мәэюс карый, аның күзләрендә
Туйганлык бар залим дөньядан;
Истикъбальләреннән өмид кискән,
«Ник тугдым, – дип еглый, – анадан?»

Кайнанасын күрә төшләрендә,
Җәллад булып килә каршына;
Башын кисә, имеш – моның гайбе:
Тоз салмаган, имеш, ашына.

Иртә тора таңнар сызылганда,
Кош-корт яңа канат какканда;
Иңләп бу бер ялгыз хезмәт итә,
Һәркем таң уйкусын тотканда.

«Чү, сүз булмасын, – ди, – кайнанамнан,
Рәхмәт әйтсен», – ди-ди эшли эш;
Аргач, ял итәргә курка, мискин:
«Тагын башланыр, – дип, – әр-каргыш».

Әгәр ялгыш булса бер хатасы,
Кайнанасы дөнья куптара;

Яшеннәр яшьни, күкләр күкри,
Дөньяларны җимрә, актара.

Зәһәрләнә, төсе зәңгәрләнә,
Гыйфритләнә килен өстенә;
Бичара килен – япь-яшь кызга
Зәгъфырандай сары төс иңә.

Мәэюс карый, аның күзләрендә
Туйганлык бар залим дөньядан;
Истикъбальләреннән өмид кисә,
«Ник тугдым, – дип еглый, – анадан?»

Бу булды бер. Тагы да мәгъруф шагыйрьләремездән Сәгыйть әфәнде Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» исемле китабыннан тәмам мәгънәсилә «сонгый шигырь» булган шушы җырны күчерәм:

Без эчәбез дә җырлыйбыз,
Акча бетсә, урлыйбыз;
Ходай безгә шулай язган,
Ярамый дип тормыйбыз.

Сәгыйть әфәнденең пьесасында бу җырны берничә исерек җегетләр урамнан җырлап китәләр. Аны алар җырламый, бәлки, Сәгыйть әфәнде бу җырны, аларның халәте рухиясенә карап, «авызларына сала». Менә бу шунлыктан «сонгый җырлар» җөмләсенә керә.

Инде шушы сәтырларны язучы кешенең дә шулай халык җырларына тәкълид уларак язганы бер шигырен дә нәкыль итәм:

**Милли моңнар**

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый,
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен,
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр берлән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзалмадым, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була,– диде,– «Әллүки»!»

Шушы мисал итеп китергәнем шигырьләр – барчасы да «сонгый җырлар»дыр. Бу «сонгый җырлар» халыкның үз рухынча, үз формасынча, үз вәзене белән язылганнардыр. Шуңар күрә боларны «Зиләйлүк» вә яки «Әллүки» көйләренә туп-тугры җырлап була.

Аңлашыла ки, бездә дә әдәбиятымызның нигезе булган шул халык җырларына, берничәшәр генә булса да, кирпеч салучылар булган һәм бар икән.

Халык җырларын, халык әдәбиятын колакка ишетелгәнчә генә хөкем итеп, бу мотлак шулай икән диеп булмый. Мәсәлән:

Җитен күлмәкне җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Безнең болай утырулар
Сагънып сөйләргә кала, –

җыруы шушы килеш отылып алынса, бу мотлак шушылай җырлана икән диер хәл юк, аны икенче кәррә ишеткәндә, ихтимал:

Җитен күлмәкне җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Гакылың булса, уйлап кара:

Бу дөньяда кем кала? –

дип тә ишетерсең.

Халык җырлары, халык әдәбияты кайчакта шулай аерым шәхесләрнең кәефенә карап төрлеләнә дә. Хикәя вә масалларда да хәл шушылай ук. Мәсәлән, бер хикәя сөйләүче үзенең хикәясен: «Бар иде урман буенда бер карт белән бер карчык»,– дип башласа, шул ук хикәяне икенче кеше: «Бар иде, ди, диңгез буенда бер карт», – дип башлый.

Халык җырларының вәзене вә җырлану рәвеше – һич үзгәрми торган бер генә вәзен вә бер генә рәвештер:

Сәҗидәнең камчат бүрке –
Күз өстендә күләгә;
Монда уйнаган монда калсын,
Анда кайтып сөйләмә, –

дигән җыру, әлбәттә, әллә кай заманнарда, әле безнең 17–18 яшьлек гүзәл Сәҗидәләремез башларына зур камчат бүрек киеп йөргән заманда җырланган. Инде хәзер, заманымыздагы кечкенә генә калфаклы туташларымыз тугрысында җырланганда да, барыбер шул ук вәзен, шул ук рәвеш белән җырланадыр.

Башка халыкта ничектер, бездә бер ел үтми ки, анда бер-бер төрле яңа көй чыкмасын. Бу хәл бабаларымызның мәҗүс заманнарыннан бирле үк дәвам итеп килми микән? (Бу урында бер нәрсә хәтергә килә: безнең халык җырларында халкымызның мәҗүс заманнарында җырлаган җырлары дип хөкем итәрлек бер җыр да сизелми. Барча җырларымыз ислам кабул иткәннән соңгылар гына булырга охшыйлар. Мисал өчен:

Иртә генә тордым, ай, таң берлән,
Битем юдым ап-ак кар берлән;
Ахирәт тә күрке иман берлән,
Дөнья күрке сөйгән җар берлән.

Безнең хәзерге җырларымызның күбесендә «ислам», «тәкъдир», «Ходай» сүзләре күренә. Гаҗәбан, мәҗүс заманындагы җырлар бөтенләй онытылып бетте микәнни?)

– Син бу ел чыккан яңа көйне ишеттеңме әле? Әнә фәлән абзый Мәкәрҗәдән яңа көй отып кайткан, – кеби сүзләр халык арасында һәрвакыт ишетелмәктәдер. Бу ел яңа көй чыктымы, халык инде былтыргы иске көйне җырламый вә уйнамый башлый. Авыл урамнарында җегетләр, көз көне никрутлар яңа көйдән тәмам ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар.

Татар көйләре, шулай ел саен алмашынып торганлыктан, төрле исемнәр илә һич тә санап бетергесез дәрәҗәдә күптер. Казандагы иске әдәбиятны сөючеләр, төрле көйләрне язып, әллә ничәшәр китап вә рисаләләр язып тараттылар. Ләкин һаман да көй исемнәрен санап бетергәннәре юк әле. Бу китапчылар һәммә Русия мөселманнарына мәгълүм вә уртак булган «Тәфкилев», «Әллүки», «Салкын чишмә» вә «Ашказар» кеби көйләргә җырлар язып таратсалар да, өязләрнең вә аерым авылларның үзләренә махсус булган җыр вә бәетләренә тия алмадылар әле. Фәлән авылда Себер киткән кызга, төгән авылда асылып үлгән яки баткан җегеткә үзенә махсус көйләр вә җырулар белән чыгарылган бәет вә моңнар һич тә җыеп бетермәслектер.

1905 ел җитеп, хөррият сәгате сукканчы, һәркемгә мәгълүм улдыгы үзрә, без Русия мөселманнарында әллә нинди бер гомуми онытылу бар иде. Шул онытылу арасында милли көйләремез, милли моңнарымыз да онытылып бара иде; әгәр бер кеше алдында «Сакмар суы», «Әллүки» кеби бер озын көйне җырлый башласаң: «Куйсана шул картлар җыруын! Яңа көйне җырла!» – дигән сүзне ишетә идең.

Әйе, хөррият булды, яшьләр чыкты. Алар халык арасына чумды. Алар шушы онытылып яки һичкем тарафыннан әһәмият бирелми башлаган милли моңнарымызны терелдерделәр. Китаплар яздылар. Әүвәл дә итальянский гармуннан башка уен коралы күрмәгән татарларга әллә нинди оркестрлар җыеп, әллә нинди чүмеч төсле мандолиннардан милли көйләр уйный башладылар. «Куйсана шул картлар җыруын! «Әпипә»не әйттер»,– диюче кешенең, теге чүмечләр белән уйнаучы унлап җегетләрнең иске «Зиләйлүк»ләрне уйнаганын ишеткәч, колаклары торды. Аркасыннан каннар йөгерде. Әүвәлге фикеренең ялгышлыгын сизде. Бөтен көй вә моңнарымызга мәхәббәт итә башлады. Казандагы «Шәрык клубы»на бу хезмәте өчен милләт исеменнән рәхмәт укымаска мөмкин түгелдер.

Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бертөрле хосусият бар кеби.

Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп, вә авызны бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәкъбүл түгел. Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы, вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбүл вә мөстәхсән күренә. Мәсәлән, мин дөм чукрак булып та, җырлап утыручы бер татарның авызына карасам, мин аны җырлый дип белмәс, бәлки бер нәрсәне кызу-кызу сөйли икән дип хөкем итәр идем. Әгәр дә шул чукрак хәлемдә бер русның җырлап утырган хәленә карасам, мин аның авызының җыртылганчы ачылуыннан вә үзенә көчлек килүеннән, мотлакан, бу җырлый дип уйлар идем.

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта һәр шәкертнең хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде. Аның шулай мыек астыннан гына җырлавы безнең хушымызга бигрәк китә иде.

Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә ошарына күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела. Бу тугрыда күп мөсахәбәгә кителсә, эшнең музыка вә аны аңлау мәсьәләсенә җитәчәге сизелә.

Минем образованием бик бала рәвештә – малютка булып калган. Юк аның тоткан нәрсәсен куптарырлык кулы. Юк аның уйлаган вә сизгән нәрсәсен дәлилләр берлән сөйләрлек теле. Юк аның караган нәрсәсен аркылы тишәрлек күзе. Шул сәбәптән җәһаләтемне билигътираф, ул хакта күп сөйләүдән туктыйм.

Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җырларыннан гына табып була.

Аннан башка кайдан табасың? Безнең матбугат исемендә йөртелгән иске китапларга вә басмаларга кайтып карыйкмы? Иске китапларымыздан «Фәзаилеш-шөһүр»гә, «Йосыф китабы»на мөрәҗәгать итикме? «Фәзаилеш-шөһүр» белән «Йосыф китабы» кем телендә? Алла белә, җен телендә. Бу китапларны кем дәрес китабы итеп тоткан? Татарлар.

Киләбез «Таһир-Зөһрә»гә:

Сазың күп моң кылады,
Ишеткән таң калады;
Гариб гашыйк, якын кил:
Исмеңез кем булады?

Бу кем телендә? Кыргыз телендә. Бу кем китабы? Татар китабы. Бу – татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер.

«Тәрҗеман» гәзитәсен алабызмы? Бармы анда бер генә татарча сүз?! Көчләре беткәнче: «Без «Тәрҗеман» бабай артыннан калмыйбыз», – дип маташкан иске өлфәтче вә башка да берничә мөхәррирләрнең тәхрирләрен алыңыз. Бармы аларда татар рухы вә татар сүзе?!

Андый мөхәррирләребез татарларны төрекләштерергә аз тырышмадылар. Ләкин булдыра алмаслыкларына тәмам күзләре җиткәч кенә туктадылар.

«Тәрҗеман»ның гына ара-тирә җылаганлыгы ишетелә.

«Борһане тәрәкъкый» тагы, яңлыш-йоңлыш булса да, төрек җөмләләре тәртип итеп маташкан булып, нинди көлкеләр эшләмәде.

Үз araларында төрекчә сөйләшеп маймылланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, «госманлыез, әфәндем» дип йөрүче хиффәтләребез дә аз булмады.

Ләкин мондый комедияләр вакытында булды да, узды да китте.

Гәзитәләр дә, «бундан», «буйлә» кеби сүзләрне генә калдырып, татарча языла башладылар, китап вә рисаләләр дә татарча чыга; без татарлар һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр – Истамбулда, без – монда.

Хәерле юлга!

**Хатимә**

Халык җырлары чын үземезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм. Шунлыктан халык җырларына мәхәббәтемнең бер әсәре булсын дип, шушы мөляхәзәләремне язарга җөрьәт иттем.

Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атнакичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем.

Мәдрәсәдүк мине җырчы, диләр иде.

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырлар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугды. Әгәр миңа җырлар ярдәм итмәсә, мин соң сарт «Бәдәвам»нәре, сарт «Кисекбаш»лары, кызылбаш «Тасриф»ләре, гарәп «Нәхү»ләре белән туган телемезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик була алыр идеммени?

Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үземне,
Әткәм-әнкәмне, Ходам.

Соң.

## Юбилей мөнәсәбәте белән

Кичә минем өчен төн үткәрү, әллә ничек, милләтемезнең җансыз тормышы кеби, күңелсез вә эчпошыргыч булды. Исемә төште ки, шундый чакта бераз көйләсәм, шыңгырдасам, күңелем ачыла торган иде.

Бәс, мин, яңа теле чыга торган баланың аңлашылмас такмагы кеби, вәзенсез-нисез бер бәет такмакларга керештем. Бәет кечкенә чакта укыган бер кадим китабыннан иде бугай. Бәетнең мәфһүмендә дөньяда тигезлек юклыгы вә кешеләрнең мөхтәлиф хәлләрдә булуы сөйләнгән. Фәкать сәтырлар тәртибе һәм вәзен тугрылыгы минем хәтердән чыккан. Шунлыктан телемә килгәнчә генә җырладым.

Бу дөнья һич тигез түгел,
Адәмнәр дә игез булмый;
Ходай шулай яраткач шул,
Берәү башы сигез түгел.
Кеми галим, кеми җаһил,
Кеми надан, кеми «гыйлем»;
Күрше килене чибәр хатын,
Күрексез лә безнең килен.
Кеми дәүләт иясеdер,
Яшел хөллә кияседер;
Әнә ул ат көтүләре –
Фәлән байның биясе бит.
Кеми динсез, кеми динле,
Кеми мәсҗед сарый килми;
Кеми салих, кеми фасикъ,
Кеми приют, кеми кызлар
гимназиясе сала –
Ходай тигез яратмаган!

(Чү, теге якта тыңлап яткан әби, шигыремнән әсәрләнеп, үкереп җылый...)

Бу минем төнлә, эч пошу саташуы белән сөйләнгән шигырьләремнән көлмәсләр дип беләм, чөнки көтепханәләр шүрлегендә моннан да вәзенсез вә тозсыз шигырьләрне алып, минеке белән чагыштырырлар, бәлки. Шул вакыт, әлбәттә, минем бу бәетләрнең кадере беленер.

Шулай инде, дөньяның, мәсәлән, кошларыннан вә хәшәрәтеннән генә дә акыллы кешегә гыйбрәт алырга мөмкин. Аларда да тигезлек юк. Мәсәлән, черки дә оча, чыпчык та оча. (Күгәрчен дә оча, чәүкә дә оча. Карга да оча, козгын да оча.) Шулар белән бергә бөтен кошлар ханы булган каракош – орел да оча. Ләкин һәрберсе үз канаты куәтенчә.

Инсаннарның дөньяда торган чактагы таләпләре дә, күңелләрендәге теләкләре дә шул кошларның очышына охшыйдыр.

Мәсәлән, Наполеон таләбе бар. Әнвәр бәк таләбе бар. Боларның таләбе мәгълүм: бөтен дөньяны үзләренә мөсәххәр итү. Гади генерал вә забитлар таләбе бар; боларның таләбе дә яшерен түгел: үзләренә атакланган көллиятле мәгашне кулдан җибәрмәү илә бәрабәр, хәрби шаннарын саклау һәм Ватан угърында күреләчәк читенлекне ничек булса да өстән төшерү, кирәк булса, утка да керү.

Бер миллионлы байның таләбе – акчасын ике миллионга җиткерү (йөз меңленеке ике-өч йөз меңгә мендерү). Инабәт белән эш итүченең таләбе ничек тә «абруй»дан төшмәү, ригайә күрү.

Приказчикның – байга ярау, авыл мужигының – җәй көне эшләгәч, кыш көне тук булып тору.

Түбән сыйныф эшченеке – бүген тук йоклап, иртәгә саулык-исәнлектән эшкә тору.

Каты җилләр исеп киткәндә, төрле зурлыктагы кошлар кунган төшләреннән очышып чыккан кеби вә һәрбере үзләренең очудагы икътидарларын күрсәткән төсле, милләтләр дә бертөрле гомуми эш чыгып, тәрәккъый җилләре иссә, үзләренең таралышкан урыннарыннан чыгып, бер җиргә җыелалар, теге гомуми эш хакында милләтнең һәр фәрде үз фикерен сөйли. Теге кошларның очышы кеби, үзенең аңы, икътидары вә голүе табигате ни дәрәҗәдә икәнен изһар кыйла. Шуннан аерым фәрдләр танылa вә бәһаләре куела, таләпләре аңлашыла.

Менә әле Казан мөселманнары, Романовлар юбилее кеби, инде тагы бер тәкрар ителмәс кеби олугъ тарихи вә ватани вакыйгадән истифадә итеп, падишаһ хәзрәтләреннән ни-нәрсә истирхам итәргә һәм, олугъ нәселнең исемен тәэбид итү белән бергә, милләткә дә файдасы тиярлек нинди мөәссәсә торгызуны сорау тугърысында сүз кузгаттылар.

Сүз кузгалып кына калмады, зур мәҗлесләр булды. Бу мәсьәләне мөзакәрә өчен бөтен шәһәр могтәбәраны җыелды. Хатиблар мөнбәргә чыкты. Һәркем дәрәҗәи фикриясен күрсәтте. Әлхасыйль, монда черки дә очты, чебен дә, чыпчык та, «каргалар» да вә, ниһаять, орел да очты. Кемнең таләбе нәрсә вә голүе табигате ни дәрәҗә икәнлеген белдек.

Шулай белдек ки, мондагы бер сыйныф халык шушы вакыйгадә, шушы, моннан соң колагымызны күрмәгән кеби күрмәячәгемез, 300 еллык падишаһ нәселе юбилее вакыйгасендә приют сорамакчы булганнар иде. Җамали агайның Тегәрҗеп урамына бакалея кибете ачарга мәхәлли мәэмурлардан рөхсәт алуы кеби, һәрвакыт мәйданга килә ала торган приютны сорарга уйлаганнар иде.

Менә бу хәл инде черки очуы була. Бу хәл инде узган юбилейнең кыйммәтен корым тазартучының бриллиант тәкъдир итүе кеби аңлау була иде. Бу хәл инде милләтнең чын ихтыяҗына вакыйф булмау, бөтен авыл янганда, белмәмешкә салынып, чабата киндерәсе үрү була иде... Киребеткәнлек була, чебен очуы була иде.

Таләпсезлек вә түбән табигатьлелек була иде. Бәгъзеләре: «Яшьләргә барыбер гимназияне бирмәсләр!» – дигән булалар иде.

Ләкин яшьләр бу тарихи вакыйганең чын кадерен аңлау белән, милләтнең дә ихтыяҗын сизү белән, аларга Шекспирның зур каһарманнарыннан берсе булган Гамлетның: «Быть или не быть!» – дигән сүзе белән генә җавапланганнар иде.

Күк капусы ачылганын күргән бер башкорт, вакыттан истифадә кыйлып, дога кыйлган:

– Йа Рабби! Иртәгә бер телем ак күмәч белән май ашасам иде!

Әнә ул приютчыларның да таләбе шул башкортныкыннан югары түгел инде.

Романов юбилее мөнәсәбәте белән падишаһ хәзрәтләренә депутация барган, нәрсә истирхам итәләр: «Безнең Печән базарында хәерче кызлары күбәйде, шуларны бер йортка җыеп асрыйкмы? Аның янына бер мәдрәсә дә салып куябыз».

Әмма яшьләр, күк капусы ачылганда, зуррак дога кыйлмакчы булганнар иде. Кабул булмаса булмас.

Янә тәкрар итәмез:

«Быть или не быть!»

## Уянгач беренче эшем

Ярты төш мисалендә үтеп киткән 7 сәнәлек бер мөддәт эчендә минем тарафтан шактый гына мәнзумат язылып ташланган. Ул мәнзумат, вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган. Гәрчә һичбер диванның басылу саны икедән артмаган булса да, алар шактый вә хәтта күп таралган. Һәр тарафта: «Бер казакъта гына түгел, бездә дә бер оста такмакчы булды», – дип, минем такмаклар мисал итеп күрсәтелгән. Шулай булган. Заман кичкән. Сулар аккан.

Югарыда шәхси тормышымны «ярты төш»кә охшатуымны Казанда минем ничек вә ни рәвештә көннәр үткәрүемә шаһит булган кешеләр, әлбәттә, аңлыйлар. Бүтәннәр бик аңлап җиткермәсәләр дә, монда үкенерлек хәл юк. Фәкать сабыр кирәк. Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле.

Әнә шул «ярты төш» мөддәтендә мин бәгъзан уянып, тәмам сафланып та китә идем. Андый чакларда мин әллә ничек, итегемә чия төше кергән кеби, штиблит бавым чишелгән кеби, тормышымның өскерәк кат уңайсызлыкларын сизеп тә ала идем. Ләкин нә файда: бәхетсез милләтнең бәхетсез угылы, бәхетсез почмакның әсир былбылы булган мин, бичара, тагы әллә кемнәрдән агу алам, тагы кәефләнәм, тагы төш күрә идем. Әйе, кардәшләр, минем уянуларым тормышымны төзәтер вә алдагы идеалыма тугрырак атлар өчен, җитди вә әсаслы бер эш кыйла алмыйлар иде.

Тугры әйтергә яраганда, кинаяләргә сыгыну нәрсәгә? Минем кайсы чаклар уянганда тыгызланган вә газапланган маддәләрем төрле диваннарымда һаман әле үзем, җаным, вөҗданым, оятым, хәятым разый булмаган шигырьләремнең шушы көнгәчә халык тарафыннан укылып (нахально) йөрүләре иде. Вә ул шигырьләрнең, бүген бу сәгатьтә үзләрен тотып яндыра вә җәһәннәмгә юнәлтә алмавым сәбәпле, гүя минем өстән кычкырып көлүләре иде. Ләкин, тәәссефләр улсын, тагы уйкуга тала идем.

Көн киттек, төн киттек, тәртә буе җир киттек. 1913 ел, менә мин уяндым. Инде мәңге йокламаска дип уяндым.

Фәсәүфә тәра иза инҗәләл-гобар
Әфәрәсен тәхтәкә әм химар!

Күрдем. Атланганым ишәк икән. Үзем бер җүләр вә фитърәтем җиһанга килмешәк икән. Чыннарым ялган, суларым төтен икән, «мәгъсум»нәрем бер җәһәннәмгә дип өйгән утын икән.

Теге «төш» күргәндә, шыр ялангач калдырылып талансам да, тормышта бик каты алдансам да, тукта әле, егъламыйм, Аллам юл ачар әле, дидем. Күз ачылуының беренче дәкыйкаләреннән билистифадә иң элек 7 ел, тәмам 7 ел мөддәтендә себерү вә пакьләү күрмәгән «такмак бүлмә»сен себерергә тотындым.

Һу, монда чүп-чар! Монда әллә нинди «американизировать» ителгән «Кичке азан»нар, бозаудан ахмак төрек шыгырдаучыларына ишәктән тиле тәкълидләр. «Шәкерт яхуд бер тәсадеф» кеби, инсан авызыннан чыкмаган диярлек тәркибләр, тагы шундый кабахәтләр...

Менә шундыйлар минем рухани бүлмәдә 7 ел торганнар. Меңнәр мәртәбә халык күз алдын мәсхәрә итеп, кайсылары бишәр меңнән икешәр кат басылганнар вә, Ходa гына белә, күпме укылганнар. Соң боларның 7 шәр ел буе бүлмәдә ятуларына ни сәбәп булган? Менә шул чүпләрнең язылуына нинди кабахәт вә кара көч сәбәп булса, шул сәбәп булган.

Башыңда гакылың сафайгач, «төш» күрмәгән чакта, бүлмәңдә үзең сөймәгән бер генә кешене дә тотасы килми. Кая ул минем «теге шигырьләрем» кеби бөтен бер артельне! Юк, котылдым. Инде мин аларны себердем. Алар «һәбаән мәнсүра» инде. Бүлмәмдә «үз сөйгәнем», «үз сөйгән шигырьләрем» генә калдылар.

Тормыш юлымда очрап, минем белән белешләнгән вә дусланган кешеләр бәгъзан аларга бөтен диваннарымны һәдия итүемне сорыйлар иде. Чит шәһәрдә налож белән җибәрүемне үтенәләр вә, күпме хак куйсам да, түләп алачакларын вәгъдә итәләр иде.

Ул китапларның кибетләрдә сатылуын да төрле сәбәпләрдән наши туктата алмаганыма ләгънәт укып йөргән мин, һичбер вакыт үз кулым белән, «борыны сизми» дип, чын дустыма үлгән мәче һәдия итәмме соң? Юк! Әлхәмделилләһи, юк. Лән тәналлу әлбиррә хәттә төнфику мимма мөхиббух.

Яхшы беләмен ки, ушбу хәзер ташлаячагым вә игъдам итәчәгем шигырьләрем белән минем хәяма тукынырга күп тәшәббесләр иттеләр. «Вакыт», «Шура», «Идел» вә башка да бик күп идарәләргә мәкаләләр бирделәр. Дәреҗ итәргә үтенделәр. Әгәр алар мине үз-үземә дә, кешегә дә шул шигырьләр белән тәкъдим итсәләр вә миннән мәлгунанә бер сурәттә шаркылдап көлсәләр, вакыйган, максудларына җитәрләр иде. Ләкин миңа эш башында рух биргән идарә мөхәррирләре эш уртасында мине мәсхәрә иттермәделәр. «Теге»ләрнең мәкаләләре дә басылмадылар. (Мүтү бигайзыйкем!)

Китапчыларның да хакымдагы төрле рисаләләрне басмыйча калдыруларына вә хәямны химаяләренә тәшәккер итәм.

Мөхәррирләр дә, китапчылар да мине хәзерге «аң»ым вә самокритикам ул шигырьләрдән гали икәнен беләләр иде.

Мин үзем дә:

– Ләкми чир, аурып та булмый, ичмасам! – сүзләренә бара-бара, рухани бүлмәмне бертөрле тазартырга вакыт эзли идем вә һаман, Алла юл ачар әле, дип өмидләнә идем.

Менә Алла юл ачты, «бүлмә» себерергә бушадым. Себереп тә чыгардым. Әй, җир йөзендәге төрек баласы, галимме син, хәкимме син, падишаһмы син, теләнчеме син, инде мин сине өемә кертергә оялмыйм, инде син кем булсаң да, мин сиңа такмак китабымны мәгаль-ифтихар һәдия итә алам.

Әле күптәнме, берәү диваннарымның берсен кесәсеннән чыгарса, калтырый идем. Кешеләр алдында укып җибәрсәләр, бүркемне дә кимичә, урамга кача идем. Җаннан кадерле кешемне, шул такмакларымны сораса, мәхрүм итәргә мәҗбүр була идем.

Фәиннә мәгаль-госри йөсра.

Тиз арада үзем браковать итмәгән вә үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга чыгарырга карар бирдем.

Валлаһел муаффикъ.

## Истәлекләр, юлъязмалар

## Исемдә калганнар

### Мөкаддимә

Бу «Исемдә калганнар»ны язуыма башлыча сәбәп берничә наширләрнең миннән тәрҗемәи халемне язып бирергә үтенүләре булды.

Мин аларга туганымнан алып хәзерге яшемә кадәрле тәрҗемәи халемне кыска гына рәвештә язып бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте.

Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде.

Шунлыктан Уральскигә килеп җиткәнемә кадәр кичердекем хәлләр илә аннан соң хәзер шушы сәтырларны язып утырган вакытыма кадәрге башыма килгәннәрне икесен ике рисалә итеп чыгарырга мәгъкуль күрелде.

*Г.Тукаев*

*29 сентябрь, 1909 сәнә*

**I**

Минем атам Мөхәммәтгариф, Кушлавыч карьясендә Мөхәммәтгалим исемле мулланың угылы булып, 14–15 яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә китеп, анда хәтме көтеб кыйлырга гадәттә ничә сәнә кирәк булган булса, шулкадәр торып, карт атасы тере вакыттук авылымыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр.

Мулла булгач та өйләндеке бер җәмәгате илә берничә генә еллар торгач, җәмәгате вафат булып, бер ир вә бер кыз баласы калмыштыр.

Моннан соңра атам, икенче мәртәбә өйләнүе уларак, Өчиле карьясе Зиннәтулла хәзрәтнең Мәмдүдә исемле кызыны (минем анамны) алмыштыр.

Анам илә бер ел ярым кадәр торгач, беренче бала уларак мин дөньяга килгәнмен.

Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам, аз гына вакыт авырып, тәрке дөнья итмештер.

Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылымыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна нам карьянең имамына кияүгә чыкмыштыр.

Бу вакыт атамның ата-анасы (бабай вә әби) күптән вафат булып, авылда башка туганнарым булмаганлыктан, мин бу карчык ханәсендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән; тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-өч ярым яшемдә генә булганмын дип уйлыйм.

Хәзер авылда минем вакъты сабавәтемне күргән карчык вә хатыннар мөрәббия карчыгымның минем илә бик начар мөгамәләдә булганлыгын үземә хикәят итәләр.

Җөмләдән берсе.

Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозгаябышып катканча көтеп торам икән.

Карчык исә үзенең: «Кадалмас әле, килмешәк!» – дигән «шәфкатьле» фикере илә мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән.

Ул карчык үлгән инде; Алла аңар рәхмәт итсен.

Мин бу карчыкта торган мөддәттә анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк: ул бервакыт мине үз янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән дәкыйкаләрдә миндә, бала булсам да, бер нәүгы шөгур хасил булганмы, нидәндер мин хәзердә дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады – анысын белмим; ләкин үги этиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт бик озакка бармаган. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

«Булган», «булганмын», «мине шулай иткәннәр» дип язуымны, билгеле, ул яшьтәге сабыйларның хәтерләрендә бик мөәссир булмаса, сирәк дәкыйкаләр генә калганлыгыннан гынадыр дип уйлыйм.

Шуның өчен мин монда, әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан үкереп җылый-җылый җөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» – дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне язамын.

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле карьясендәге анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән.

Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чактук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны аңар ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

Өчиле карьясе (исеменнән дә мәгълүм) бик кечкенә вә ярлы бер карья булганга, шуның өстенә мин ятим калган елларда ул тарафларда каты ачлык булганга, бабайның көн күрмеше гаять начар булган.

Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган семья эченә мин ятим бала булып ки-

леп кергәнмен.

Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине, җыласам – юатучы, иркәләним дисәм – сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә – кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.

Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.

Шул рәвешчә көннәр үткән, мин, монда торганда, чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.

Бу гаиләдә һәммәсе (бер җитеп килә торган Саҗидә исемле кыздан башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде», – дип кенә караганнар.

Мин әле хәзер истисна итдекем Саҗидә апайның үги әбидән яшереп кенә мине җуатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә.

Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган – һәрничек мин бу семьяга сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылымыздан Казанга бара торган бер ямщикка мине утыртып, Казанга озаткан.

Ямщик Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» – дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. Ул мине мөддәтсез бер асрау бала итеп өенә алып кайткан.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт, әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдыртмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәленнән бераз язып китим әле.

Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә иде.

Әти талчокта сату итә идеме, әллә тиречә идеме шунда – анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армыйталмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.

Әни, Печән базарына кәләпүш чыгарганда яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде.

Мин, байлар йорт эченең матурлыгыны, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

Бервакыт шулай, байларга барганда, ишегалдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны күреп, бигрәк тә сокландым.

Бу ата-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда миңа ач торырга туғры килми иде.

Кайчакта әни белән Ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатланып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем, акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.

Аннан соң җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз җоннары куып йөргәнемне, арыгач, Хан мәсҗеденә юнәлеп ятып, чирәмдә ял иткәнемне бер дә онытмыйм.

Мин бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк...» – дип, теге мине Казанга китергән ямщикны табып, мине янәдән, аңар утыртып, Өчиле карьясенә җибәргәннәр.

Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу семьянең мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.

Мин кайтып, бераз торгач та, әби белән бабай, инде мине шәһәргә җибәрүдән өмид кисеп, кайда булса да бер чит авылга асрарга бирергә уйлашканнар.

Болар Өчилегә килгән һәрбер чит авыл кешесенә үзләрендә асрарга бирергә бер ятим бала барлыгын сөйләгәннәр.

Шулай мәшәкатьләнә торгач, бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди исемле бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән.

Бу урыннан игътибарән тәрҗемәи халемне үземнән хикәя итүне күңелем хаклы тапканга, «булган»-ны – «булды»га, «йөргәнмен»не «йөрдем»гә илх... алмаштырам.

**II**

Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби (Сәгъди абзыйдан яхшысынмый гына булырга кирәк) мине озатырга чыктылар. Тагы да минем китүемне кызык күргән яланаяклы малайлар да арба тирәсендә җөгергәләп йөриләр иде.

Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Алла боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың», – дип, миңа барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине юатып бара иде. Мин дә, ачык йөзләрне бик күптән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.

Бу вакыт җәйнең матур чаклары булганга, әтрафтагы яшел чирәмнәр вә урманнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш икенче яктан тагы рәхәтләндерәләр иде.

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән; аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә, салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган, минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты; мине ачык йөз илә каршы алып, арбадан күтәреп төшереп, өйгә дә алып керде.

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, эти дә өйгә керде. Кергәч тә, әнигә хитабән: «Хатын! Бар, балага катык белән ипи китереп бир», – дип әмер итте.

Әни дә, дәрхаль баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле җүнләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, бик шәп бер иштиһа илә икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин анда чыгып, адашудан куркып, артыма карый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар һәр көн авылның бер башыннан бер башына җөгереп йөреп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда да мине Өчилегә кире җибәрер алдыннан әнинең, миңа сагынмалык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар; мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда (бая катык ашаганда күрмәдекем) ике җиткән кыз күрдем.

Боларның берсе – таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе арык кына, сары йөзле генә, култыгында агач таяклары бар аксак бер кыз иде.

Әни миңа: «Менә болар апайларың: берсе – Саҗидә апаең, берсе – Сабира апаең, күреш», – дигәч, мин, әкрен генә барып, кулымны суздым. Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Саҗидә атлы икән.

Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым. Авыл малайлары белән дә таныштым.

Сәгъди абзыйның юлда әйткәненчә, вакыйган, монда катык, сөт күп, шулай ук бәрәңгегә дә ихтыяҗ юк иде.

Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар.

Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар илә авыл буенда җөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем. Әгәр көндез кайвакыт уен арасында карыным ачса, тиз генә өйгә кайтып, җан тәрәзәдән генә өйгә кереп, әнинең минем өлешкә калдырган бер җамаяк бәрәңгесе илә бер телем икмәген ашый идем.

Алар әбәттән (көндезге аш) соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, җан тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше дә калмаганлыктан, без бакчалардагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек. Әгәр өй саклаучы карчыклар күрсә, без дәрхаль киртәдән сикереп качадыр идек. Карчык мискинәнең орышып, тешен кысып калудан башка кулыннан бер эш тә килмидер иде.

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үземезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар илә вак балыклар сөзеп ята идек. Күңелле чаклар!

Бервакыт шулай уйнап йөргәннән соңра, кич белән өйгә кайтсам, өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем. «Бу нидән икән?» – дип уйлап торгач, Сабира апайның идәннән сәкегә котырган шикелле җөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен, һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның урактан «җенләнеп» авырып кайтканын белдем.

Ул көнне өйдәгеләр берсе дә йокламый үткәрделәр. Мин генә, бик йокым килгәч, тыштагы арбага чыгып йокладым.

Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма: «Сабира апаң вафат булды; син йоклап ятасың, тор, тор!» – дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам – каршымда әни тора иде.

Бу, билгеле, миңа да гади хәбәр түгел, – йокы тәмле булса да, сикереп тордым.

Шул көнне Сабира апаны җирләделәр. Аны җирләп берничә көн үткәч, әнинең этигә:

– Менә, «үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул; мөгаен, шуның шомлыгыннан булды инде бу! – дип сөйләгәнен ишеткәли башладым.

Андин соң кайчакларда әнинең җә кушкан җомышын тыңламасам, җә җиренә җиткерми эшләсәм, шул сүзне әйткәли торган иде.

Әти белән без бик-бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде. Мәсәлән, бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, казакиләрем тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән угылының күк киндер күлмәге илә бишмәтен миңа бирмәкче булды.

Шунда әни:

– Мин үз угылымның төсе итеп саклаган киемнәрне кешегә бирер хәлем юк, – дип, бик озак тарткалашты.

Ахырда әти:

– Җә, хатынланма әле юкка, үзеңнән тумаган бала дип, әллә аны шыр ялангач йөртерсеңме? – дип, киемнәрне көчләп диярлек миңа алып киертте.

### III

Шулай итеп, урак бетте, көз җитте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәңге казырга вакыт җитте.

Бу бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә тугъры килмәде: мине казып чыгарылган бәрәңгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт, көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым туңганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем.

Бервакыт шулай, аякны балчыкка күмеп бәрәңге чүпләгән чагымда, теге бәрәңге казучы аксак Саҗидә апай яңлыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин дә урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып егъладым да соңра, җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемә дәвам иттем; ләкин бу юлы аяклар никадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

(«Моны ни өчен яздың?» – диерләр. Ни өчен язйым? Шул вакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга, тоттым да яздым.)

Бара торгач, бакча эшләре дә бетте.

Беркөнне кич белән әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга укырга илтәчәкләрен миңа мәгълүм иттеләр.

Таң атты; кояш чыкмас борын ук торып чәй эчтек. Чәйне җыештыргач, әни мине кулымнан җитәкләде дә үземездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек. Мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында, минем яшемдәге кечкенә кыз балалар күп булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богъдай арасындагы берничә борчаклар кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни иң элек ике бөтен икмәк илә бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кыйлдык.

Әни мине тапшырып, үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «әлеп, пи, ти, си, җымыкый»ны, бер дә тарланмыйча, кычкырып укый башладым.

Шул рәвешчә, «әлеп, пи, ти, си»не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарты» да тоттырдылар.

Бу «Иман шарты»ның иҗеге белән сүрәсе миңа кыш буена җитте бугай. Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарты» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым.

Фәкать, «Иман шарты»н бетерүгә гыйлавә уларак, бервакыт абыстай өйдә юк вакытта, бәгъзе шаян кызларның: «Кәлимәтен таййибәтен, безнең әни бай катын, изүе тулы тәңкә, борыны тулы...» – дигән сүзләрен ишеттем.

Ишетелмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым. Һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкрарлап, аларны көлдереп йөрер булдым.

### IV

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр, тәмам кардан ялангач калып, карала башладылар.

Менә бераздан Сабан туе җитте. Мине Сабан туе көнне иртүк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән

аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем.

Авыл халкы тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген Сабан туе бәйрәме көне булганга, бигрәк тә иртә торганнар вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибарән миңа, башка малайларга биргән кеби, конфет, бер-ике прәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буяган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыкның болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр дә, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы – анысын белмим; капчыкны әнигә бирдем дә, үзем, кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл җегетләре, авыл кызлары, ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан Сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситсы кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без, яланаяклы малайлар исә, аның артыннан бер дә калмыйча җөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы – хатыны-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр. Көрәшләр, узышулар башланды. Болынлыкта җөк-җөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак прәннекләр хисапсыз иде.

Болар арасында егетләр тарафыннан кызларга бирелергә иң муафигы, әлбәттә, кызыл билле ак прәннек инде. Чөнки ул прәннек хакында бер авыл җыруы да бар. Болай:

Болынлыкка бөркет килгән,
Куркытадыр казларны;
Кызыл билле ак прәннек
Кызыктыра кызларны.

Атлар да чабышты, малайлар да җөгереште, яулыклар да алынды; шулай итеп, Сабан туе да бетте.

Исемдә юк инде – бу Сабан туе ничә көн булгандыр, мин бер көнен генә яздым. Бәлки, ул 3–4 көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

Шуны да әйтергә кирәк: мин бу җәйне үткән җәй кеби җөгереп, уйнап үткәрә алмадым. Чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы җуатып, тирбәтеп утыра идем.

Менә тагы урак вакыты да җитте; үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мин бер малайны бу ел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә уракка да алып чыктылар. Шунлыктан бу җәем уйныйсы килгән балалар өчен зур газап булган нәрсә – эш белән үтте.

Бу бала тугач, этинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды, шөйлә ки мин үз өлешемә төшкән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым.

Җитмәсә тагы, теге аксак кыз да: «Үз энем! Җан энем!» – дип, Садрины җүри мине кәефсезләндерер өчен сөйгән була иде.

## V

Көз җитте. Гадәттәге бәрәңге хезмәтемне иткәч, мине бу юлы (кызлар белән бергә абыстайга түгел) мәдрәсәгә бирделәр.

Мин мәдрәсәдә, Һәфтияк иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга тугъры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар.

Шул балалар арасында авылымызның бер бай баласы да булып, ул мине хәлфәсе кебек итеп чәйгә вә эченә борай ярмасы салган бәлеш ашарга чакыргалый иде.

Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да йорт хезмәтләренә дә ярый башладым. Мәсәлән, иртә белән менеп морҗа ачу, аннан соң морҗа ябу, мичкә ягар өчен салам көлтәләр бәйләү, сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кеби эшләр – һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.

Кайвакыт җәй көне эти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем.

Авылымызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, берзаман этинең шәриге йә дусты булганмы, нидәндер миңа атна саен 5 тиен акча бирә иде. Мин бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем.

Эти мәрхүм, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәчеңне әниеңә дә калдыр!» – дип куя иде. Мин дә, әлбәттә, «ярар» дия торган идем. Ләкин ул күмәч авылга

кайтып җиткәнче, вак-вак кына капкаласам да, әнигә кала идеме, юкмы – анысын хәтерләмим.

Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга, андагы хатирәләрдә озаграк туктарга тугъры килде.

Шуның өчен хәзер андагы үзгәреш вә тәхаттырларны берничә җөмлә белән генә язам да Кырлайдан чыгып китәм.

Саҗидә апай, чахотка белән бик озак авырып, хәтта мунчага-фәләнгә барганда аны әти үзенең аркасына күтәреп йөри торгач, ниһаять, үлде. Әтине дә, кич белән әллә кайсы авылдан кайтып ат туарган чакта, кисәктән килгән бер авыру эләктерде. Аның шундук аңсыздан бер аягы аксады. Бу авыру хакында «ат җене сукты», «йолдыз атты»-фәлән кеби төрле хөкемнәр йөрттеләр.

Әти бу авыру сәбәпле эштән калмады, тик бер аягы гына чатанлап йөрүчән булып калды.

Бервакыт көз көне өйләдән соң әти белән әни ындырда иде, мин җан тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады.

Бу кеше, атын куеп, өйгә керде дә миңа хитабән: «Әти-әниең кайда?» – диде. Мин: «Ындырда», – дидем. Бу кеше: «Бар, чакырып кайт»,– дигәч, мин тиз генә ындырга җөгереп барып: «Өйгә әллә нинди бер кеше килгән, сезне чакыра», – дигәч, алар хәзер кайтырга булдылар.

Бераздан ишектән әти белән әни килеп керделәр; мөсафир белән күрештеләр.

Чәй куелды. Бу юлы, кунак булса да, чәй янына нидәндер мине дә утырттылар вә, гадәткә хилаф уларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар.

Әтинең: «Ни хезмәт илә килдеңез?» – дигән сөаленә каршы мөсафир: «Менә бу баланы алырга килдем»,– диде.

Бу сүздән әти бик гаҗәпкә калып: «Ничек ул? Ник син алырга килдең?» – дип сөальләр бирә башлагач, мөсафир бу рәвешчә сүзгә башлады: «Мин – Кушлавыч кешесе. Бу бала авылымызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән бихәбәр идек; менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе бар. Менә шул җизнәсе, каенесенең болай кара кешеләр кулында йөрүен ишетеп, аны Җаекка үз катына чакырмакчы була. Менә мин быел Җаекта аның кушуы буенча бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм».

Мөсафирның бу сүзләренә әтинең дә, әнинең дә бик кәефләре китте: «Ярар менә, без икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта аны 3–4 ел ашатып торыйк та, хәзер, эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрик, имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән?» – кеби сүзләр илә бик нык тартыштылар.

Ара-тирә әни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!» – дип куйгалый иде.

Мөсафир Бәдретдин абзый: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга, мин хәзер үрядниккә әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне падсуд җибәрермен», – дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара әти-әни йомшардылар.

Бераздан минем тату тормаган әнием: «Җә, атасы, бирик инде; ахры, кеше баласы безгә булмас, Алла сакласын, әллә ниләр күрермез», – дип үкереп җылап та җибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соңра бераз дулкынланып торган диңгез кеби, актык вә йомшак тартышу белән генә тартышкач, әти дә разый булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми, мине арбага чыгарып утырттылар.

Әти-әни, бичаралар, һәр икесе егълаганнары хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың», – дип, ахыр сүзен кычкырды да без авылдан чыгып киттек.

Минем китү мәсьәләм бөтенләе ярты сәгать диярлек аз вакытта хәл ителгәнгә, авылдагы иптәшләр вә таныш-белешләр илә күрешә алмадым. Алар гафил калдылар.

Без юлга чыккач, күп тә үтми кич булып, караңгы төшә башлады.

Юлда Өчиле карьясенә бабайларга төштек. Анда чәй эчтек.

Бу гаиләнең һәммәсе мин күргәндәгечә бергә торалар, фәкать Саҗидә апай гына кияүгә киткән иде.

Чәй эчкәч, әллә нинди Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты авылларыны үтеп, төн урталарында үземнең туган авылым Кушлавычка барып кердек.

Юлда килә-килә, мин арбада шактый ватылган булырга кирәк, Бәдри абзыйның өенә кергәч тә, эреп йокладым.

Иртә белән торгач, үземне бер кара өй эчендә күрдем. Бу өйнең эчендә табак-савыт, кашык-чүмеч, камыт-эшлия кеби нәрсәләр генә булып, җиһаз-фәлән кеби нәрсәләр бер дә юк иде.

Чәй эчтек, Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14–15 яшьлек бер угылы вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы, вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде.

Чәйдән соң бу өйдән чыгып, аңар каршырак салынган ак өйгә кердек.

Бу инде мин кунган кара өйгә охшамый, стеналары сап-сары нараттан, җиһазлары вә язу өстәлләре авыл кешесе өчен мөкәммәл диярлек иде.

Бәдри абзыйның амбарлары тулы ит, ярма, богъдай, арышларны күргәч, мин аны бу авылның иң бай кешеләреннән берсе икәненә хөкем иттем.

Тагы Камалетдин миңа, күз җитү сәбәпле яме киткән булса да, умарта оялары белән тулган шактый зур бакчаларын да күрсәтеп йөрде.

Мин инде, бер кергәч, бу ак өйдән чыкмас булдым вә шунда куна да башладым.

Кич белән китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел җөләса» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать мин Кырлайда чакта тик «Газизә» вә «Сөбател гаҗизин»нәр генә укыганга, бу китаптагы оят сүзләргә гаҗәпләнәм вә: «Китапта шундый сүзләр дә була микәнни?» – дип, үземә сөаль бирә идем.

Кайчакта мин, шул «Фәвакиһел җөләса» тәэсире илә, Гайшә абыстайның кер юган җиренә – кара өйгә барып, аның белән кычкырыша торган идем. Ул ирләрне мыскыллый иде, мин дә үз нәүбәтемдә хатыннардан көлә идем.

Кая барсам да, мине мулла баласы дип халык башка малайлардан аерганга, хәтта җыеннарда яшьтәш кызларым илә «так-каравыл» уйнау да миңа гаеп булганга, мин үзем дә үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем.

Мәсәлән, берзаман, Бәдри абзыйларга килгәч, минем илә күрешергә Ситдикъ исемле, авылымызның шактый могтәбәр кешесе килде, үзе исерек иде. Миңа килеп сәлам бирде – сәламен кайтармадым, кулын сузды – кулын алмадым.

Сәбәбен сорадылар. Мин шул вакыт «Бәдәвам»ның:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә, һәм син алма... –

дигән бәетен ярдым да салдым. Моңар бөтен Бәдри абзый гаиләсе гаҗәпләнүдән башка минем бу диндарлыгым авылга да җәелде.

Бәдри абзый, мине өенә алып кайткач та, үзе бер эш белән Казанга китте.

Ул анда бер ай кадәр торган мөддәттә мин дә буш ятмадым. Камалетдин илә бергә авылымызның мәдрәсә шикелле бернәрсәсенә барып, сабак укыдым. Күп вакыт кунып укырга да тугъры килә иде.

Хәзрәтләре, ахры, бик «кысып» укыта торган вә кешене «гыйлем» итә торган кеше булган булырга кирәк ки, шул аз мөддәт эчендә дә мин аның көн саен әллә ничәшәр баланы эт урынына кыйнаганын күреп калтырап торганым бар.

Качан да булса бервакыт бу хәзрәт таягының миңа да эләгү ихтималы мине куркытканга вә таң белән, шәкертләр белән бергә куылып, иртә намазына бару бик авыр булганга, эчемнән: «Ай, Бәдри абзый кайтса, тизрәк Җаекка китәр идем», – дип көтә идем.

Берзаман Бәдри абзый кайтты. Миңа яңа бүрек, яңа киез ката, яңа бишмәт алып кайткан.

Мин бу яңаларны бик зур куанычлар илә кидем дә үземнең иске киемнәремнән бүркемне, «бервакыт кайтып карармын» дип, очырмага яшереп саклап куйдым. Бу да гаҗәп эшләремнән берсе булды.

Шуннан соң Кушлавычта берничә көн генә тордык та Бәдри абзый белән Җаекка таба юнәлеп чыгып киттек.

Бер тәүлек кадәрле баргач, Казанга килеп кереп (Печән базары тирәсе булырга кирәк), бер урынга туктадык.

Шул вакыт күрдек ки, безгә таба күзләре яшәргән, куллары җәелгән, сакалы агарып бетә язган бер кеше җөгереп килә.

Бу, минем яныма килгәч тә: «Әле син теремени?! Анаң әле кичә генә сине төшендә күргән иде; әйдә, өйгә алып барыйм; чәй эчәрсең, бездә кунарсың», – дип, мине алып китте.

Өйгә барып кердем. Анда әни каршы алды. Бичара, сагынган икән, ул да еглады.

Минем өчен хәзер чәй куелды. Әти хәрчәүнәдән пилмән алып чыкты; сыйландык. Миннән моңар кадәрниләр күргәнемне сораштылар. Мин дә онытмаган кадәрене сөйләдем.

Бу ата-анамның, мин аерылып торган мөддәттә, этинең сакалы агаруы вә әүвәл Яңа бистәдә булып, хәзер Иске бистәгә күчүләреннән бүтән үзгәреш күренми иде.

Ул кичне шунда кундым. Иртәге чәйне эчкәч, әни мине ләгәнгә утыртып җуындырды. Яхшы кәләпүш һәм кыш көне барачак минем озын сәфәрем өчен кирәкле булган бер тире чалбар кидерде.

Ул мине нумиргә Бәдри абзый янына озатканда, тагы сагынмалык итеп, тәсбихләр вә «Мәрьям ана»лар бирмәкче булса да, мин: «Кирәкми, берсе дә кирәкми, мин бай җиргә барам», – дип, нидәндер кабул итмәдем.

Без торган нумир бик начар да, бик яхшы да түгел, уртача гына бер нумир иде.

Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән икән. Шул сәбәпле Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык.

Ниһаять, безнең көткән Алты-биш Сапыемыз килеп, без торган нумир күршесенә төште.

Ул килеп, берничә көн торгач, Бәдри абзый мине аның нумиренә күчерде дә, үзе, миңа алты данә икешәр тиенлек 12 тиен акча биреп, авылга кайтып китте.

Мин Бәдри абзыйдан тагын бер генә көн торуын үтенсәм дә, аннан бер дә аерыласым килмәсә дә, ул мине төрле сүзләр илә җуатты-җуатты да китеп барды.

Ул киткәч, мин Алты-биш Сапый вә хатыны янында калдым.

Бу – шәһәрдән килгән кешенең киемнәре вә сөйләшүе миңа ят тоела иде.

Мәсәлән, ул сүз арасында: «Мин өлкән кеше», – дип ычкындырса, мин бу «өлкән» дигән сүзне һич аңлый алмый идем.

Алты-биш Сапыйның өстендә якасы вә җиңе камалы төлке тун булганга, «өлкән» кеше дип әллә шундый тун кигән кешегә әйтәләрме? дип тә уйлый идем. Соңыннан, Җаекка килгәч, белдем ки, «өлкән» «олугъ» дигән сүз икән.

Бәдри абзыйдан калган унике тиенгә тозлы балык – вобла һәм симәнкә алып ашадым.

Берничә көн торгач, Җаекка юнәлдек.

Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һичбер яктан сулыш алырга бирмәделәр. Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә, иркенгә чыгаралар иде.

Мин никадәрле: «Җәяү барсам да, тышта, иркендә барам», – дип гозерләнсәм дә, «Туңарсың, җизнәң туңдырмаска кушты», – дип, мине чыгармыйлар иде.

Җизни бу Алты-биш Сапыйга Казаннан әллә нинди бер яхшы чана алып кайтырга кушкан икән, шул чана безнең артка тагылган, һәм, безнең алдан бара торган тагы төрле-төрле йөкләр төягән Җаек кешеләре булганга, без «абуз» йөрүе илә бардык. Шул сәбәпле ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә, тәмам унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып кердек.

Җаекта иң элек Сапый абзыйның өенә төштек. «Монда чәй эчик тә, җизнәңнәргә кичкә илтермез», – диделәр.

Кичкә таба, икенде-ахшам арасында, Сапый абзыйның җитәгендә җизниләргә киттем.

Юлда яшел чапан бөркәнгән бер яшь кенә хатын очрады, Алты-биш Сапый: «Бу – апаең, күреш», – дигәч, моның илә күрештем.

Җизниләрнең өе бер ун сажин гына булыр ераклыкта икән; капкадан кереп, биек-биек баскычлардан менеп, өйнең икенче катына кердем.

## Мич башы кыйссасы

*(Баштан үткән бер эш)*

Мин быел 29 сентябрьдән үк салкынлыктан зарлана башладым. Шуннан бирле икәнлеге язып ташлаган бер бәетемнең түбәндәге тарихтан беленде. Бәет шушы иде:

Номер салкын, якмыйлар бит, арка туңа,
Иртә берлән, киям дисәң, яка туңа;
Авыр да соң иртә берлән тышка чыгу,
Чыкмый хәл юк, чыгасың шул ката-туңа.
Җәйләр үтте, җиттек инде октябрьгә,
Җылылык юк җирдә һәм дә күктә бер дә;
Сентябрьдә син дә бер, ди, мин дә бер, ди,
Миһманнарның якмаучыга үпкә бергә.
Хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын,
Кайгырмый бай, күтәргән дә ята ботын;
Акчам янга калыр, ди ул, якмый торсам,
Барыбер бит җәһәннәмгә үзе утын!

*Туңучы*
*29 октябрь, 1911 сәнә*

Бу бәетләр актык тамчы күз яшьләре булган, ахры; озакламый номерны яга башладылар. Ләкин күзләр беткәч, кояш булудан сиңа ни файда? Миңа шул якмый торган арада бизгәкнең шәбе эләккән. Бинаән галәйһи мин, җылылык-фәлән сизмичә, көне-төне туңуда идем. Бизгәк, мин иртәге чәйне эчеп бетерер алдыннан (сәгать беренче яртыда), көтелгән кадерле кунак шикелле, миңа рәхим итеп, тәнемдә күпме тамыр бар исә, һәммәсен селкетеп, мине хәрәкәттәге поезд шикелле итә иде. Бу дерелдәү никадәр кәеф җибәргеч нәрсә булса да, мин аңар әһәмият бирмичә, чәемне дерелдәгән кул белән ясап эчә бирә идем. Тик бу дерелдәү вакытында күрше марҗалар-фәлән килеп керсә һәм алар минем кул дерелдәүдән купкан «стакан диңгез»ендәге дулкынны күрсә генә, бүлмәмдә тавыш куба иде.

– Батюшки! Что с тобой?

– Лихорадка, разве не видите?

– А у доктора был?

– Пусть сам придет!

Мин бигрәк каты тәгассыбтанмы, нидәндер дөнья күрә башлаганнан бирле медицинага ышанмый идем вә һәр халәткә «нервы расстроены» дигән докторларны һәр авыруны кизүдән диюче әбиләр белән тиңләштерә идем. Шунлыктан, тетрәү көн саен дәвам итсә дә, доктор дип әйткән кешене хәтеремә дә кертмидер идем. Минем хәлне белгән иптәшләр дә миңа күп даруның исемен әйтеп карадылар. Әмма мин лям-ялтәфит. Авырсам, бүлмәмдә бишмәтме, юрганмы, казакимы – һәммәсен бөркәнеп ятам да бер сәгать кадәр заманнан соң тирләп торам. Тир белән авыру чыккан була, чыкса да – мине тәмам алҗыткан була иде.

Көннәрдә бер көн хәстәм килеп, баягы чүпрәкләр астында хәзан япрагы кеби дерелдәп ятканда, берсекөнгә Рамазан гаеде икәнлеге исемә төште. Абау, Ходаем! Мин гаед көнне дә шушылай дерелдәп ятармынмы? Юк, бу һич тә ярамый.

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген! –

дип берзаманнарда җырлаучы үзем түгел идемме? Юк, бәйрәм хөрмәтенә мин докторга да ышанам дип уйлап ятканда, ишек ачылып, бер иптәшем килеп керде.

– Иптәш, кара әле! Син нәрсәне бизгәктән файдалы дигән идең?

– Аспиринны.

– Зинһар, иптәш, шуны алып кайтсана!

Иптәшем даруны алып кайтты. Менә сиңа берсекөн. Гаед җитте. Гаед көн мин йокыдан торып киенгәч тә, бер стакан җылы су белән аспиринны эчтем. Бөтен Казан буе өстерәлеп йөргәнем визитнең берсендә мин тирләдем, шапырма тиргә баттым. Менә аспирин нишләтә! Ул көнне, иртәгесен, аның иртәгесен мин һаман аспирин эчәм. Бизгәк килми иде. Гаед бетте. Корбан бәйрәме җитеп, ул да үтте. Мин һаман бизгәкне, ул килде исә, аспирин таягы белән кыйныйм. Димәк, бизгәк тә аспирин, бизгәк тә аспирин!

Беркөнне бер якын иптәшем килеп керде дә:

– Иптәш, әйдә, фәлән мөсафирханәгә күчәсеңме? – диде.

– Күчәм, – дидем.

Ул мөсафирханәдәге миңа булачак номерны барып карадык. Бу номер әүвәлге номерым кадәр өч бар. Түшәме биек, умывальнигы бар. Әлхасыйль, элек торган номерыма караганда җәннәт!

Тора башладым. Элек өстәлем иң түрдәге тәрәзә төбендә иде. Андагы сыростька сабырым бетеп, өстәлне ишек төбенә күчердем.

Бу әүвәлгедән дә начар. Монда бөтенләй зәмһәрир. Бу – көнаралаш бөтенләй үк ягылмый. Мич ягучы урысны чакырып:

– Почему вчера не топили? – дидем.

Ул колагыма гына:

– Дров не было, – диде.

«Ярабби! Монда да мине кыш көне очырмага элгән каз кеби катыралар!» – фикерләренә киттем. Монда утын булмауга мин тәгаҗҗеб итми идем, чөнки бу номерның нәрсәсенә генә карасаң да, аның фәкыйрьлеген күрсәтә иде. Айлап торучылар булса да, күбесе болайрак. Залына кеше керми. Анда музыка куйганнар. Бөтенләй мужик урыслары күпер суккан төсле уйный.

– Наплевать на все, – дидем дә, беркөнне ямщик яллادым да авылга киттем. Монда миңа кечкенә генә, нараттан салган, сандык шикелле җыйнак, матур бер өй бирделәр. Көненә ике мәртәбә ягалар... Һавасы яхшы, җылы, күңелле. Монда бер 15 көн эчендә 29 сентябрьдән бирле күргән салкын михнәтләре һәм юлда килгәндәге адашулар, туңулар – барысы да онытылды. Михнәт үтсен генә, адәм баласы тиз оныта аны. Беркөнне мин үземнең борадәр муллам белән, тәмам терелгән кеше шикелле, күтәренке бер рух белән авылымыздан ун чакрым җыраклыктагы базарлы авылга киттем. Көннең җылысын сайлаган идек. Бер дә туңмыйча гына барып җиттем. Фатирчы бер карт урыска төштек. Монда бүтән авыл муллалары да бар икән, алар белән сөйләшеп чәй эчтек. Ни сөйләшкәнемезне язмыйм әле. Муллалар һәм минем борадәр әйберләр алырга базарга чыгып киттеләр. Без карт урыс белән икәү генә аулак өйдә калдык.

Бабай белән без элек минем авыруым тугърысында, аннан күчеп бүтән мәсьәләләр тугърысында сөйләштек.

Бабай миңа Александр Второйның крәстияннәргә манифест укып торганын буяп ясаган бер рәсем күрсәтте. Мин карадым да:

– Добрый царь! – дидем.

Бабай терелде. Хөрриятә кадәр солдатларның илле биш яшендәге карт булып, үзләрендә жизнь калмагач кына өйгә кайтканнарын, хөрриятә кадәр мужиклар җәйдә иң элек алпавыт игенен урып, тәмам урнаштырып бетергәч кенә үз җирләренә тотынуларын, вакыт аз калганлыктан, нинди начар һава-

ларда да кырда эшләргә мәҗбүр булуларын вә алпавытның ачуы килгән саен крәстиянне розгалавын вә солдатка тотып бирүен, вә башка золымнарын да бер-бер бәян итте.

– Ә хәзер без кырда үз игенемез бар вакытта, алпавыт көненә алтмыш тиен бирсә дә, аның кырын эшләмибез; алпавыт ялына, бичара, – дип, кәефе килеп, кычкырып көлеп җибәрде.

Ул көлгәнгә мин дә көлдем. Бабай тагы да кызып сүзгә кереште:

– Менә хәзерге көндә студентлар һәм жидләр падишаһымызны безгә хөррият биргән өчен яратмыйлар. Менә әле, ничек исеме, Киевтә бер жид министрны үтерде.

Бабай министр һәм үтерүченең фамилияләрен белми икән, мин әйтеп бирдем. Шул вакыт, белмим нәрсәдән, минем бабайның кәефенә тагы да кәеф кушасым килде дә болай дидем:

– Ие, ул жидләр – начар кешеләр. Аларны Русиядән куасы иде.

– Да, да!

– Без – руслар белән татарлар – һәрвакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз. Әмма жидләр үзләренең биниһая хәйлә вә ялганнары белән безне алдыйлар вә бөтен сәүдәне диярлек кулдан алып баралар. Бозык халык. Безнең Коръән аларны «мәгъзубе галәйһи» дип атый.

– Дөрест, дөрест.

Шул вакыт минем аркамда суык чымырдап тора, вә мин ихтыярсыз, хәзер генә сүнеп, капкачы ябылган мич янында торып кына, бабай белән сөйләшә ала идем. Бераздан, тышка да чыгып кергәч, суык бөтенләй минем тешләрне шакылдатып, Казандагы рәвешчә бөтен тамырларны дерелдәтә башлады. Бабайдан:

– Ятып торырга бер урын булмасмы? – дип кенә йокларга сорап, авыру килгәнне әйтмәдем.

Ул:

– Хәзер генә морҗа ябылды, мич башы бик җылы, – дип, миңа анда менәргә киңәш бирде.

Менеп яттым. Минем тәндәге суык үзеннән көчлерәк эссе белән очрашканлыктан, миңа шундый рәхәт хасил булды ки, тәгъриф мөмкин түгел. Әгәр бай булсам, бабайга аның мич башында яткан вакытымның минутына бер тәңкә бирер идем!

Мич башы рәхәт. Тән пешәргә җитә, аның саен шәп. Шулай рәхәтләнеп ятканда, өченче ел ук бик шәбәеп язган бер шигыремнең бәгъзе сәтырлары исемә төштеләр дә, үз-үземнән кычкырып көлә башладым. Шигырь ушбу иде:

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

«Мич башына менмәм» дим, имеш; менмәссең, аркаң туңса! «Менмәмен мин, Ходай кушса» дип, «Ходай кушса»сын да язганмын лабаса. «Бу нигә көферлегем җитте икән?! – дим дә кычкырып көләм. Көлдем, көлдем дә: – Әйе, шигырь башка да, дөньяны әйләндерүче чыгыр башка», – дип, җитди кыяфәт алып, ишегалдындагы чанага чыгып утырдым. Кайтып киттек.

## Казанга кайтыш

### I

Авылны күпме мактасаң да, аның калада торып өйрәнгән кешене разый итмәслек урыннары табыла икән. Бигрәк кыш көне һәм быелгы кеби ачлык елда. Һәр көн димәсәм дә, бик еш буран. Урамга да чыга алмыйсың. Муеннан кар. Каты буранның икенче көнен безнең авыл башында остабикәсе белән кунактан кайтучы бер мулла аты белән карга баткан иде. Атны чыгарганчы, өшемәсен дип, безнең авыл мужиклары мулланың остабикәсен, үз чаналарына утырган көе, безнең өйгә тартып кайтардылар. (Үзен Япония извозчигында кеби хис иткәндер!)

Быел авылда батканнар да, өшегән-катканнар да хисапсыз булды (ачлык, салкын, ялангачлык – өчесе берьюлы һөҗүм иткәч, адәм түгел, дию дә чыдамас).

**Бәет**

Бу сәнә ачлык җыланы чын халык бәгърен ашый!
Кит, китап! Сабрит, дип әйтмә, – ул халык көчен ашый!

Бу сәнә ачлык сәбәбеннән урманнарда, аулакларда караклар күбәйгән, дип тә күп сөйлиләр. Безнең якта мәгълүм Чыпчык, Балавыз урманнарында фәлән кешене үтергәннәр, фәлән байны талаганнар дигән хәбәрләр атна саен ишетелә. Ләкин мондый хәбәрне сөйләүчеләр һич тә чынга охшатып сөйли алмыйлар.

Мәсәлән, берәвенең нәкыле: «Әлләкеметдин бай Чыпчык урманы аркылы калага кайтып бара икән,

каршыларына өч карак чыгып, ат башыннан тотканнар. «Малыңмы, җаныңмы?» – дигәннәр. Ләкин байның кучеры таза җегет булган». Равинең нәкыленчә, әллә кайсы авылда шактый «җибәргән» дә булган, ди. Менә шул кучер, повозкадагы нуктаны алып, каракларны уңлы-суллы яңакка кыйный башлаган. Караклар качканнар. Ләкин повозка кузгалып киткәч, байның артыннан әллә ничә мәртәбә «либарбир»дан атканнар. Ни булса булган, бай сау-сәламәт калага кайтып җиткән. Бу хикәяне ишеткәч, кучер минем күңелемдә бер Сәет Баттал кеби булып калды. Кавказ тауларындагы «тотылмас» Залим ханны тотарга да шундый бер кучерны нукта күтәртеп җибәрү тиеш кеби күренде.

Нәкыле болай булса да, факты алай түгелдер дип, мин иртәгә иртүк шәһәргә чыгачак сәфәрем өчен күрше агаемыздан бер алтатар сорарга кичтән ният итеп яттым.

Бу, мин алтатар алачак агай, табган үткен, бәдәнән көчле, үз сүзеннән күчми. Бер алачыгы бар; тимер, чуенны үзе эшли, авылдагы вә әтрафтагы сәгатьләрне ул төзәтә. Авылның хөкүмәт эшләренә дә катыша, укый-яза белә. Үз исеменә алдырмаса да, Казаннан «Вакыт»-фәлән кеби гәзитәләр алып кайткалый. Бер тарафтан кибет тә тота. (Бер-ике ел гына элек бу авылда кибет булмаган. Нинди һавага да карамыйча, күрше 3 чакрым җиргә җөгерергә мәҗбүр булганнар.) Менә бу кеше инде сугыш коралларын да карый, мылтык, алтатарны да карый, тубыннан да качмый. Ул элек гармун, скрипкә кеби уен кораллары төзәтсә дә, хәзер аны ташлаган. Чөнки мәзкүр кораллар аркылы аның йортын яшьләр, никрутлар басып, картаеп бармакта булган һөнәрчене тынычсыз иткәннәр.

Минем алачак алтатарым да, минемчә, шунда иде. Ул бирер идеме, юкмы – анысын белмәдем.

Әгәр авылда бу адәм кеби биш-алты гына кеше булса да, авыл күптән инде тәрәккый иткән булыр иде. Яңа укулар мәйдан алыр иде.

**Бәет**

Мәдрәсә дип нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе,
Нәкъ эче азган мөрит, мәҗнүн ишаннар хилкасе.

Чәйниләр монда җирәнгеч әллә нинди мөһмәлят,
Яшь гомерләр мөһмәлят чәйнәп була монда һәлак.

Кайсысы «кәптеркү» ди, һәм кайсысы «каптырку» ди;
Чорт ява знат, нәрсә ди, «сентерсү» ди, «саттырсу» ди!

Кыш буе шул мөһмәлятне ач төя төсле күшәп,
Яз көне туктый укудан һәр күсәк угълы күсәк.

Алларында шунда да Коръән була һәм Әфтияк,
Буш түгел букча – китергәннәр аны көчләп төяп.

Кул керенә былчыраткач Һәфтиякнең һәр битен,
Уртасыннан капкалап, тәмләп кимергәннәр читен...

Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра,
Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора.

Бу – ике дуст, берсенә чөнки аларның берсе тиң,
Бертигез тәгълимнәре дә: берсе – дөнья, берсе – дин.

Ва әсәф! Ачлык вә коллыктан бүтән һич бездә юк,
Шул гаҗәп: ник бу егерменче гасырда – йөздә юк!

Әлкыйсса, инде шигырь язудан туктыйм. Чөнки мине күптән инде, башына сөртергә эзләпме, май таба алмаган бер «критик» сүнгән шәмгә охшатты. Мәхмүт бай мәрхүм кантурында ташландык майлар беткәндер шул!

Шулай да, ягъни әлегә шигырь язмый торсам да, җырлаудан тартынмыйм:

Җырласаң да, җегет, ачы җырла,
Уяу җаткан кызлар җокласын;
Тәрәзәләр ачтым, гөлләр сачтым,
Асыл кошлар килеп чүпләсен.

Әле каләмне куеп торып, кулыма карадым. Тырнаклар шүрәленеке шикелле булган. Болай ярамый, мин аларны кисәм һәм һәрвакыт, һәр җирдә «Сөю – сәгадәт» язган кулны, Алладан оялмый, бәндәдән кызармый: «Кул кисеп бәхәсләшәм», – дип фаш иткән бер критик белән мин «тырнак кисеп бәхәсләшәм». Чөнки «Шүрәле» тырнагы бары «Ялт-йолт»та гына булып, теге критик кулы кеби, теләсә кайда сузылмаганга, кулдан кыйбатлырак инде. Минем белән бәхәсләшүчеләр дә тизрәк табылыр. Пәке дә үткен икән.

«Бәшири мырауламый башлады» – тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Укмаси порнографияләрен сирәкләндерде» – тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Сәгыйть белән Тукай сүнгән шәмгә охшый» – тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Фатихның «Хәят»ы милли роман түгел» – тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Гаязны шагыйрь дисәләр, Третейский судка бирәм» – тырнак кисеп бәхәсләшәм.

Ун тырнакны кисеп тә бетердем – бәхәс тә тәмам булды.

«Әгузе биллаһи минәшшәйтан иррәҗим; бисмиллаһ иррәхманир рәхим». Тырнакларны, кәгазьгә төреп, стена ярыгына куйдым.

## II

Иртәнге сәгать алтынчы. Без мулла белән, Казанга сәфәр өчен, чана түренә чыгып утырдык. Кучер – кучердә. Җул тып-тын. Алдымыз ачык, бер дә җил исми. Әкрен генә исә калса да, каты кар кузгалмаслык. Тик ат борыныннан чыккан сулыш кына минем күземә карауча кеби күренә иде. Шактый җир киттек. Иптәш безнең алтатар алмаганны искә төшерде дә: «Хәер, чана төбенә бәйләгән күсәк бар әле!» – дип гыйлавә итте.

Минем күз алдыма Чыпчык урманы һәм безнең күсәк чишеп алганны сабырлык белән көтүче пычаклы караклар килделәр. Көтсәләр дә гаҗәп түгел, чөнки кыш гаҗәеп мәүсим ул, «Волшебница-зима» ул. Кышның суыгы белән кайчакта кеп-кечкенә колагыңны чабата кадәр ясый алган Аллага безне каракларның куллары каткан чакка тугъры китерүе дә мөшкил түгелдер.

Юлда әллә нинди гаҗиб, тыштан караганда мөһмәл кеби күренгән исемдәге авыллар очрый. Мәгънәсе мәгълүм Тимерче атлы авылны да чыктык. Бу авылның мулласы «Әннәсолул хәдидә»че һәм әллә нинди исемнәр белән ысулы җәдидәгә каршы китаплар чыгарган каһәрмане дин икәнлеген сөйләделәр. Авылны дикъкать беләнрәк карадым. Күрдем ки, моңарчы килгән авылларның һәммәсеннән ярлы, һәммәсеннән чокыр-чакырлы. Өйләренең һәммәсе карчык кеби бөкрәйгән, кайсы ачык, кайсы тишек. Авылның тыш ягында дикъкать итәрлек хәл: бер данә диярлек арыш, богъдай кибәне булмаса да, печән кибәне бик күп дәрәҗәсендә. Моны күргәч: «Мулласы «дин вә мәгыйшәт»че булган бу авылның халкы да печән ашыймы әллә? Һәм «Дин вә мәгыйшәт» айгырларына печән шушы авылдан доставить ителәмикән әллә?» – дигән фикерләр килде.

Көн суык. Аяклар туңа. Безнең чәй эчә торган Чыпчык – һич шунда җитеп булмый. Әллә без барган саен Чыпчык ераккарак оча бара?!

«Көлле атин карибен» мәаленчә, ахырда Чыпчыкка җиттек. Чишендек, чәй эчтек. Бүтән язарлык нәрсә күренмәде. Тик бер ямщик кына, «шәйтанны коткарырга барам» дип, әллә кая барып, эчеп, кәефләнеп кайтты. Аның эчүе түгел, шуны «шәйтан коткару» дигән тәгъбире көлке тоелды. Бу сүз минем башта бәгъзе хыяллар кузгатканга, аны үткән номер «Ялт-йолт»ка рәсем итеп ясарга бирдем.

Чыпчыктан сәгать көндезге бердә чыгып киттек. Теге куркынычлы урман алдыбызда мәһабәтләнеп тора иде. Барып кердек. Ләкин, бердән – көндез, икенчедән – олуг юл атлар белән тулы булганга, күсәк түгел, таяк та кузгатырга тугъры килмәде. Менә Киндерле авылы. Казан күренә. Менә без кич белән гаять биек «Швейцария» тавын менәбез. Корт кук үрмәлибез. Мендек. Өйләргә ут алынган. Күк йолдызлар белән, шәһәр фонарьлар белән бизәлгән. Әле сәгать 7 генә. Кибетләр ачык. Урамда хәят бөтен: «тең-тең» дип шалтырап, эче тулы кешеләрен якты тәрәзәсеннән күрсәтеп, Бельгия ширкәтенең «барабызы» – трамвай һәм безнең татар ширкәте «барабызы» – Гайфулла агай урам уртасында чабышалар иде.

## III

Авылдагы тәфәрред, андагы тынлык миңа тәмам сөекле күренгәнгә, мин Казанга кайткач та шулай япа-ялгыз тору планын корган идем. Фәкать бердәнбер карчыгы булган тыныч фатирда торырга, бер җиргә дә чыкмаска, берәүне дә кабул итмәскә, фатирны да Подлужный тирәсендәрәк эзләргә, ашарга да йокларга, укырга да язарга, сукранмый гына авырырга карар биргән идем. Подлужныйга ук китмәсәм дә, «Йолдыз» әйтмешли, «Икенче чокырский» урамда бер бүлмәгә күчтем. Апалы-сеңелле ике марҗа – хозяйкаларым. Мещанкалар, кабахәтләр, мещанкалар.

Максим Горькийны укыганда – шуларга нәфрәтем,
Кнут Гамсунны укыганда – шуларга ләгънәтем.

Моннан ике ел элек бер мещанкага фатир өчен ай ярымга акча түләп, шуларны сөймәгәннән өйдә өч кенә кич кунганымны оныткан кеби, тагы шуларга барып эләктем.

Айга 8 тәңкә, эчендә аш пешерү дә бар. Итне жумыйлар. Чи иттереп китерәләр. Ашның тозы юк йә тозы күп. Чәйнең чүбе тәүлекләп тора. Чынаяк сарыга каткан. Өстәлең чүплек төсле. Кергән көнне: «Иртәгә караваt кертәбез», – диделәр. Бер атна, буш бутылка төсле, идәндә аунадым, һаман караваt юк. Ана мәчеләр кеби, көне-төне югалалар. Самавырны да бүтән квартирантлар куя. Беркөн сөйләшкәндә, маймыл кеби кыйланып, сүз саен рожа алыштыра торган, авызында алгы бер теше юк хозяйкамны кү-

реп: «Когда у вас кровать будет?» – дигән идем. Ул, әүвәлге вәгъдәсен инкяр итеп, үзенең караватын сатып ала алмаячагын, ярлылыгын мыгырдарга тотынды. Шундук, ялганын тыңлап бетермичә, яныннан качып, иптәшем белән номер эзләргә киттек.

Номер таптык. Әмма яхшы, әмма матур! Исеме дә «Яктылык», эчендә нур. Ул җиһаз! Караватның дүрт читендә – дүрт ялтыраган гөмбәз. Көзгесе дисәң, кыргыз сахраларында ком арасында ярсыз гына җәелгән саф күл шикелле. Ишек ак сәдәфтән ясалган кеби. «Җуынгыч» – мәрмәрнең нәгызе. Язу өстәле бордовый төсле сукнолы, әллә ничә тартмалы. Паркет идәннәре адәм угылы аяк белән басарга оялып, күкрәге белән генә шуарлык. Стеналар әллә нинди шиколад төсле прәннектән коелган кеби. Әлхасыйль, «тәгърифе мөхаль». Әмма «ля нөсәллим» дию кариэмнең иркендә.

## IV

Бу реклам төсле мактау дисәңез, минем «шүрәлинский девизем»:

Теләрсәң кемне сүк син яки макта,
Берәү берлән дә булма иттифакъта, –

дыр. Кич белән тугъры өйгә кайтып, дәшми-тынмый, әйберләрне «барабыз»га чыгарып төйи башладым. Задатка акчамны сорый башлагач, теге ике марҗа, задатканы кайтармау юлында булырга кирәк, шулкадәр колак төбемдә чәрелдәп кычкырырга тотындылар ки, тиз генә колакларны тыгып, актык әйберемне күтәртеп, көчкә качып өлгердем. 3 тәңкә янды.

Номер. Алдан бер айга түләп, үземнең шушы матур урында тыныч кына тора алачагымны хис итү кадәр татлы минутларны оныткандырмын инде. Бер кич кундым. Иртә белән номер үзенә бертөсле матур. Кич белән электрик яктысында тагы бүтәнчә гүзәл. Икенче кич кундым, рәхәт йокладым.

Өченче кичне, мин сиңа әйтим, язу эшләрем белән төнлә утырадыр идем, үземне хикәят китапларындагы «кергән кеше сәламәт чыкмый» торган пәриле җортта кеби тойдым. Әллә ниләр кытырдый. Дикъкать итсәм: күселәр! Ах, Алла дошманнары! Ах, бәндә дошманнары! Ах, генерал Толмачев дошманнары! Алар минем комод эчендәге азыкларымны кимерәләр. Язудан туктадым. Күселәр болай да гасаби булган минем тәмам канымны бозалар. Юк, язып булмый. Аптырагач, утны сүндереп, йокларга яттым. Яныма, күселәр тавышланса, комод өстенә сугып аларны куркытырга дип, юл каешы алдым.

Күзне генә йомасың, караватк каршындагы комод тартмасында күсе кытырдый. Шикәрне көл итә. Булкины кимерә. Аптырагач, каешны алып, бар көчем белән комодка сугам. Аз гына тына. Күзне генә йомасың, тагын шытырдый. Тагын сугам, тагын сүгенәм. Аптырагач, әйтәм: «Әй, карак! Беләм инде, син, бичара, ач үлмәс өчен мондый кыюлыклар илтизам итәсең; соң, әкренрәк ашасаң булмыймы инде? Мин синнән аш кызганмыйм, чөнки мин ашны син җитә алмаслык урынга яшерсәм, ачлык сине минем колагымны вә борынымны кимерү кыюлыгына да мәҗбүр итәчәк», – дим. Ләкин: белә әтәч синең хәрфе җәреңне! Ул һаман үз эшендә. Менә сиңа матур номер! Иртә белән ак майда да күсе тәпиләре эзен күрдем. Юк, моңар чыдар хәл юк, китәм, бүгеннән үк песи эзләргә китәм!

## V

Иртә белән «барабыз» белән барам. Ат очрый – песи очрамый, эт очрый – песи очрамый, кәҗә очрый – песи очрамый. Мөхәммәтҗан хафиз очрый – песи очрамый. Зур корсаклы татар байлары очрый – песи очрамый. Ул көнне кичкә кадәр йөрсәм дә, песи таба алмагач, номерыма песисез кайтмаска булып, кунарга Әрмәнскидәге иптәшләремә киттем. Йокыга яттым. Менә кандала! Менә кандала! Һәр чәнчүендә бер кашык кан ала. Торып ут белән карасам: ак мендәрнең тышы, гайре мөтәнаһи вак үрнәк белән чигелгән кеби, бихисап кандала белән тулган! Йокыдан өмид өздем. Иртәнге сәгать сигезгә кадәр ут белән утырып, өстәлдәге һич бүтән чакта кулга да алмаслык чепуха китапларның һәммәсен укып чыктым.

Минем йөрү оборотым болай булды: күседән качып, песи эзләргә чыгып, табалмыйча, кандала ияртеп кайттым...

Башыма шәп фараз килде. Мин үзем мәче булырга уйладым. Беркөн кич аякка киез итек һәм өсткә, эчен тышка әйләндереп, тун кидем. Башта да эче тышка чыгарылган бүрек иде. Тунның арт итәгенә мунчаладан койрык төсле бер нәрсә тактым. Бервакыт мәчечә кычкырып, номерымда репетиция ясарга тотындым: «Мияу», «мырау», «мәааауу», «моррраууу!»

Үземә бик яхшы, бөтенләй мәчечә тоелганга, мин төн уртасында, һәйбәтләп аяк бөкләп, күсе чыга торган тишек янына утырдым. Менә мияулыйм, менә мыраулыйм!

– Мияу, мырау, мәааау, морррау!

Бервакыт мыраулаудан туктап карасам, күселәр тишек эченә бөтен гаиләләре белән җыелганнар. Аларның үткен тешләре аркылы минем мыраулавым хакында түбәндәге рәвешчә мөхакәмә сүзләре ишетелә:

– Менә Камил Мотыйгый! (Шырык-шырык көләләр.)

– Җә, әле без акча биреп тыңламыйбыз, әле Камилнең моннан начар концертына адәмнәр акча да түләделәр.

– Плохой артист!

– Шунда да «чалбарчылар»дан артык.

– Мәче, имеш!

– Безне куркыта, имеш!

Мин, боларның үземне мөхакәмәләрен вакытча кисеп:

– Йа әйеһәл-каумел-күсиюн! Ля тәнзыру иля мән мыраулый вәнзыру иля ма мыраулый!

– Ничек синең үзеңә карамаска, адәмчә тырнакларыңны да баягы бәхәстә кисеп ыргыттың... битең дә шоп-шома; мыегың да юк, үзең дә зур.

Байбәтчәләр шикелле мактанып әйтмим, мин дә усал бит, менә аларга нәрсә дидем:

– Әй, күселәр! Сез нигә минем локъмәмне ашыйсыз? Ник интендант булмыйсыз? Ашасаңыз, корсакларыңыз яхшы күперә бит; килешле булыр иде.

– Син безне, идән астында яткач та, бернәрсә белми дип уйлыйсың икән (гомуми хахылдап көлү). Бу җылларда интендантларны тимер капчыкка утырталар аларны. Менә Казанда, Киевтә, Петербургта...

– Хәбәрдар халык икәнсез. Ихтилалчыларның рухы төшкәч, әллә «идән асты матбугаты» бөтенләй сездәме?

Бер күсе, күкрәген киереп:

– Бездә шул, бездә! Нишләтмәкче буласың?

Икенчеләре, мине кызганышып:

– Әмма үз ролеңдә булмаган кеше кәмит соң!

– Миңа нишләсәм мәгъкуль булыр, критик әфәнделәр?

– Язуыңны яз. Карт чиновник шикелле борчылма.

Бу сүзләрдин соң мин, аларның сүзен җыкмас өчен, ушбу озын кыйссага хатимә итеп, түбәндәге бәетләрне борчак кеби тездем:

**Гыйбрәт вә нәсихәт**

Номерың матур булса, күсе булгай,
Һәр матурда начар якның берсе булгай;
Ансы булып җитмәсә дә, монсы булгай, –
Андин җыртык, мондин җыртык туннарым бар.

Бер адәмнең чын дошманы күсе булгай,
Икенчесен җөдәтүче кеше булгай;
Һәркемнең үзенчә бер эше булгай, –
Андин сүтек, мондин җыртык туннарым бар.

## Мәкаләи махсуса

### Беренче кисәк

Мөхәррир әфәнде мине орышып яза: «Казаннан киткәнеңә икенче ай инде, бернәрсә дә язмыйсың, идарәгә бер мәкалә дә җибәрмисең...» – ди.

Соң инде, әфәндем, үзең озата төшкәндә, «Фультон» пароходының эсселеген вә «сәйяр мунча» дияргә ярарлык булганын, минем шуңар никадәр куанганымны күрдең бит. Пароход кузгалды. Син чыгып киттең. Мин каютның ләүкәсенә мендем дә яттым. Шуннан бүтән нәрсә языйм? Мин яныма каләм, кара да алмаган идем. Һәркем үз кайгысын язарга рөхсәт инде. Арка туңу мәсьәләсен кыш көне бер кәррә язган да идем.

Әле Гаяз әфәнде рисаләсендәге «Сөннәтче бабай», аркасы туңганлыктан гына, арка җылытырга бер хатын алган, ди. Мин ул китапны үзем укымадым, укыган кеше генә сөйләде.

Укырга, мин Гаяз әсәрләреннән куркам да. Беркөн, соңгы китапларыннан берсен укыган тәэсир бетмәс борын, мәхәббәт хакында бер нәрсә язган идем, гөнаһ шомлыгына каршы, язганым ушбу рәвешчә булды: «Берзаман үгез, сыеры бар бер агайның капка төбенә барып, авызын күтәрде дә, мәхәббәт һәм нәзек хиссият белән, ишегалдындагы бозауга хитабән:

– Әниең өйдәмүүүһһһ? Әниең өйдәмүүүһһһ? – дип кычкырды.

Бозау җавабында әкрен генә:

– Өйдәәәәммм, – диде.

Шуннан соң гашыйк садыйк маңлай сөңгеләре белән капканы төртте дә эчкә тәшрифе кадәм боерды».

Димәк, мин язалмыйм; әгәр материалыңыз булмаса, мәсәлән, Һинди Минһаҗ дарелфөнүн акчасына «Дөньяда җәннәт вә аның хурлары» ясап ята, ди. Шуны языңыз.

Беренче апрель көнне Җиңги Садыйк кибетенә әллә кем алдап автомобиль китерткән, ди. Шуны языңыз. Кяфер арбалар дин мәсхәрә итә, диеңез. Шуны языңыз.

Теге, яз көне Иделнең күперен ватып, миллионнарча зарар иткән зур бозны Каф тавы артыннан Дәҗҗал мәлгунь безнең шәһәргә җибәргән, имеш. Дәҗҗалның болай каты күңеллеләнүенә Казаннан чыккан «Дәҗҗал» атлы пьеса сәбәп, имеш, ди. Дәҗҗал мәлгунь мәзкүр пьесада үз усаллыгының бер кешегә ике бутылка кара сыра эчерү белән генә беткәнлегенә гаять тә кәефе киткән, ди. Маңлаендагы чынаяк чаклы күзе, акаеп, табак чаклы булган, ди. «Нигә Мефистофель вә демоннарны үз дәрәҗәләреннән төшермичә, көчле итеп, чын усал итеп язалар да, мине кара сыра эчертүче дип кенә сыйфатлыйлар», – дип әйтә, ди. Боз әждәһа сурәтендә, ди. Казан городской галавасына хат язган, ди. «Күперне ваттырасың килмәсә, кызыңны бир!» – дигән, ди. Городской галава, дуст-ишләре белән киңәшкәч, әждәһага (бозга) каршы мөселман итчеләреннән иң тазаларын сайлап, балта күтәртеп җибәрмәкче булган, ди. Үзеңез ялганыз да, ялганлаштырыңыз да, шуны языңыз.

Казанда бер зыялы мәрхүм Әхмәтҗан абзыйны милләт хамие, дин атасы, хәдис көтүчесеме, нәрсәләр дип мактаган, ди. Шуны языңыз.

Лөгатьче Хәсән Гали Казан дигән сүзнең ата казлар җәмгысы икәнен кәшеф иткән, ди. Ягъни фарсы җәмгысы дип әйтә, ди. Казан татарча дип әйтә, ди; Казан фарсыча дип әйтә, ди. Чорт ява знат, нәрсә дип әйтә, ди. Шуны языңыз.

Казанда бер хәрчәүнәче үзенең пәрәмәч сата торган номерларына «Амур» дип исем кушкан. Вәхәлбуки «Камыр» дип атау тиеш иде. (Аның да тараканлысы.) Шуны языңыз.

«Ялт-йолт» дигән сүз безнең журналга исем булырга ярамый икән. Шуны языңыз. Көлке журналларга үлгән шагыйрь вә мөхәррирләр исемен куярга кирәк икән. Мәсәлән, русларның «Будильник», «Оса», «Сатирикон», «Стрела», «Осколки», «Весельчак», «Попрыгунья-Стрекоза» исемнәрендә олугъ шагыйрь вә мөхәррирләре булган икән дә, алар, шул бөекләр рухына дога булсын дип, мәзкүр исемнәр белән көлке журналлары чыгаралар икән. Баштук мәдәни кавемнәргә бер нәугы мәмдух тәкълид белән ияргән «Акмелла» мискиннең ахыры нишләп сүә хатимәгә терәлсен?

Мөхәррир әфәнде! Әле минем авырудан башка эшем юк. Бер зур эш эшләгән шикелле, әллә кайларга барып авырып йөрим. Авылда авырдым, Казанда авырдым, Самарда авырдым, Уфада авырдым, ахирепәмер, патша тора торган шәһәргә – Петербургка барып авырдым. Троицк халкы да күрми калмасын дип, монда да авырыйм. Ләкин монда эш шәп. Терелермен кебек. Терелсәм, әллә нәрсәләр язармын әле.

Әлегә хушыңыз.

### Икенче кисәк

### I

Ләүкәгә менү бәхтиярлыгының икенче көнендә бугай, төнгә табарак Самарга җиттем. Ярдагы извозчикка: «Мине бигүк начар булмаган бер номерга илт», – дидем. Извозчик, әллә минем тышкы кабыгым чибәр булганга, әллә үзенә якынлыктан, Самарның безнең «Воскрәсән»емез кеби яхшы урамындагы - «Бристоль» номерына туктатты. Бинасы гаять мәһабәт, ишеге койма кадәрле зур, кыйбатлы пыяладан булганга, уңымнан, сулымнан шәһәрнең хисаплаулы публикасы үткәнгә, бу номерга керүдә тәрәддед иттем. Тик җүләр балык шикелле торам. Читтән караган кеше Саламторханның патша сарае янында торуын исенә төшергәндер.

Акылым тиз үк житеште:

– Син Самарда начаррак номерга төшсәң, бер атна тормакчы идең, «Бристоль»дә исә бер генә кич кунарсың; син бит Казаннан, аның юеш һавасыннан качып кына чыктың, Самарны яратып түгел, ягъни «ля лихөбби Галиин биллибогзый Могавия». Төрекләр: «Бер көн шаһлык – шаһлыктыр», – диерләр...

Шуннан соң тәүлеге 1 сум 25 тиенлек иң арзанлы номерына кереп урнаштым.

Караңгы булды. Ут янды. Ләкин кыр зурлыгы номерда япа-ялгыз утырырга күңелсез. Извозчик белән Фатих әфәнде Мортазинга киттем. Извозчиктан:

– Мулла ерак торамы?

– Вот, за углом.

Чынлап та, бер чатны борылсак, Фатих әфәнде капка төбендүк тора икән. Дәгъвәт иттем. Бер сәгатьтән килмәкче булды.

Кайтып самавыр сорадым. Фатих әфәндене көтәм. Әмма эчемне бер нәрсә тырный... Ходай орган извозчик шул бер чатлык җиргә бер тәңкә алды бит! Әле номерга кереп җитмәгән, 2 сум 25 тиен – выжжжт! Менә ничек булды.

– Самарның мулласын беләсеңме?

– Беләм.

– Шунда күпмегә алып барасың?
– Илле тиен.
– Таксача күпме тиеш?
– Кырык тиен; ну, бер ун тиен арттырырсыз инде.

Риза булдым. Бер чаттан барып, икенчесеннән алып кайтты да, мин, ди, ике конец йөрттем, ди. Бер тәңкә кирәк, ди. Нишлим? – бирдем. (Бу вакыт муллаларның дәвере исемә төште.) Чәй янында кайгырып утырам. Ник полицийский чакырмадым? Ник 50 тиен генә биреп кереп китмәдем? Вә әсәф! «Икътисад» мөхәрриренә барганда, шундый икътисадсызлык эшләдем бит! Соңыннан таксаның 25 тиен генә икәнен белдем.

## II

Вәгъдәсендә Фатих әфәнде килде. Бик озаклап һәм төрле мәсьәләләр тугърысында сөйләп, тәмам төнге уникене җиткердек. Фатих әфәнде тыныч кич теләп китте. Иртәгә миңа вокзалга барырга вә озатышырга бер шәкертен җибәрәчәген вәгъдә итте.

Фатих әфәнде тыныч кич теләсә дә, минем күңел тыныч түгел, йокы килми иде. Чәй урынын җыярга звонок бастым. Марҗа килде. Аңар йокы килмәгәнлектән, эч пошудан зарландым.

Ул номерда тоташ первоклассный ресторан барлыгын, анда номер коридорыннан эчке кием белән керергә мөмкинлеген сөйләде... Ресторанның первоклассный булуы миңа ошамады. Мин андый ресторданнарны яратмый торган идем. Чөнки Казанда шуларның швейцарлары, кием начарлыктан, бер-ике мәртәбә кертми җибәргәннәр иде. Шул заман ук ресторан ишекләренә тыштан йозрык селкеп киткән идем. Көннәрдә бер көн шундый ресторданнарның берсенә бер иптәшем берлән бардык. Ишеген ачкач та, швейцар, безгә күзен акайтып:

– Вас не пустим!
– Почему?
– Одеты неприлично.
– Чорт с вами.

Без мәэюс-мәэюс, мәхзүн-мәхзүн чыгып киттек. Юлда иптәшем бер хәйлә корды:

– Әйдә, – ди, – мин синең фуражканы киим, син минем бүрекне ки, – ди.

Мәгъкуль, шулай иттек, тагы ресторан ишегенә бардык. Безне инде икенче кешеләр дип белерләр дип уйлыйбыз. Швейцар, ишектән башын гына чыгарып:

– Вам сказано, господа! – диде.

Иртә белән торгач, иптәшем белән кичә кичке хәйләбездән шундый көлештек ки, хәтта «Болгар» стенасындагы тараканнар, көлкедән эчләре катып, идәнгә шап-шап егылып төшәләр иде.

Хикәят бетте. Әлхасыйль, Самар киченең иртәсендә кесәмдә акчам сәламәт, башым сау көенчә уяндым.

Шәкерт үз вакытында килде. Әйберләрне төреште.

Без икәү резиналы фәйтунга утырып, Самарның ат аягы «ләп-ләп!» итеп кәефне китереп бара торган асфальт урамы белән вокзалга юнәлдек. Юлымызда атлы вагон – конка очрый иде. Зур шәһәрләрдә трамвай күреп өйрәнгән күзгә бу конка бик хәкыйрь һәм көлке тоела иде.

Конка янымнан үтсә, мин андагы пассажирларның сакал-мыексыз кешеләренә карамыйча, бигрәк сакаллы сабыйларга күзем төшә иде. «Оялмыйча, сакалларын салпайтып, шунда утырып баралар бит!» – диясе килә иде. Кыскасы гына, көлкегә калган бу нәрсәне тотасы да балаларга бирәсе! – дигән фикер хәтергә килә иде. Конкага җигелгән атлар җан авырттырырлык кызганыч вә теге сакаллы сабыйлар тарафыннан мәзлум тоелалар иде. Бу бөтенләй чебенгә сука җигү булып күренә иде. Вокзалга барып җиттек. Вагонда бер урысның слойка белән тозлы кыяр ашавыннан башка бернәрсә дә кызык тоелмады. Уфага барам.

## III

Уфага җиттем. Тау башында тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым. Ләкин бу инде Самарныкы түгел иде. Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем, такта арбага буш салган дилбегә кеби, үрле-кырлы сикерә иде. Таудан акрынлап менәсең. Җулның әтрафында җәһәннәм кеби тирән чокырлар хисабы юк. Җәһәннәмнәрнең тирәсенә саклык өчен тезгән баганаларның арасы бик сирәк булып, арба янтайса, мөкиббән галә вәҗһиһи җәһәннәмгә төшү бик мөмкин иде.

Уфага кергәндә, бер дә шәһәргә кергән кебек булмый. Әллә нинди ачык-тишек вә рәтсез һәм пустынный урамнар белән барасың. Эч поша. «Кая соң моның шәһәрлеге?» – дип сукранганда, көчкә беркадәр яхшырак урамнарга кердек. Шулай барганда, «Сабах» көтепханәсенең ак вывескасы күренде. Тугъры анда туктадым.

«Сабах»ка килүдән максудым, Самардагы кеби, бер «Бристоль»гә барып әләкмәскә, ягъни нинди номерлар ничек булачагын сорашу иде. Ләкин, күрдем ки, магазинга тоташ шундый киң вә яхшы бер

квартир бар, монда мин түгел, миңа тагы 19 кеше кушсаң да сыярлык иде. Җитмәсә, аның асты кухня булып, һәрвакыт астан җылы бәргәнлеге беленде. Менә рәхәт! Менә икенче ләүкә! Монда китап төялеп килгән гайре мөтәнаһи ящиклардан карават ясау вафли пешерү шикелле тиз. Аста ящик булса да, өстенә йомшак вә матур нәрсәләр каплагач, ярый ул: өстеңдә әйбәт кием булгач, синең бәрәңге генә ашаганыңны кем белә? Урамга чыксаң, мыекны кашыктагы май белән майлап була. Дөнья яратылганнан бирле ялганнар күбесенчә тотылмый калган. Бичара Рәшит казый гына, микадо мөселман була дигән булып, һәммә татар галәмен алдый язган иде. Ләкин «Тәрҗеман» мөхәррире чыгып, Рәшиткә: «Баба, кашыктагы мыек майлый торган маеңны песи ашады», – дип, оятлы итте. Мин фәкыйрь дә, татар вә исламга гаид эшләрдә «чебен тимәс чер итәр» бер кеше булганымнан, «Японияне мөселман идәчәк голяма нәрдә?» сәрләүхәле бер шигырь язган идем.

Квартир гомумән күңелле. Кеше күп килә. Эч пошарлык түгел. Монда һәр көн мөхәтдисе кәбир Әхмәтфаиз Даутов белән күрешәбез. Ул скрипкәдә маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый җыруны бөтен гомеремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голүвиятен изһар итә. Мин Латыйповны ишеткәнем юк, ләкин Камил бушбугаз кебиләрне бу җирдә телгә алырга да хурланам. Петербург профессорлары хәзер башкорт халкының бик тиздән мөнкариз булачагына иман иткәннәр. Башкортларның гадәт вә әхлакларын язып һәм кием вә зиннәтләрен музей өчен тикшереп ятмакталар икән. Әгәр Фаиз әфәнде кеби чын башкорт рухы вә башкорт моңы белән җырланган җырлар да граммофоннарга алынып калса, моның башкорт инкыйразыннан соң азмы әһәмияте булыр иде?! Ләкин милләтемез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өсткә кала шул.

Дикъкать итәсезме? Хәзер граммофонга җырлау фахишәләр вә әнвагъ эшсез, ашсызлар кәсебе булды. Казанның «Кәҗә Маһи», «Подвал Фатыйма», «Этле Хөсни», «Җиңгәчи кызлары»на кадәр, төрле шәһәрләрдә граммофонга җырлап, милләтнең сәмгын мәсхәрә итеп бетерделәр. Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй! Фахиш мәгънә! Менә шулар безнең фахшиятсез, пакь мөселман түрләренә кереп утыралар. Түрдә утырып, граммофоннан сүгенәләр. Мин Казанда, Әстерханда әллә ничә граммофоннан шуны уйнатучы гаилә әфрады өчен кызарып утырдым. Алар минем кәефемне ачарга граммофон боралар иде. Мин исә чыраемны сытып утыра идем. Чөнки алар миңа шикәр дип, үзләре белмичә, ачуташ каптыралар иде.

## IV

Уфаның мәгъмурият ягы Казаннан күп начар булса да, табигать ягы күп шәһәрләрдән өстен. Әүвәл үк ул тау башында. Димәк, җәй көне дә, кыш көне дә һава яхшы. Җырларымызда шулкадәр күп җырланган Агыйдел буенда. Шәһәр эчендә йортларга караганда агачлар күп диярлек. Моның җәй көнеге әһәмияте! Өстән караштa Уфаның халкы да айнык вә саф күренә. Чөнки бу шәһәрдә чат саен халык саулыгын химая итә торган сөт кибетләре. Һәммәсендә халык. Пивнойлар сирәк. Бу шәһәр «ай-һай, Казанның каласы, аза ишан баласы» түгел. Сөт сатучылар, мендәргә утырган мулла кеби, үзләре хезмәт итмиләр. Сөт эчүчеләр үзләре буфеттан сөт алып килә. Чөнки мулла сиңа Коръән укыта, дин өйрәтә, сөтче дә сәламәтлек бирә, алар нишләп хезмәт итсеннәр! Мөселман буласың килсә – дин өйрән, сау буласың килсә – әнә сөтне үзең барып ал! Монда трактир официантлары кеби рия, нифакъ вә посетительгә ярарга тырышып кыйлану күренми.

Фәлсәфәгә кердем... язам, язам – кая көлкесе; урман, урман – кая төлкесе?!

## V

Әйе, урманның да бөтен җирендә төлке булмый, мәкаләнең дә һәр сәтырында көлке булмый. Актар агач араларын – бардыр төлкесе; укып чык бөтен караларым – бардыр көлкесе.

Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мосахәбәмез күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек – әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек – әле күздән яшемез дә кипкән.

Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән...

Әйе, әле күздән яшемез дә кипкән. Киләчәктәге шатлык яки ерак, яки юк.

Уфада шактый заман торсам да, аның эчен вә әтрафын карап җөри алмадым. Мәҗит белән йөрергә чыксам да, ярты юлда хәл беткәч, өйгә борыла идек. Монда трамвай юк. Извозчикта эч кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде.

Шәһәр бакчасында борадәран Кәримевләрнең «Йолдыз» исемендә кинематографлары бар. Көннәрдә

бер көн Кәримевләр, әлбәттә, үзләре сизмичә булырга кирәк, кинематографларында «Мөхәммәт оҗмахы» дигән нәрсәне күрсәтмәкче булып игълан тараткannар. Бу хәлне сизгәч, Уфага яңарак килгән бер «зыялы» мәсҗедтәге картларга Кәримевләрнең шундый начар эш эшләячәген сөйләгән. Картлардан хәбәр халыкка да таралган. Халык кызып, витринадагы афишаларны җыртып, Кәримев кешеләрен кыйнарга да уйлаганнар. Ләкин Кәримевләр ни дип җавап биргәннәр?

Наданлык сәбәпле көфергә төшү җиңел инде:

Алар, без белмәдек, дип зари кыйлды,
Гөһәрләр күзләреннән җари кыйлды...

Әлкыйсса, мәзкүр нәрсәне күрсәтмәгәннәр.

Хәзергә җитәр әле.

## VI

Өстән генә ләктереп китү тарызын алган мондый сәяхәтнамә өчен Уфада артык нәрсә күрмәдем бугай.

Хәер, шәһәр бакчасында, өстенә җөббә, башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка «батинкә», авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкертне туктатып, җүри, «вәкарь вә мәһабәтен» бозар өчен: «Син курай уйный беләсеңме?» – дип сорыйсым килде. Мин үзем, гомумән, шундый «кәмитле» мәһабәтлекне бозудан ләззәт табам. Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек аның «вәкар»ен бозарга кирәк.

Бу – өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кеби кагыйдә инде.

Андый «вәкарь» яшьлектә җимерелмәсә, бәгъзан мөхәррир булып гомер итеп, неграмотный үләчәк «зате галиләрдә» дә кала. Мисал эзләсәңез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез.

Әле апрельнең әүвәлге яртысы гына җитә. Минем өчен көннәр әкрен кичәләр. Апрельнең әүвәл ягыннан, «әүвәле Коръән»нән чыгалмый җөдәгән малай кеби, мин дә үтә алмыйм. Малай, хәлфәсе сизмәгәндә, сабагын «сикерткән» кеби, мин дә күп йоклап карыйм. Ләкин максады аслый булган кымыз сезоны җитми. Уфада кымыз юк.

Дөрест, мин кымызны Уфада да, әтрафында да эчәчәк түгел. Мин аның өчен Троицкигә барырга Казаннан ук карар биреп чыккан вә йөзләп баш бия саудыра торган бер Троицки кешесенә барасы, кымызны савылган урынында чатыр корып эчәсе кеше. Чөнки Уфа әтрафын европалылар басып, биттабгы, андагы кымыз искусственныйланганыннан (җәгъли) хәбәрем бар иде. Ләкин Уфада кымыз да булмаганлыгыннан, Троицки «кусагасылары»ның да «бия байламаганлыгын» истидлял итә идем.

Шулай ни ары, ни бире булып торганда, кесәмдәге Петербургка мине чакырып язган бер хат исемә төште. Бу хат инде беренче түгел, берничәнче иде. Буш та түгел, җитди иде. Ләкин, җитди булса да, мин Петербургка баруны көзгә, кымыз эчеп хәлләнгән чакка кичектермәкче идем. Юк инде, Петербургка хәзер барам. Кымыз да булмагач, Уфада нәрсәгә ятыйм. Җитмәсә, аның «авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем әле хасил булмактагы европалылыгымны, культурный шәһәр кешеселегемне, шау-шу яратучылыгымны, галәбәлек, көрәш сөючелегемне үчекләгән кеби булды. Китәм Петербургка! Кымызга кадәр торам. Телеграм, ответ. Киттем.

## VII

Иртә белән сәгать сигез. Менә сиңа Петербург. Николаевский вокзал. Кечкенә чакта Бәдигыльҗамалны эзләп барган Сәйфелмөлекне укыганда, Сәйфелмөлек барган пәри шәһәре әллә нинди тып-тындыр, җеннәр үз шәһәрләрендә күренеп йөрсәләр дә, безгә күренмәгәндәге кеби, тавышсыз йөри торганнардыр һәм әллә нигә ул шәһәр томанлыдыр, караңгыдыр кеби тоела торган иде. Күккә, баскыч куеп, фәрештәләрнең серләрен урларга менә торган җеннәрнең өйләре дә күз җитмәслек биек була торгандыр кеби сизелә иде.

Вокзалдан чыгып, извозчикка утыргач, миндә дә шул хатирә яңарды. Шәһәрдә бер тавыш, шатырдау, дөбердәү юк; үзе караңгы, томанлы; агач түшәгән урамда, резиновый шинле йомшак фәйтунга утырып барганда, бөтенләй калын киез итек киеп барган кеби буласың.

Ул өйләрнең биеклеге! Чорт белә: күгең кайда да, кояшың кайда! Болытмы, аязмы? Бернәрсә күренми. Бу шәһәргә керүне Уфага керүемне язган кеби язалмыйм инде. Гакылым хәйран.

Мине шәһәрнең мәһабәте баскан. Барысы бертөсле агач түшәүле урамнар. Конкалар уза. Алардан Самардагы кеби көләсе килми. Чөнки трамвай да шундук, артындук автомобиль дә! Өйләрнең номерларын санап барам. Менә «Сергеевская, 81».

Шып... туктадык.

Звонок бастым. Әле һаман иртә булганга, Муса әфәнде йокысыннан хәзер генә торган иде. Чыгып кабул итте.

Ишегалды эчендә, бөтен дөньяны вә Петербургны күрсәтми торган сәдде Искәндәрләр кеби стеналар арасында бер квартир. Үзе кешегә зәхмәт бирү дәрәҗәсендә артык югары түгел. Дүрт-биш бүлмәле, шәһәренә күрә якты да. Муса әфәнде рәфыйкасе вә бала-чагалары белән шунда торалар икән. Мин түр бүлмәгә кереп урнаштым. Чөнки минем хәбәрем тизлектә вә телеграм белән генә килгәнгә, табигый, минем өчен номер-фәлән кеби махсус бер урын хәзерләнмәгән.

Мин Муса әфәнденең эш бүлмәсендә (рабочий кабинет). Бүлмә әнвагъ гарәби китаплар белән тулы. Язу өстәле бер көн, өченче көн, кичә, аннан элек, әле генә язып ташланган материалларга күмелгән. Муса әфәнденең иртәге чәе дә, көндезге ашы да, кичкесе дә язу өстәлендә эш арасында, между прочим гына, ашалып эчелә.

Петербург – мәгариф урыны. Анда гакыл биналары да шул пәри йортлары кебек биек. Анда гыйлем урамнары да шулай пакизә вә тәрбияле. Көндезнең әллә кай сәгатьләрендә, кич белән төн буе, әллә кайда, әллә нинди лекцияләр, укулар...

Муса әфәнде шулар артыннан да җисмани вә рухани көче җиткәнчә йөгерә. Аңар көн җитми, төн җитми. Ул таң атарда мәзкүр урыннардан кайта. Между прочим гына йоклый. Тагын иртүк тора, укый, яза, тагы җөгерә. Между прочим гына идәндә җөргән берсе-берсеннән бер илле генә биек кечкенә балаларны сөеп, җуатып ала.

Менә шул фәгалиять, шул эш арасында, җитмәсә, Муса әфәнденең үзе ята торган караватында мин авырып, җөткереп, гадәт буенча папирос тартып ятам. Муса әфәнде минем белән ләкъләка сатарга аз бушагач, бу кабинетта үземә-үзем уңайсызлык та сизгәч, минем көннәр, табигый, тагы авырая төштеләр.

Ихтыярсыз минем исемә Петербургта үземә бер номер алып тору төшә. Бу мәсьәләдә мин Муса әфәндене борчырга уйламыйм. Петербургта минем бишәр еллык иптәшләр: Кәбир Бәкер, Габделкәрим Сәгыйтевләр бар. Номер табышыр өчен дә, сагынганга да шуларны хәтерлим. Ләкин алар Муса әфәнде ханәсенә килмиләр икән. Билгеле, килгәнемне ишетмәгәннәрдер, ә мин инде бишенче көн Петербургта! Муса әфәндедән мәзкүрләрнең адресын вә «Нур» идарәсен сорыйм – ул белми.

Шулай аптыраганымда, бишенче көнне кич, бер студент килеп, Сафа әфәнде Баязитовтан миңа дәгъвәтнамә тапшыра. Дәгъвәтнамәдә адресы бар. Иртәгесен иртүк Сафа әфәндегә барып, «Нур» идарәсендә кичә уйлаган иптәшләрне күрәм. Хәлне сөйлим. «Казанская»дан әгъля бер номер алабыз. Номер тәүлеге самавырдан башка ике ярым. Чынлап та әгъля коридор, очыннан урамга кадәр хәтфә палас. Мин аның коридор вә баскычына «Муромцев юлы» куштым. Невский проспектка якын. Гүзәл урамда.

Менә монда аулак, теләгәнчә авырып ят. Мин барганда, «Нур» чыгачак көннәр тугъры килеп, Кәбир Бәкергә эш муеннан булса да, Сафа әфәнде аның урынына вакытча бүтән бер кешене язарга бәйләп, аны минем белән булышырга вә гәпләшергә «сәрбәст быракты». Менә Шакир әфәнде Мөхәммәдьяров килеп чыкты. Менә укучы яшьләр, мөгаллимнәр, менә Габделкәрим Сәгыйтев. Инде монда күңелсезләнергә урын калмады. Чөнки минем бүлмә чирек сәгать тә кешесез тормый. «Нур» идарәсенә барабыз. Сафа әфәнде анда гәзитә мәкаләләре тәртипли. Шул арада наборщиклар килә. Мәкалә сорыйлар. Хәзерләнгән бернәрсә юк. Чөнки без берничә кеше, аны онытып, аш ашап, фәлсәфәләр сатып утырабыз. Чөнки яңа килгән кеше булганга, мин үзем гәзитә, үзем мәкалә булып киткәнмен.

Шулай да мин кайчыны искә төшерәм. Кайчы китерәләр. Яңа килгән татар гәзитәләрен сорыйм. Күз төшерәләр. Гәзитәләрдән әллә никадәр кисеп алырлык нәрсәләр чыга. Шытырдатып кисеп алалар. Кая наборщик? Менә материал! Идарә кешеләрен мин кайчы тугърысында мөсаһәләдә гаеплим. Чөнки рус гәзитә идарәләрендә кайчының әһәмияте бик зур була. Анда каләм белән кайчы янәшә торалар. Кайчы белән эш итүчегә каләм кешесенә биргән вазифәне үк бирәләр. Шулай иттереп, кайчы безнең бүленгән татлы гәпне ялгап җибәрде.

Петербургның сыросте мине, вокзалдан төшкәч тә, хаҗига ябышкан мөселман кеби, кочаклап алганга, табигый, минем авыру Петербургта гаять тә көчәйде. Апрель ахырлары җитсә дә, Петербургның суыгы – гыйнвар суыгы, сыросте сырость иде. Шунлыктан фәйтунга утырып булса да урамга чыгу миңа газап иде.

Кайвакыт үзеңне җәберләп, каһәрләп чыкканда, юлда гади шәһәр бакчалары очрый. Агач төпләрендә яшь кыз белән җегет бер-беренә могашәка серләре сөйлиләр, «в любви объясняться» итеп утыралар. Болар төбенә утырган агачлар миңа урам себеркеләре булып күренәләр. Менә старший дворник җегет белән кызның торып киткәнен көтә, менә алар киткәч, дворник гашыйкларның агач дип уйлаган урам себеркеләрен алып китә шикелле тоела. Монда яз булганына галәмәт булса, ул да ит кибетләре тәрәзәсендә күренгән яшел суган иде.

Иттифакый уларак, Невский проспектка чыгыла иде. Бу урам мине гаҗәпләндерә дә, куркыта да иде. Бервакыт Муса әфәнде белән шуның бер ягыннан барганда, аркылы чыгарга тугъры килгән иде. Мин уртага таба бер-ике атладым да, артык барырга куркып, чигелдем. «Муса әфәнде, – дим, – зинһар, – дим, – аргы якка 10 тиенгә извозчик яллап чыгыйк», – дим. Муса әфәнде көлә дә, ачулана да. Ул алай

итү көлкелеген, курыкмаска кирәклеген, ахырда, үзе семьяле кеше булып та, рисковайт иткәнлеген сөйли. Мин тагын, извозчик, дим. Ул күнми, гакыйбәт, Аллага тапшырып, күзне йомам да, Муса әфәнденең култыгына тотынам да, күзне ачканда ары якта булабыз. Күкрәгем куркудан шулкадәр суга ки, площадьтагы чиркәү төбендә 15 минут җал итмичә, ары китә алмыйм.

Курыкмаска, ул урам дию кеби. Һәр көн үзенә бер-ике корбан алмый калмый. Һәр көн тапталучыларны тикшерсәң, күбесе рабочий була. Чөнки алар да, минем кеби, андый «пәриле» урамнардан йөрергә өйрәнмәгәннәр.

Байлар урамы ул! Шомалар урамы ул!

## VIII

Мин дә Петербургка бардым, дегет чиләге дә! Никадәр мөмкин була торып, Думага керә алмадым. Финляндиягә чакырдылар, анда бара алмадым. Бер театрга, бер музейгә вә, гомумән, бер достопримечательный җиргә булсын җөреп булмады: әлеге хәстәлек! Алла бүрегә бәхет бирсә, тешен сындырып бирә, имеш!

Но иной находит счастье,
Чувство счастья потеряв, –

дигән бер шигырь дә исемдә.

Тик Сафа әфәндегә барганда гына бер җан рәхәте була иде. Анда граммофон, идәннән түшәмгә кадәр өелгән кыйммәтле пластинкалар. Әнвагъ арияләр. Бөтен мәшһүр моганни вә моганнияләр. Тәмам колак арганчы граммофон борыла иде. Сафа әфәнде, граммофонны борганчы, нинди нәрсә вә нинди көй куелачагын бәян итә иде. Ул үзе дә музыканың илаһи ләззәтләрен аңлый торган кеше икән. Мин иң элек, ул граммофон уйнатмакчы булгач та, «татарча булмаса иде» дип үтенгән идем. Ул үзендә татарча пластинка юклыгын сөйләде. Мин, мәкаләмнең әүвәл башларында зарланган пычрак татар җырчыларын тагы бер ишетермен дип курыкканлыктан, Сафа әфәндегә эчемнән чын күңелемнән тәхсин әйттем. Менә Онегин ариясе. Татьяна бакчада утыра. Онегин, агач араларыннан килеп чыгып, җуан, ир кеше дә сискәнеп китәрлек тавыш белән җырлый. Татьяна әле генә өйдән, Онегиннан, гыйшыклык куркуы дигән курку белән качып чыгып утырган. Җөрәк леп-леп тибә. Шундый мәгънәле, нечкә курку һәм аптырау заманында Онегинның, Татьяна янына килеп, үгез тавышы белән кычкыруы, әгәр сценада күрсәм, миңа бик җәгъли кебек тоелыр иде дип уйладым. Чөнки минем (надо признаться) әлегә кадәр опера дип әйткән нәрсәдән җүнләп хәбәрем юк. Быел, разочароваться итәчәгемне алдан сизеп, гомеремдә беренче мәртәбә операга йөрү эшен башламакчы булам. Шул тугърыда ничек тә «гыйлем тәхсил» итмәкче вә аңламакчы булам. Әгәр мин уйлаган җәгълият шулай ук чыкса вә ул фикерем хаталыгын аңласам да, бернәрсә оттырмаячагым билгеле. Ни булсам да, Сафа әфәнденең бай вә мөхтәлиф пьесалы граммофоны миңа яңа бер галәм ачарга сәбәп булыр төсле әле.

Кирәк номерымда, кирәк Сафа әфәндедә шулай күңелле вә ямьле тормыш белән Петербургта тагы бер атналар үткәргәч, иптәшләр мәслихәте белән Петербургның дарелфөнүн табибен, зогъфем сәбәпле, минем номерыма китерттек. Ул, мине карап, кымыз эчәргә кирәклеген вә бик тиз Петербургтан китәргә тиешлеген сөйләде. 13 көн Петербург «ризыгын» ашагач, тагы Уфага таба сәфәр киттем. Инде Ряжскине үткәч тә, яшәргән агачлар (Петербург бакчасындагы урам себеркеләре түгел) күренеп, күкрәккә саф һава керә башлады. Уфага кайтсам, Уфа мине кияү көткән кыз кеби көтеп торган. Әтраф киенгән. Ямьяшел. Кояш көлә. Яз җиткән, яз!

## IX

Инде Уфада да кымыз күренгәли. Димәк, Троицкидә күптән бар. Г.Баттал әфәнденең үткен вә искренний интикадларын укыганым булса да, биззат күргәнем юк иде. Бу юлы Уфада аны күрдем. Уфада берничә генә көн хәл җыйгач, Баттал әфәнде белән вокзалга киттек. Троицкигә сәфәр. Поезд кузгалыр алдыннан билетнең бераз хатарак алынганы вә кире кайтарырга мөмкин түгеллеге аңлашылды. Чөнки без Чиләбегә туп-туры, туктамый бара торган поезд билете алганбыз. Дөрестендә безгә Чиләбедән бер станция бире – Полетаевкага туктый торганга алырга кирәк булган. Баттал әфәнде минем баруым тугърысында Чиләбедә Галиевләргә телеграм белән игълам итәргә уйлады. Мин рәд иттем. Чиләбедә вокзал тирәсендә бер номерда ял итеп, аннан соң ат яллап, кире Полетаевкага кайтырга карар бирдем.

Шулай итеп, видагълашып, Чиләбегә киттем. Чиләбе вокзалына төшсәм, өст-башы яхшы бер мөселман миңа тугъры карый вә һаман янымнан бара. Мин, сизенеп:

– Абзый, сез мине танийсызмы әллә?

– Сез фәлән түгелме?

– Әйе.

– Мин Галиев булам. Сезне алырга килдем.

Вокзалда берәр стакан кофе эчкәч, әйберләрне сакларга биреп, Чиләбенең каласына юнәлеп, Галиевләрнең йортына килдем. Чәй янында хата билет алганнарны сөйләп, Троицкигә барырга берәр иптәш юкмылыгын сораштым. Бу мөхтәрәм әфәнделәр, мин аштан соң ятып хәл җыеп торганчы, иптәш тә тапканнар. Ат та киләчәк булган.

Бераздан атлар килеп, Троицкигә бара торган бер приказчик юлдаш булып, Полетаевкага юнәлдек. Юлымыз күңелле. Ике тарафы урман. Көн матур. Җилсез. Кояшлы. Җылы. Иптәш белән Троицкидә вәгъдә куешкан тройкалы ике немец вояжеры безне урманда туктап көтәләр икән. Аларга юлыктык. Свежесть вә здоровье дигән нәрсәнең мөҗәссәме булган бер вояжерыбыз, яшел чирәмгә утырып, авыз гармуны уйный. Ул шул гармунында такмаклардан, тансылардан алып озын арияләргә кадәр – һәммәсен уйный. Ул тәмәке урынына кесәсендә калай тартма белән ландрин манпасие йөртә икән. Тартмасын ачып, безгә дә тәкъдим итте. Гармунны уйнагач, манпасине суыргач, без трантасларга менеп киттек. Тройка алдан, без арттан. Тузан куба. Безнең пар ат кына булса да, аларның тройкасыннан һич калышмый, әтраф мужикларының ихтыярсыз дикъкатен җәлеп итәбез. Шулай күңелле рәвеш барганга, Полетаевкага җиткәнебезне тоймый да калдык.

Төнлә поездга утырдык. Берзаман таң аткан, кояш күтәрелгән.

Мине вагонда берәү уята. Поездда бер кеше дә калмаган. Буп-буш.

– Габдулла әфәнде сезме?

– Мин.

– Мин Габдерахман мулладан, алырга килдем.

Чыгып атка утырдым. Шәһәргә киттем. Габдерахман хәзрәткә барып кердем. Нәкъ аш вакыты. Аштан соң беренче стакан кымыз эчеп, ахры, наконец, гакыйбәт авызга кымыз тиде. Мине кымыз өчен Уфага бару фикереннән кайтаручы вә андагы кымызның җәгълилеген сөйләүче вә яз көне кымыз эчәргә үзенә чакырып вәгъдә алып китүче ушбу Габдерахман хәзрәт иде. Троицкидә берничә көн генә торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем. Анда хәзрәт тарафыннан ялланган казакълар, аның йөзләп баш биясен савып, бүтән малларын көтеп торалар. Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә миңа махсус чатыр тегелде.

Шәһәр смрадыннан, завод агуыннан, бозык һавадан качып чыгып, арбадан пароходка, пароходтан поездга күчә-күчә, эштән чыккан мин бичара, ахры, бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым. Бу – сахра. Бу – казакъ җире. Әүвәл «бисмиллаһи» дип, бер чишенеп ташладым. Коры степь һавасы. Сөт, каймак, теләсәң, коен, әле генә сауган саф кымыз. Бүген генә суйган ит. Бөтен нәрсә табигый, бөтен нәрсә алдаусыз.

**Валлаһи**

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!
Аз гына бер җил исү берлән үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Иштә бу – сахрада беренче көнемдә язылып ташланган бер кәгазьдән алынган җырулар!

# Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр

## Мөрит

Рамазан шәрифтә бер Мөритнең бик ифтар итәсе килде. Мөрит, бу тугърыда күп уйламыйча, бер караңгы бүлмәгә кереп, шәм яндырды да шәмгә тотып җомырка пешерергә тотынды. Җомырка пешкәч, кабыгын әрчеп ашарга гына башлаган иде, кисәктән күзе алдында үзенең шәйхе пәйда булып: «Бу ни гөнаһ!» – дип кычкырды.

Мөритнең курыкканлыктан теле тотылып: «Хәзрәт, зинһар, кичерә күр, шәйтан котыртты... кот... котырткан иде», – дигәндә, мич астыннан бер шәйтан баласы сикереп чыкты да, Мөриткә карап: «И оятсыз! Син нәфесең теләгән эшне эшлисең дә һаман без шәйтаннарны гаеплисең; мин әле шәмгә тотып җомырка пешерүне үзем дә синнән генә өйрәндем», – диде.

## Аю мәҗлесе

Аю мәҗлес ясады. Мәҗлескә үзенең якын күргән Аю җенесен генә хасламаенча, күзенә кем күренеп, күңеленә кем килгәннәрнең берсен дә калдырмыйча чакырды.

Белмим, үзенең туган көне булдымы, әллә исемләнгән көне микән? Ни булса да булсын, мәҗлес шәп иде. Ашарга күп булган шикелле, эчәргә дә аз түгел иде. Кунаклар тезелешеп утырдылар. Аларның төрле аш вә эчемлекләрдән кәефләре килгән иде.

Кунакларның болай кәефләре килгәнне күргәч, Аю, тагы да кызык булсын дип, биззат үзе төшеп биергә кереште.

Төлке, моның биегәнен күргәч, болай дип җырлый башлады:

Ары да барып биисең, бире дә килеп биисең;
Бигрәк оста биисең, күз тияр дип белмисең.

Моны җырлагач, янәшә утырган Бүре, чыдый алмыйча, Төлкенең колагына: «Әй, иптәш, нигә болай бер дә килешмәгән биюне, бүрәнә кеби аяклары илә дөп-дөп сикергәнне бик оста, бик җиңел дип мактыйсың?» – дигәч, Төлке җавабында: «И Бүре! Син тик утыр, хәзер минем бу мактавым Аюның хушына китсә, ул безне тагын чакырып сыйлар», – диде.

## Вагыйз

Вагыйз мәчеттә, бал янына җыелган чебеннәр шикелле халыкны үз әйләнәсенә җыеп, һәр изгелекләргә боерып, һәр әшәке эшләрдән тыеп, үзенең давуди тавышы илә көйләп-көйләп вәгазь әйтәдер иде.

Вагыйзнең сүзләре ике ирен арасыннан балдай агып чыга, нәсихәтләренә, бер дә бакыр катышмаган алтын шикелле, рия яхуд берәүне кагу, чәнчү катышмаган. Тыңлаучыларның тамырлары буенча каннар җөгергәне бер-берсенә ишетелү дәрәҗәсенә җиткән. Һәркемнең күзендә яшь, йөрәгендә ут; күзләренә Аллаһы Тәгаләнең үзенә махсус сыйфаты илә кыямәттә хаким вә назыйр булып торуы, фәрештәләрнең саф баглап торулары тәмам күренгән шикелле була.

Һәркем, үткәндәгеләргә үкенеп, киләчәктә гөнаһ кыйлмаска кистереп, мәсҗеттән чыгалар.

Мәсҗеттән чыкканда, бер кеше икенчесенә: «И кардәш, вәгазь бигрәк әсәрле булды, әмма, иптәш, хәтерең калмасын, мин синең күзеңдә бер тамчы да яшь күрмәдем», – дигәч, икенчесе: «Миңа нигә җыларга, мин бу мәхәлләнеке түгел бит», – диде.

*

Бертөрле кешеләр бар: син аларга дуст булсаң, алар кашында галим дә син, мөхәррир дә син, әмма бераз салкынлык булса, алар синдә булган фазыйләтне уйларга да куркалар.

## Мирон

Бер шәһәрдә Мирон исемле бай бар иде.

Халык моның хакында: «Гүя бу байның тимер сандыгында миллион булса да, фәкыйрьләргә бер тиен дә бирми...» – дип сөйли иде.

Әлбәттә, һәркемнең яхшы атак аласы киләдер. Бервакыт безнең Мирон халык арасына: «Һәр җомга көннәре фәкыйрь-фокара, хәерче-саилчеләр капкама килсеннәр!» – дип хәбәр таратты.

Бу хәбәр бик тиз шәһәргә таралды. Миронның начар исеме яхшылык илә алмашынды.

Җомга көн дә җитте. Шәһәрнең фәкыйрьләре, толлары, ятимнәре – барчасы, җыелышып, Миронның капкасы төбенә бардылар.

Әмма ни күрсеннәр: Мирон яңа гына чылбырдан ычкынган усал этләрнең бер дистәсен боларга каршы куйган иде.

Инде бичара хәерчеләргә вә бала-чагаларга ашау-эчү кайгысымы? Мискиннәр, бу усал этләрнең тешләреннән сау-сәламәт өйгә кайтып җитә алсалар, бик шөкер итәчәк булып, һәрберсе качу юлын тоттылар.

Бу эштән соң халык: «Аһ, Мирон абзый – юмарт кеше, ул үзе ярлылар берлә актык бер тиенен бүлешер иде, ләкин этләре бик явыз», – дип сөйлиләр иде.

*

Мин күп вакыт күрәм: биек пулатларга менү җиңел түгел. Гаеп һаман этләрдә генә, Мироннар үзләре читтә калалар.

## Бәхет

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, нинди генә эшкә тотынсалар да, ни сәбәптәндер эшләре уңга китми иде.

Бу агай-энеләр, эшләре уңмавында үз-үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, һаман Бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Берзаман ничектер Бәхет, күзгә күренмичә генә, боларга кунакка килде дә бу өч агай-энегә, нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде.

Бу вакытта өч агай-эненең берсе сәүдәгәрлеккә тотынган иде. Дәрхаль Бәхетнең ярдәме илә ни сатса – аннан файда, ни алса – аннан табыш итеп, берничә көндә малы вә хәзинәсенең хисабы булмаган бер зур бай булып китте.

Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәше мәхкәмәдә кятиб (писарь) иде. Бу да Бәхет аркасында хакимлек дәрәҗәсенә күтәрелде; медальләр бирелде.

Сез инде өченчесенә дә Бәхет ярдәм иттеме диерсез.

Ник итмәсен, итте: өченче кардәш чебен тота иде. Хәзер Бәхетнең булышлыгы илә кулын селтәгән саен чебен тота; һичбер селтәгәне бушка китми.

Бәхет кунакка гына килде, дигән идек бит. Дөрест, Бәхет озакламады, китте.

Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар. Өченчесе, һаман явыз Бәхетне яманлап, авылдан авылга, сукрана-сукрана, капчык тотып теләнергә китте.

*

Укучы! Ушбу хикәядә кем гаепле икәнен үзең хаким булып табып хөкем ит.

## Җил илә Кояш

Берзаман Җил илә Кояш икәве: «Кайсыбыз Адәмнең киемен салдыра алыр?» – дип даулаштылар.

Җил, бар куәте илә исеп, Адәмнең киемен салдырырга тырыша иде. Җил катырак искән саен, Адәмнең киеме тәненә катырак ябыша бара иде. Җил булдыра алмады.

Менә берзаман Кояш күтәрелде. Баягы Адәм, Кояшның кыздырганына чыдый алмыйча, барча киемнәрен култык астына кыстырып, ялангач китте.

## Бер Гөл

Урманның бер почмагында, аулакта гына, чәчәкләнгән бер Гөлнең кисәктән генә чәчәге шиңә башлады һәм аз гына вакыт эчендә яртысы шиңеп тә бетә язды.

Бичара Гөл, башын бөгеп, хәсрәт илә үзенең тәмам бетүен көтә иде.

Гөл, мискин, шул өмидсезлек эчендә дә өмидләнеп, Аллаһы Тәгаләгә зарыйлык кыйла башлады вә диде: «И Раббым! Рәхмәтең берлә бу караңгы җиргә дә Кояш яктысын төшерсәң, мин бәхетсез Гөлең дә, бәлки, терелеп, матурланып китәр идем!»

Гөлнең бу сүзләрен ишеткән бер Коңгыз, Гөлдән көлеп: «И бичарам, син бигрәк саф күңелле икәнсең! Ничек соң сиңа Кояшның яктысы төшсен? Әллә син Кояшның кайгысы тик бер син генә дип беләсеңме? Юк, дустым, Кояшның аның кырларны, игеннәрне, имәннәрне, наратларны яктыртасы вә җылытасы бар; аның синнән башка да эше җитәрлек. Менә син безнең шикелле очып йөрсәң, Кояшны күрер идең, әмма Кояш урман араларына килеп сине эзләмәс бит; беләмсең, сахраларда кешеләрнең исләрен китәрә торган матур вә хуш исле чәчәкләрне бизәү вә башкасы – Кояш хезмәтедер. Шулай булгач, син Кояштан өмидеңне кис; андый килешмәгән сүзләрең илә Кояшны борчыма», – диде.

Болар бу сүздә икән, шул вакыт таң атып, Кояш чыгып, бөтен дөньяны ялтыратты.

Караңгылыктан тәмам һәлак була язган бичара Гөл дә Кояш нуры илә яңадан җанланды.

*

Әй сез, Ходай тәкъдире илә зур дәрәҗәләрне алган затлар! Сез Кояштан үзегезгә үрнәк алыгыз. Кояш, үзенең яктысы кайда гына җитсә дә, андагы яхшыларга, яманнарга бертигез яктылык бирәдер, һәм ул шул сәбәптән үзенә рәхәт, бәхет, сәгадәт табадыр, шуның өчен дә аның сурәте һәр җан иясенең кү-

целендә пыяла стаканга төшкән шәүлә шикелле ялтырыйдыр. Һәм һәркем аңар рәхмәт укыйдыр.

Моннан аңлашылган икенче мәгънә: син чын ихласың илә бер эшне мәйданга чыгармакчы булсаң, сине төрле манигъләр илә куркытып өмидсезләндерәләр.

## Мут илә Карлыгач

Атасының вафатыннан соң бик бай мирас алып калган бер яшь Егет, артык дәрәҗәдә мутлык вә исрафка керешеп, берничә көн эчендә мал-мөлекнең барысын урнаштырып, өстендә бер искерәк туннан башка нәрсәсе калмады; ул тунны да сатар иде, ләкин, вакыт кыш көне булганлыктан, суыкка туңып үләрмен дип курка иде.

Менә беркөнне бу Мут бер Карлыгачны күрүе илә тунны да сатып эчте. (Безнең җиргә Карлыгачның яз көне килгәне мәгълүмдер.)

Мутның уенча, инде һавалар яхшыланды, көннәр җылынды, суыклар да төн ягы аулаклыкларына куылды; Мутның тун сатуы тиешле иде.

Әмма яшь Егет «бер карлыгач яз ясамый» дигән мәкальне оныткан иде. Менә бервакытны кайдандыр исә янә суыклар, бураннар чыкты. Морҗаларда багана-багана төтеннәр күренеп, чана табаннары астында шытыр-шытыр кар тавышы ишетелә башлады.

Бичара яшь Егетнең, гаять тә өшегәнлектән вә салкын үзәгенә үткәнлектән, ихтыярсыз күзләреннән яшьләре атылып чыкты.

Беркөнне Егет, урамда йөргәндә, үзенең тун саттырган Карлыгачының кар өстендә катып калган үләксәсен күргәч, янына килеп: «И бәдбәхет Карлыгач! Бетердең син мине! Сиңа ышанып, мин кыш көне тунсыз калдым», – диде.

## Ишәк

Мужикның юаш кына бер Ишәге бар иде.

Иясе, бу Ишәкне урманда табу читен булмасын өчен, муенына кыңгырау такты.

Ишәк, әлбәттә, медаль хакында сүзләр ишеткәләгән булырга кирәк: менә берзаман үзенең медале илә һаваланырга, борынын күтәрергә башлап, борынгы үзенең иптәш ишәкләренә әйләнеп тә карамый торган булып китте.

Ләкин бу медаль моңар файдамы булды?

Ишәк әүвәлдә, медале юк вакытта, теләсә кемнең бакчасына вә теләсә нинди игенлекләргә акрын гына кереп, туйганчы ашаганнан соң, тавышсыз гына чыгып китә иде.

Әмма хәзер эш бөтенләй башкарды.

Ишәгебез, бер күршенең бакчасына кереп, авызын гына сузмакчы булса, гөнаһ шомлыгы, медаль шылтырый. Кешеләр ишетәләр дә, кулларына күсәк алып, безнең галиҗәнабне бер дә кызганмыйча, кабыргаларын санныйлар, әгәр берәүнең игенлегенә керсә, әфәндебезнең сыртына без кадап куалар.

Менә берзаман көз булды; ни күзең берлән күрәсең: Ишәкнең коры сөяге илә кутырлап беткән тиресе генә калган.

*

Кеше үзе бозык булып та дәрәҗәсез булса, ул бик тикшерелмидер. Әмма бозыкка дәрәҗә бирелсә, аның бозыклыгы, тәмсилдәге кыңгырау тавышы кеби, бик тиз һәм бик ерак ишетеләдер.

## Ике бала

Гариф, Зарифка карап: «Әйдә, иптәш, бу агачтан чикләвек өзик!»

Зариф: «И дустым, ул агач, күрәмсең, ничек биек, кая анда безгә менү! Кая чикләвек ашау!»

Гариф: «Көч белән ала алмаган нәрсәне хәйлә белән алалар. Менә син әгәр мине бу түбәнге ботакка менгезсәң, минем чикләвеккә буем җитәр, аннан ары икебез дә чикләвек ашарбыз, җәме?»

Зарифның күңеленә дә бу киңәш ошап, дустлар җөгерешеп агачка бардылар.

Зариф, үзенең бар көчен сарыф итеп, иптәше Гарифны ботакка менгезде, ләкин Зарифның бу эше үзе өчен файдасыз булды: Гариф агач башында шатыр-шотыр чикләвек ашый, әмма дусты Зарифка тик чикләвекнең кабыкларын гына ташлый.

Зариф, мискин, Гарифның кулыннан яңлыш ычкынган чикләвекләрне генә ашап, югарыдан төшкән кабыкларны гына ялый иде.

*

Дөньяда күп Гарифлар бар ки, аларның дәрәҗәгә менүе өчен җан көчләре илә тырышкан Зарифлары баеган Гарифлардан чикләвек кабыгы да күрмиләр.

## Оракул

Кайсы динсезләрдәдер Оракул исемендә агачтан ясалган бер мәгъбүд (санәм) бар иде.

Бу санәмнең бер гаҗәп хасияте бар иде ки, әгәр бер кеше нинди булса да бер эшкә гакыл таба алмый килсә, санәм аңар ана нәсихәте кеби йомшак нәсихәтләр биреп җибәрә иде.

Кайвакытларда бу санәм киләчәктәге эшләрдән дә хәбәр биреп, вакыйгга бик тугъры китерә иде.

Шуның шикелле хасиятләре булганга күрә, санәм баштан-аякка алтын, көмешләр илә бизәлгән, садакалар, хәйратлар илә күмелгән һәм күп халыкны үзенә ышандырган иде.

Көннәрдә бер көн ни сәбәптәндер Оракул саташкан: бер мәслихәтче килсә, яңлыш мәслихәт бирә, икенче берсенә ап-ачык ялганлый... Менә гаҗәп! Моның пигамбәрлек хасиятләре кая киткән?

Халык бу эшкә таң кала, исләре китә. Күп тә үтмәде, эшнең дөресте мәйданга чыкты: бу Оракул үзе агачтан ясалган бүкән икән. Әгәр артында гакыллы кеше утырса, Оракул бер дә яңлыш, ялган катыштырмый, имеш; әгәр артында ахмак кеше булса, бүкән һаман бүкән булып тора икән.

*

Мин ишетәм, белмим, растмы, ялганмы, дөньяда шундый хакимнәр бар икән, алар гакыллы секретарьлар бар вакытта бик тәдбирле булалар, имеш.

## Көтүче

Алпавытның сарыкларын көткән Сафаның кисәктән генә сарыклары кими башлады. Безнең Сафа кайгыда, хәсрәттә; очраган бер кешегә: «Көтүгә котырган бүре кереп, сарыкларны алып китә, аларны бер дә кызганмыйча ертып, йолкып ашый», – дип сөйли.

Сафаның «бер дә кызганмыйча ашый» дигән сүзеннән кешеләр: «Таптың сүз, бүре кайчан соң сарыкны кызганып ашаганы бар?» – дип көләләр.

Менә бүрегә аучылар, сакчылар җибәрделәр. Алар бара торсын әле. Белмим, ни өчендер һәрвакыт безнең Сафаның алдында йә сарык ботлары, йә итле ботка күренә, табакларында шурпа, ит бер дә өзелми. Сафа үзе бай кеше дә түгел, шәһәрдән авылга көтүчелеккә генә җибәрелгән. Әлхасыйль, аучылар бөтен урманны актардылар, бүренең эзе дә юк, исе дә юк.

*

Аучылар, дустлар, юкка тырышасыз; бүрегә – исем генә; әмма сарыкларны Сафа бүре ашыйдыр.

## Кәгазь Очырткыч

Балалар җибәргән кәгазь Очырткыч, югары һавадан, җирдән аз гына күтәрелеп очкан Күбәләкне күргәч: «Мискин, ышанамсың, син миңа аз гына күренәсең бит. Син, бичара, минем бу кадәр югары очканыма, әлбәттә, көнләшә торгансың», – диде. Күбәләк җавапта: «Юк, бер дә көнләшмим аның өчен, син никадәр югары очсаң да, бәйләүдә генә очасың; минемчә, мондый гомер итү бәхеттән бик ерак булырга тиеш. Әмма мин никадәр түбән очсам да, бәйләүдә очмыйм; минем үз иркем – теләсәм кая барам. Мин синең төсле, бөтен гомеремне берәүнең кәефе өчен фида итмим», – диде.

## Вәзир

Бер Вәзир ни сәбәп иләдер назлы киемнәрдән, мамык түшәкләрдән, татлы ашлардан аерылып, кортлар, җыланнар патшалык сөрә торган мәмләкәткә китте; дөрестен генә әйтсәм, вафат булды.

Күмүчеләр кырык адым җир киткәч тә, Вәзир терелде. Терелгәч, караса, күрә ки, Мөнкир илә Нәкир хәзрәтләре килеп тә җиткәннәр. Бу ике фәрештә Вәзирдән: «Раббың кем?», «Пигамбәрең кем?» – сөальләренә җавап алгач:

– Син кайда туган идең? Вә ни хезмәттә идең? – дип сорадылар.

Вәзир дә, бер аптырамыйча:

– Мин Иранда тудым, хезмәтем вәзирлек иде; мин үлгәнче саулыкка туя алмадым; шул сәбәпле хөкемнәрне, эшләрне янымдагы секретарьга тапшырдым, – диде.

Тегеләр тагы да:

– Соң син үзең ни эшләдең? – дигәч, Вәзир:

– Ашадым, эчтем, йокладым һәм, секретарь нинди генә кәгазь күрсәтсә дә, шуларга кул куеп тордым, – диде.

Вәзир бу сүзне әйтеп кенә бетергән иде, Нәкир хәзрәте дәрхаль янындагы дәфтәренә «бу кеше оҗмахлык» дип язып куйды.

Шул вакыт бу язуны Мөнкир күреп дәфтәрдән боздырмакчы булган иде, әмма Нәкир хәзрәте, эшнең чынын сөйләргә керешеп:

– И иптәш Мөнкир! Син белмисеңмени, бу Вәзир үзе җүләр булган; әгәр, бәхетсезлеккә каршы, җүләр башы илә үзе хөкем итсә, никадәр кешеләр күз яшьләре илә һәлак булырлар иде. Менә ул үз гаебен үзе белеп, эшкә кешене кушканы өчен оҗмахлы булды, – диде.

*

Мин кичә мәхкәмәдә бер хаким күрдем, минем уемча, ул да, эшне секретарьга тапшырса, оҗмахлы булыр иде.

## Казлар

Мужик, озын талчыбык илә Казларны сөреп куалап, каладагы базарга иртәрәк барып җитәргә ашыгып бара иде.

Казлар, хуҗаларының боларны бер дә ял иттермичә, әлсерәтеп куганына җаннары рәнҗеп, сукранып, бу түбәндәге сүзләрне сөйләп баралар иде: «Мужик дисәң, мужик, хуҗамыз безнең дәрәҗәмезне белми. Ул безне гүяки простой Казларны куган шикелле сөреп, сөртендереп куалый. Әгәр ул мужик булмаса, безнең Рим шәһәрен коткарган казлар нәселеннән икәнемезне белер иде. Рим шәһәрендә безнең хөрмәтемезгә бәйрәмнәр вә шәрәфемезгә туйлар ясыйлар. Бу хуҗа наданлыгыннан үзенең безне кадер-хөрмәт итәргә бурычлы икәнен аңламыйдыр һәм безнең гади Казлар гына түгел икәнемезне белә алмыйдыр».

Боларның зарлануларын читтән ишетеп торган бер Мөсафир, боларга карап: «Сез ни һөнәр илә гади вә простой Казлыктан чыгасыз?» – диде.

Казлар: «Безнең бабайлар!»

Мөсафир: «Дөрест, мин сезнең бабаларыңызның Римне коткарганын ишеткәнем бар, әмма беләсем килә: сез ни файда китердегез соң?»

Казлар янә: «Безнең бабайлар Римне коткарганнар».

Мөсафир: «Дөрест, коткарганнар, әмма сездә ни хасият бар?»

Казлар: «Бездә бернәрсә дә юк!»

Мөсафир: «Алайса, сез бабайларыңызны исеңезгә төшермәңез. Алар тыныч кына каберләрендә ятсыннар. Аларга һөнәрләренә күрә хөрмәт булды. Әмма сез, дустлар, һичбер вакыт кәбабтан башкага ярамассыз!» – диде.

*

Ля тәкыль аслый вә фәслый әбәда, иннәма аслыль фәта ма кад хасаль.

## Мактанчык Куян

Ерткучы хайваннар бергәләшеп бер зур Аюны аулап ектылар.

Табышны уртага салып, үзара бүләргә тотынганда, бер яктан Куян да, килеп, Аюның бер колагына ябышты.

Башка ерткучы хайваннар, Куянның болай батырчылык иткәненә гаҗәпләнеп һәм ачуланып: «Әй син, Кыек аяк! Син нигә тотынасың? Аюны аулаган вакытта синең эзең дә күренмәде бит!» – дип кычкыргач, Куян, бер дә аптырамыйча: «Ә Аюны урманнан кем куып чыгарды дип беләсез?» – диде.

Куянның бу мактануы ерткучыларга бик кызык вә көлке күренгәнлектән, аңар дәгъвасы буенча Аю колагын тапшырдылар.

*

Мактанчыклардан гәрчә көлсәләр дә, күп вакытта аларга өлеш тә тиядер.

## Умарта корты вә Чебеннәр

Ике Чебен, чит мәмләкәтләргә китәргә хәзерләнеп, үзләре илә бергә китәргә Умарта кортын да чакыра башладылар.

Бу Чебеннәр чит җирләрнең бик яхшы икәнлеген Байгышлардан ишеткәннәр иде.

Чебеннәр ник китмәсеннәр? Туган җирләрендә боларны рәнҗетәләр һәм, чакырылмаган кунак шикелле, бичараларны ашъяулык тирәсеннән куалар, татлы ашларны да ашатмыйлар...

Һәммә ашамлык нәрсәләр өстенә пыяла калфаклар каплап, мыскыл иткән шикелле, тик Чебеннәрнең күзләрен генә кызыктыралар.

Почмак тарафларына бөтенләй барыр хәл дә юк: анда усал Үрмәкүчләр ау корганнар.

Онытылмасын әле, Умарта корты боларга ни җавап бирде? Ул: «Миңа туган-үскән җирем кадерле. Мин үземнең кәрәзле балым илә алпавытларны, байларны, хәтта авыл кешеләрен үземә гашыйк иттем. Мин монда да сөекле. Әмма сезгә сүзем юк; сез теләсәгез кая барыгыз. Ләкин белегез ки, сезнең һәр җирдә дә бәхетеңез бер булыр; әгәр сез һаман хәзер ашны ашау гадәтеңезне ташламасаңыз, кая барсаңыз да, сезне хөрмәт итмәсләр», – диде.

*

Кем ки туган-үскән җирендә файдалы кешеләрдән саналмаса, аның күңелендә һәрвакыт чит җирләр сөекле булыр.

## Черки изгелеге

Агач күләгәсендә рәхәт-рәхәт йоклаган Көтүчегә таба зәһәрле Җылан угын чыгарып килгәнен шул җирдән ерак түгел бер Черки күреп, Көтүчегә мәрхәмәте килгәнлектән, тиз генә безелдәп барды да Көтүчене тешләп уятты. Көтүче уянды, Җыланны үтерде, ләкин Җыланнан элек изгелек иткән Черкине бер дә дөньяда тормаган кебек итеп изде.

## Җылан илә Бәрән

Кое янында бер Җылан бөтен дөньяга каршы каһәрләнеп, ачуланып ята иде.

Җыланның ачулану өчен генә яратылган һәм зәһәрләнү хисеннән башка хисе юк икәне билгеледер.

Шуннан ерак түгел бер җирдә кечкенә генә яшь бер Бәрән, Җыланның барлыгыннан да хәбәре булмыйча, йөгереп, сикереп, рәхәтләнеп уйнап йөри иде.

Менә бервакыт Җылан, Бәрәнгә таба әйләнеп, авызыннан угын чыгарып, күзләре алдында һава томанланып, бөтен каны кайнап, каһәрләнә башлады.

Җыланның кыланышларыннан гаҗәпләнгән Бәрән, аның янына ук килеп: «И Җылан! Соң бу кадәр ачуланырлык мин сиңа ни зарар китердем?» – дигәч, Җылан: «Кем белсен? Бәлки, син мине таптар өчен шулай сикергәләп йөри торгансың»,– диде.

*

Кемнең ки күңеле дустлык, сөешү кеби хисләрдән буш яратылган булса, аның каршында бөтен халык дошмандыр.

## Ташбака илә Куян

Ташбака илә Куян узышмакчы булып бер тауга таба йөгерешә башладылар.

Куян, үзенең йөгереклегенә ышанып, юлда ятып йоклады.

Куян берзаман йокысыннан уянып караса, Ташбака әллә кайчан тауга барып җиткән!

Инде безнең Куян артка калганына үкенде дә, хурланды да, әмма ни файда?

*

Көчлегә үзендәге көчкә ышанырга ярамый. Кечкенә генә дошманга да зур дошманга хәзерләнгән кеби хәзерләнергә тиеш.

## Арыслан ауда

Эт, Арыслан, Бүре, Төлкегә ничектер күрше торырга туры килеп, болар дүртәве ни генә ауласалар да, дүрт өлешкә бүләргә сүз куештылар.

Көннәрдә бер көн Бүре, бер Болан тоткач, иптәшләренә хәбәр бирде.

Иптәшләр килделәр: табыш начар түгел.

Арыслан, бик мөтәкәббиранә бер сурәттә генә Болан янына килеп утырып, Боланны дәрхаль дүрт кисәккә бүлеп ташлап, сөйләргә тотынды: «Менә, дустлар, без дүртәү инде; әйдәңез, бүлә башлыйк; менә тыңлаңыз: бу беренче кисәк миңа – вәгъдәбез буенча. Икенчесе миңа – минем Арыслан булганым өчен. Өченче кисәге минеке – аның өчен мин барыгыздан да көчлерәк. Әмма дүртенче кисәккә кайсыгыз гына кул сузса да, урыныннан тере тормас, белегез аны!..»

## Файдасыз җумартлык

Яңгырсызлык берлә комга әйләнгән болынлык, игенлекләр өстеннән бер зур Болыт үтеп китеп, бер Диңгезгә барып, бик озак яуды да үзенең җумартлыгы илә шул тирәдәге Тауга мактана башлады.

Тау моңар каршы: «И Болыт, Болыт! Диңгездә синнән башка да су күп; син, Диңгезгә яумыйча, менә бу корып, кибеп беткән сахраларга яусаң, никадәр кешеләрне ачлыктан коткарыр идең; җә инде, синең бу җумартлыгыңнан бер-бер җан иясе файдаландымы?» – диде.

## Бүре Этләр оясында

Бүре, Сарыклар абзарына керәм дип, караңгыда яңлыш Этләр сараена керде.

Бу кунакның кем икәнлеге сизелгәч, зур тавыш-гауга купты. Этләр каһәрләнделәр. Сугышка хәзерләнделәр. Бер яктан Кешеләр дә: «Карак бар! Карак бар!» – дип кычкырыша башладылар.

Бер минут эчендә бөтен йорт җәһәннәм рәвешенә керде. Аннан да күсәкле Кешеләр, моннан да мылтыклы Аучылар килеп чыгалар. «Ут китерегез, лампа яндырыгыз!» – дип кычкыралар.

Безнең кунак, почмакка гына посып, тешләрен шыкырдатып, төкләрен кабартып, күзе илә бөтен дөньяны ашамакчы булып утыра иде. Бүре, үзенең каршысындагы дошманнарның Сарыклар булмаганлыгын аңлагач, хәйлә юлын тотып: «Туктаңыз әле, дустлар! Бу нинди тавыш кубардыңыз? Беләсезме, мин сезнең иске дустыңыз ич, мин сезнең белән талашырга килмәдем, татулашырга килдем. Үткәннәрне онытырга кирәк; инде киләчәктә мин кая ул сезнең сарыкларыңызга тию! Хәтта үземнән башка Бүреләр тисә дә, мин, Сарыклар ягыннан төшеп, ул явыз Бүреләр илә чәйнәшермен», – дигәч, йорт Хуҗасы: «И Бүре, Бүре! Син соры җонлы булсаң, мин ак сакаллымын; мин сезнең гадәтеңезне әллә кайчаннан бирле беләмен, шуның өчен синең илә килешмим вә татулашмыйм», – дип, сүзне бетерер-бетермәс, Этләр, мылтыклар, күсәкләр берьюлы Бүре башы өстендә уйный башладылар.

*

Адәм баласы җиңелгән заманында солых яратучан буладыр.

## Каз

Каз, суда Йолдыз шәүләсен күргәч, Балык дип белде һәм ничә мәртәбә аны ауламакчы булып тырышса да, шәүлә урыныннан кузгалмагач, Каз да шәүлә икәнен белде дә аулауны ташлады.

Иртәгесен Каз суда чын Балыкны күргән иде, ну, бу да кичәге кеби шәүләдер, дип ауламады вә аңар әйләнеп тә карамады.

*

Безгә дөрестне яңлыштан һәрвакыт аерырга кирәк, бу икенең берсен берсе урынына төшермәскә тырышырга кирәк.

## Тиен

Бер Тиен кайсар Арысланга хезмәт итә иде. Ничек вә нинди хезмәт иткәнен белмим, ләкин Тиеннең хезмәте Арысланга бик ошый иде.

Арысланга ярар өчен аз хезмәт кирәкмәгәнлеге билгеледер. Бу хезмәте өчен Арыслан Тиенгә бер йөк чикләвек бирергә вәгъдә кыйлган иде.

Вәгъдә кыйлынган, әмма вакыт һаман су кеби акмакта. Тиеннең хезмәте авыр; эш арасында ара-тирә ач та торырга тугъры килә иде.

Тиен, мискин, ни эшләсен, аңар яшь аралаш күзләрен Арысланга тегәләп утырудан башка чара юк иде.

Кайвакыт Тиен, әллә ничек читкә караганда, үзенең иректәге иптәшләренең шатланышып, сикерешеп, ботактан ботакка йөргәннәрен һәм «шырт! шырт!» чикләвек ярганнарын күрә иде. Моны күргәч, безнең Тиеннең дә иптәшләре янына барасы, уйныйсы, сикерәсе килә иде.

Кайчакта, чыдый алмыйча, алар янына барам дип аягын кузгатса, атлар-атламас, моны Арыслан хезмәтенә куып җибәрәләр иде.

Күп заманнар үтте. Тиен бичарабыз картайды.

Эшкә ярамаслыгын белгәч, Арыслан да Тиенне азат итте.

Азат булгач, үзенә бер оя ясап тора башлады. Теге вәгъдә буенча Тиенгә Арыслан тарафыннан күз күрмәгән, колак ишетмәгән диярлек дәрәҗәдә яхшы чикләвек тә бирелде. Әмма ни файда? Мискин Тиеннең тешләре күптән коелып беткән иде.

*

Шәкертләр гомерләренең иң гүзәл вакытында ачлы-туклы мәдрәсәдә ятып гомер кичерәләр.

Дөрест, яшьләре 30–40 ка җиткәндә, мулла булыпмы йә башкачамы азык табалар. Ләкин ни файда?

Күкрәкләре черегән, яңаклары ябышкан, уйнап тора торган күзләр урынына тирән-тирән чокырлар гына калган буладыр.

## Сарыклар вә Этләр

Кайсыдыр бер урман буенда көтелгән Сарыклар Бүреләрдән бик җәбер вә золым күргәнлектән, Ияләре Сарыклар арасына бозау кеби Этләрдән ике дистә Эт җибәрде. Моның уенча, бу Этләр Бүреләрне Сарыкларга керүдән тыячаклар иде.

Вакыйган, хуҗаның бу фикере бик тугъры иде: бу кадәр күп Этләр булганда, Бүреләр көтүгә керә алмыйлар иде.

Әмма Этләргә дә ашарга кирәк; бу саклаучы Этләр, ахиреләмер һәр көн берәр Сарыкны сугышыптлалашып ашый-ашый, Бүреләрдән ничә вә ничә мәртәбә зарарлы бүре булып, берничә көндә көтүне тәмам һәлак иттеләр.

*

Бәгъзе галимнәр дин вә шәригать саклыйлар. Әмма үзләре шул ук шәригатьне ашыйлар. Әгәр шәригать бер зур хайван сурәтендә булса, алар тешендә каннар күрергә дә мөмкин булыр иде.

## Дуңгыз

Ничектер Дуңгыз, бер алпавыт ишегалдына кереп, ат абзарлары тирәсендә әйләнеп, чүплектә, көл базларында теләгәнчә аунап, шакшы суларда туйганчы коенып өенә кайтып килгәндә, моңар Көтүче каршы килеп: «Җә, син, Катыборын, кунакта ниләр күрдең? Мин алпавытта энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш күп дип ишеткән идем, растмы?» – дип сорагач, Дуңгыз: «Мин, борынымны кызганмыйча, чүплекләрне, көл базларын казыдым, әмма син әйткән байлыкларның берсенә дә очрамадым!» – диде.

## Аю

Аю ауга эләкте. Әҗәл – ерак вакытта уен гына, ләкин әҗәл якын килсә, эш бөтенләй башкарадыр. Аюның бер дә үләсе килми: җан татлы. Безнең Аю батыр сугыштан да кул тартмас иде, ни чара, аяклар ауга чорналган. Аның өстенә сәнәкләр, мылтыклар, этләр – барчасы моңар касд кыйлалар.

Аю, монда сугыш белән эш чыгарып булмасын белгәч, талашып котылудан өмид өзгәч, гакыл берлә хәлас тапмакчы булып, Аучыга бу рәвешчә ялына башлады: «И Адәм баласы! Син ни сәбәптән минем каныма сусадың? Әллә Аюлар хакында сүз йөртүчеләргә, шәйтаннарга ышанасыңмы? Син, әгәр бөтен дөньяны эзләсәң дә, Аюларның үлгән Кешене ашаганын күргән бер шаһит тә таба алмассың!» Аучы җавапта: «Сез Аюларга мәетләрне ашамаганыгыз өчен рәхмәт, ләкин сезнең кулдан тере Кешеләр сәламәт ычкынмыйлар. Әгәр сез, тере Кешене сәламәт калдырып, үлекләрне генә ашасагыз, бигрәк инсафлы хайван булыр идегез», – диде.

*

Аюларның үлгән кешене ашамаганлыклары мәгълүмдер.

## Арыслан илә Төлке

Төлке, иң беренче мәртәбә Арысланны күргәндә, куркуыннан чак кына үлми калды.

Менә күп үтмәде, ул тагы Арысланны күрде. Инде Арыслан аның күзенә ул кадәр үк куркынычлы күренмәде.

Өченче мәртәбә күргән иде, инде Арыслан белән кара-каршы сөйләшергә үк башлады.

*

Куркыныч һәр заман ияләнмәгәнгә генә була. Бер ияләнсәң, куркыныч та гади нәрсә генә булып кала.

## Тимерче вә Эте

Тимерченең Эте Тимерче шак-шок эшләгәндә йоклап ята иде.

Тимерче, эшләп бетергәч, хатын вә балалары илә ашарга утырды.

Шул вакытта гына Эт уянып, сикереп торгач, Тимерче, Эткә ачуланып: «И явыз хайван! Мин бөтен җирне тетрәтеп тимер сукканда уянмадың, әмма әкрен генә икмәк чәйнәгән тавышка уянасың», – диде.

## Алмас

Тимерчедәге иске тимер кисәкләре арасына бер Алмас кылыч ташланып, бу Алмас, шуннан базарга чыгарылып, базарда бер Мужикка сатылган иде.

Мужикның гыйлеме ни дәрәҗәдә икәне билгеле инде. Ул, Алмасны саплап, аның илә урманга барып, чабатага җүкә агачлары кисә башлады. Шулай ук самавыр куйганда чыралар яру, мич якканда чыбыклар кисү, көз көннәрендә бакчада бәрәңге, шалкан казу – барчасы Алмас хезмәте иде.

Шул рәвешчә Мужикка бер ел кадәре хезмәт иткәч, Алмас кителеп, теш-теш булып беткәч, Балалар Алмасыбызга атланып, ат итеп уйный башладылар. Ахырда Алмасның сабы да төшкәч, аны сәке астына ташладылар.

Шул ук сәке астында бер Бәрән бар икән. Бу Бәрән, Алмасның болай түбән дәрәҗәдә изелгәнен күргәч:

– И бичара Алмас! Синең бөтен дөньяны тоткан шөһрәтең кайда? Син чабатага җүкәләр хәзерләп, балчыклар казып, иң ахырда Балаларга уенчык булып йөрергә оялмыйсыңмы? – диде.

Алмас аңар каршы:

– Әйе, мин гаскәрләр кулында заманында дошманнарга Арысланнан гайрәтлерәк идем, әмма бу Мужик кулына төшкәч, дөрест, начар хезмәтләрдә йөрим. Ләкин бу тугърыда оят миңа булмый, бәлки минем ни эшкә яраганлыгымны белмәгән Хуҗамгадыр, – дип җавап бирде.

## Тычкан илә Күсе

– Күрше! Син бер шатлык хәбәр ишеттеңме? Мәче Арыслан тырнагына эләккән, ди, – дип, Тычкан йөгереп килеп Күсегә әйткәч, Күсе:

– Шатланма, күз нурым! Әгәр Мәче Арыслан тырнагына якынлашса, бер дә шиксез, Арысланны да һәлак итәр, Мәчедән көчле хайван юк, – диде.

*

Куркак, берәүдән курыкса, үзе курыккан кешегә бөтен дөнья курку күзе берлән карый дип уйлый.

## Ике Эт

Баеның хезмәтеннән бер дә ялыкмаган, чын күңелле, хыянәтсез Муйнак, үзенең иске дусты Актырнакның һәйбәт мендәрдә, тәрәзә төбендә утырганын күргәч, янына килеп, гүя анасын күргән шикелле булып, каннары кайнап, күзләрен яшьләндереп, тәрәзә янында койрыгын болгап, сикереп, гүя Актырнакның рәхәтенә көнләшкән шикелле булып тора иде.

Шул арада дусты Актырнакның хәлен сораша башлап:

– Йә, дус, нихәл? Ни эшләп торасың? Кәефләр хушмы? Мин карап торамын: сине бөтенләй боярлар шикелле кадерли башлаганнар. Әле исеңдәме? Күптән түгел синең илә мин, ачлыктан аз гына үлмичә, абзар каравыллый торган идек, – дигәч, Актырнак, җавапка керешеп:

– И дуст! Мин хәзер бик бәхетле, миннән Хуҗа һәм Хатыны үзләренең җаннарын да кызганмыйлар; шөкер Ходага, байлыкта, рәхәттә торамын, алтын-көмеш табаклардан гына ашыймын, ашап туйгач кәефләнәм, Хуҗа хатыны илә уйный башлыйм. Әгәр арсам, хәтфә паласларда, йомшак көрсиләргә ятып аунbackup, – дип, үз бәхетен сөйләп тәмам иткәч: – Ә син, Муйнак, ни хәлдә торасың? – диде.

Муйнак та, үз хәлен бәянга тотынып:

– Минем тормышым һаман үзең күргәндәге шикелле: суыкка да түзәм, ачлыкка да чыдыйм, Хуҗамның йортын саклап, ачык һавада яңгырларга да чыланам. Әгәр дә вакытсызрак өрсәм, башыма таяк та кабул итәм. Мин гаҗәпләнәм, Актырнак дуст, син үзең көчсез һәм кечкенә булып та, бу кадәр бәхеткә, бу чаклы рәхәткә ничек эләктең? – дигәч, Актырнак, янә сүзгә керешеп, көлемсерәп:

– И дустым! Кеше бәхетенә көнләшү гөнаһтыр. Беләмсең, мин арт аяк илә йөри алганым өчен шулай бәхетле булдым, – диде.

*

Дөньяда күп кешеләр бар ки, алар арт аяк илә йөргәннәре өчен генә бәхетле булалар.

## Сәүдәгәр

– Кил әле, иптәш! Син кайда югалдың, менә мин берәүне утырттым! Син дә, тиз байыйсың килсә, шулай сату ит. Үзең беләсең бит, минем кибеттә Нух пигамбәр заманыннан калган череп, саргаеп беткән ситсы бар иде. Хәзер мин аны, американский дип, бер ачык авызга саттым; менә хәзер генә бу кулымдагы йөзлекне шуннан алдым...– дип, бер Сәүдәгәр икенчесенә мактана иде.

Икенче Сәүдәгәр, әүвәлгенең кулыннан йөзлек кәгазьне алып, әйләндереп-әйләндереп карагач:

– И иптәш! Мин кайсыгыз алданганын бер дә белә алмадым; син фальшивый кәгазь алгансың бит! – диде.

*

Алдарлар. Бу Сәүдәгәр дә алдый язды. Анда бер дә гаҗәп юк.

Әмма кем булса да бу заман халкыны нечкәләп кенә караса, күрер ки, һәркайда, һәркемнең уе бары бер: кем кемне оста хәйләләр һәм кем кемне яхшы утыртыр.

## Әтәч илә Күке

– И сөекле Әтәч, нинди матур сайрыйсың!

– Ә син, Күкеҗан, бигрәк моңлы, бигрәк күңелле җырлыйсың! Синдәй сайраучы бөтен дөнья урманнарында да булмас. Аһ! Синең җырлавыңны үлгәнче тыңлап кына торыр идем. Менә, билләһи, ант итәм. Әгәр син сайраудан туктасаң, тагы кайчан гына сайрый башлар икән дип көтәмен. Минемчә, си-

нең тавышың янында Сандугач тавышы бөтенләй югаладыр; белмим, оҗмах кошлары сиңа пар була алырлар микән?..

Бу макташуны читтән тыңлап торган Чыпчык, Әтәчнең сүзен бүлеп:

– Сез, дустлар, бер-берегезне макташып киерелсәгез дә, музыкагыз һаман борынгыдыр, – диде.

*

Ни өчен, Алладан курыкмыйча, Күке Әтәчне мактый? Аның өчен Әтәч Күкене мактый?

## Мәче илә Сандугач

Мәче, Сандугачны тотып, бичараның тәненә үткен тырнакларын батырды. Һәм шул арада тәмле генә, сөчүк кенә тел илә Сандугачка бу сүзләрне әйтә башлады: «И Сандугачым, җаным! Мин сине дөньяда беренче сайраучы дип ишетә идем, синең сайравың һәртөрле музыкалардан матур булганлыктан, урмандагы көтүчеләр, ат ашатучылар – һәммәсе биһуш булганнар, имеш. Шуның өчен мин сине тотып, үз алдымда сайратып карамакчы булган идем; селкенмә, тиберченмә, кошчыгым, мин сине бөтенләй үк ашамыйм әле; курыкма, сайра әле, дустым. Әгәр сайрасаң, мин сине азат итәрмен, болынлыкларда, куакларда иркенләп йөрерсең. Син мине музыкага әһел түгел, иш түгел дип уйлама. Мин үзем дә эчем пошкан вакытларда бертуктамый мыраулап, мияулап йөримен».

Мәче болай сөйләгәндә, Сандугач, әҗәле якынайганны сизеп, кызганычлы тавыш илә чырылдый иде.

Мәче исә, Сандугачны мыскыл итеп: «И мискин! Шушы тавышың илә дөньяга исемең таралдымы? Һәм бу чырылдавың өчен егетләр, кызлар телендә сөйләнденме? Сүзем ялган булмасын, бу тавыш кына минем балаларымда да бар; сынадым, белдем, Сандугач, синең сайравың татлы түгел икән, инде татып карыйм әле, итең тәмлеме икән», – дип, бәхетсез шагыйрьне валчыгын да калдырмыйча тәмамлады.

*

Дустлар! Уйлап карыйк әле: Мәче тырнагында Сандугач сайрармы?

## Роща илә Ут

Юлчылардан калганмы, ничектер кыш көне Роща янында кечкенә генә бер Ут ялтырап яна иде.

Яңа утын беткәнлектән, Роща ераграк булганлыктан, Утның хәле сәгатьтән сәгатькә начарлана бара иде.

Ут, мискин, үзенең сүнүе бик якын калганны күргәч, Рощага әйләнеп, бу сүзләрне әйтә башлады: «И матур Роща! Бу кара көннәр сиңа кайдан килде? Мин күптән бирле карап торам, әмма синдә борынгы шикелле бер яфрак, чәчәк күргәнем юк; ботакларың туңган, бозланган; үзең өшегәнсең!»

Роща моңа каршы акрын гына: «Мин кыш көне асла яшәрә алмыйм, бөтен җирем карлана һәм бозланадыр», – диде.

Ут, янә сүзгә керешеп: «И мискин! Бу читенлек вә бу авырлыклардан котыласың килсә, минем белән дуст бул; мин сиңа ярдәм итәрмен. Кыш көне Кояш урынына мин торамын, һәм мин Кояштан ким хикмәтләр ясамыймын. Менә син кыш көне ачы бураннарда бер дә бозылмый үскән гөлләрдән гыйбрәт ал. Ул гөлләр, чәчәкләр – барчасы миңа рәхмәт укыйлар.

Әгәр мичтә мин булмасам, гөлләр, чәчәкләр – барчасы туңып, шиңеп бетәрләр иде.

Мин мактануны яратмыйм; шулай да мин көч ягыннан Кояштан бер дә калышмыйм; күрәсеңме, минем янымдагы карлар ничек эриләр.

Әгәр син кыш көне дә, яз вә җәй көннәрендәге шикелле матурлануны теләсәң, миңа бер почмагыңнан урын бир!» – диде.

Агач дисәң агач, Утның сүзенә ышанып, урын бирде. Ут иркенләде, ботактан ботакка йөгерә башлап, минуттан минутка кыза һәм ялкынлана бара иде.

Һавага болыт кеби кара төтеннәр күтәрелеп, бөтен дөньяны Ут каплады.

Ахырда Рощабыз тәмам һәлак булды.

Бервакыт, каты бураннан ышыкланыр өчен, бер Мөсафир борынгы Рощага килеп керсә, ни күзе берлә күрсен: әүвәлге күләнкәле агачлар урынында кап-кара күмер булган бүкәннәр генә калган.

## Бүре илә Тычкан

Соры Бүре көтүдән бер Куйны алып китте. Әлбәттә, кунакка алып китү түгел инде. Бер урманның аулак почмагына гына кереп, мискин Куйны ертып, өзгәләп, үзенең табигый ачкүзлелеге илә ашый башлады. Әмма никадәрле ашаса да, берьюлы ашап бетерә алмыйча, итне икенче ашарга калдырып, үзе, көчкә генә сулыш алып, кибән төбенә ятты.

Бүредән ерак түгел бер ояда яткан Тычканның борынына ит исе кергәч, Тычкан, күп уйламыйча, камыллар, чирәмнәр, куе үләннәр арасыннан килеп, үзе кеби кечкенә генә бер ит кисәген элде дә алдыартына карамый сызды.

Бүре, бу эшне күргәч, гакылдан шашып, бөтен урманны яңратып:

– Караул! Харап булдым! Тотыгыз каракны! Малымны урладылар! – дип кычкыра башлады.

*

Дустлар! Бүре бу малны үзе кайдан алган иде?

## Сыбызгы

Кечкенә чагында миңа бервакыт утыз тиен кадәр бакыр акча бирделәр. Бу кадәрле байлыкка куанып, мин дәрхаль уенчыклар сатыла торган кибеткә йөгердем дә, шул һәммә акчамны биреп, бер Сыбызгы алдым. Мин мондый бәхетле алуга шатлана-шатлана өйгә кайттым. Кайткач, Сыбызгыны бер дә кулымнан төшермичә, бертуктамый сызгыртып йөреп, өйдәгеләрнең һәрберсенең тынычлыгын качырдым.

Кечкенә сеңел вә энеләрем, минем Сыбызгыга никадәр түләгәнемне белгәч, миннән бик көлделәр: «Ул аның ярты хакына да тормый», – диделәр.

Соңыннан минем күз алдыма, әгәр Сыбызгыга шулкадәр акча бирмәгән булсам, калган акчага алынырлык әллә никадәр матур-матур уенчыклар килә башлады. Җитмәсә тагы, миннән кычкырып-кычкырып көләләр. Мин хурланып җылый башлыйм.

Шулай итеп, Сыбызгы миңа шатлык урынына хәсрәт кенә бирде, вәләкин бу хәсрәтнең ахыры минем өчен яхшы булды.

Мин бу бәхетсез сәүдәне һичбер вакыт исемнән чыгармас булдым. Бундан соң, кайчакта бер-бер нәрсә сатып алырга тугъры килсә, үз-үземә: «Сыбызгыга артык бирмә!» – дия идем дә акчам кесәдә кала иде.

Бара-бара мин үстем. Дөнья күрә вә кешеләр арасына керә башладым. Күрәм ки, кешеләрнең күбесе Сыбызгыга бик кыйбат түлиләр.

Бәгъзе кешеләр, халыкның ихтирам вә баш июен үзенә тарту өчен, әллә никадәр хәйлә, мәкерләргә чумып, артына карамыйча, әллә никадәр маллар түгеп, гакыйбәт фәкыйрьләнеп, мискинләнеп калалар. Боларны күргән чакта мин: «Ай-яй, бу кеше Сыбызгыны кыйбат алды», – дип уйлыйм.

Үзенең капчыгын кабартыр өчен генә дөньяның барча рәхәтләрен, бәхетләрен, изге эшләрен, дустлык вә кешелек хисләрен кире каккан саранны күргәндә: «Мискин кеше бу! Сыбызгыга никадәр күп түләде бит!» – дим.

Бер рәхәт вә тәмлене сөюче ялкауны, вак кына ләззәтләр өчен әллә никадәр киләчәкле эшләрне бер якка куючыны күргәндә: «Бичара кеше! Сыбызгыга ничаклы артык түләгәнеңне белмәвең һәм эшнең соңын уйламавың берлә син нинди кызганычсың!» – диясем килә.

Бик ялтыравыклы, кыйбатлы киемле, ифрат бай җиһазлы вә артык бәһале ат вә фәйтунлы бер мутның шартлавын күргәндә: «Киләчәккә бер дә күзе җитми шул, ул Сыбызгының үзенә нигә төшкәнен соң гына сизә шул», – дип куям.

Матур гына, сөйкемле генә бер кызның бер тупас, түбән фикерле кешегә кияүгә чыкканын күрсәм: «Нинди кызганыч кыз соң, ул үзенең Сыбызгысына шулхәтле кыйбат түли!» – дип уйлыйм.

Бер сүз белән генә әйткәндә, бәхетсезлекләр инсаннарның мал бәһасен белмәүләреннән вә үзләренең Сыбызгыларына ифрат артык түләүләреннән түгелме соң?

## Бытбылдык

Бытбылдык, диңгезгә кереп, барча җан-җанвар, кош-кортка: «Мин хәзер бу диңгезне яндырам», – дип мактанды.

Бу простой хәбәр түгел: шул ук сәгатьтә бөтен җир йөзенә, су төпләренә, урман араларына таралды.

Барча су падишаһлыгының халкына зур хәвеф төште; һәркайсының җаннары башларына сачрады. Һавага карасаң, көтү-көтү кошлар килә; урманнан гөруһ-гөруһ хайваннар шәһәрдә пожар булганда халык җыелган шикелле җыелалар. Һәрберсе: «Диңгез ни төсле булып янар икән?» – дип уйлыйлар иде.

Бу хәбәр авылдагы, шәһәрдәге кешеләргә дә таралган булырга кирәк. Кешеләр дә, бер кулларына кашык, икенчесенә икмәк тотып, балык шурпасы ашарга берсен-берсе егып, таптап, ашыгып чабалар.

Тамашачылар килеп бетте; һәркем, телсез кеше шикелле, тавышсыз-тынсыз диңгезгә күзен текәп тора иде.

Тик кайсы арада пыш-пыш кына: «Менә диңгез кайный башлар, менә янар», – дигән тавышлар ишетелә иде.

Кешеләр, хайваннар, кошлар көтәләр, көтәләр, көтү уттан да эссерәк булып эчләрен яндыра.

Аптырагач, бер-берсенә: «Ичмасам, кайный башламадымы?» – диләр иде. Диңгез исә янмый да, кайнамый да. Ахырда ни булды?

Бытбылдык оятыннан күзен йомып очып китте.

Дөньяга даны чыкты, әмма диңгез янмады.

*

Бу урында һичкемнең йөзен ертмыйча гына бер сүз әйтергә мөмкин: бер эшнең очына чыкмыйча, мактану кирәкмәс.

## Күке

Үзенең үтенүе буенча падишаһ Каракош Күкегә Сандугач дәрәҗәсен бирде.

Инде Күке яңа мәртәбәгә менде. Тәкәбберләнеп кенә бер усакка кунып, үзенең музыкаларын борып җибәреп, Сандугачча сайрарга тотынды.

Берзаман, бераз сайраганнан соң, бөтен кошлар минем тавышымны өелешеп тыңлап тора торганнардыр дип кошларга таба борылып караса, ни күзе белән күрсен: алар, кайсысы Күкедән көлеп, кайсысы Күкене орышып, мыгырдап баралар иде.

Безнең Күке бу эшкә бик ачуланды, кабарынды да, вакыт үткәрмичә, Каракошка барып: «И гадел падишаһ! Мин Сезнең әмерегез илә урманда Сандугач хезмәтен иттем, әмма кошлар, хайваннар миннән ятып-ятып көләргә батырчылык итәләр», – дип зарлангач, Каракош җавапта: «И Күкеҗан! Мин Ходай түгелмен, мин фәкать кошлар падишаһы гынамын. Шул сәбәпле мин сине Сандугач дәрәҗәсе илә хөрмәтли аламын, ләкин Күкене һичбер вакыт Сандугач ясарга кодрәтем юк!» – диде.

## Бала караучы

Җылан, Мужикка килеп, аның өендә торырга рөхсәт сорады. Әлбәттә, хезмәт итеп ашаган икмәк тәмлерәк буладыр. Җылан, сүз башлап:

– Дөрест, сез адәмнәрнең җыланнар хакында фикерегез начар; сез: «Җыланнар дустлык, татулык нәрсә икәнен белмиләр, хәтта үз балаларын үзләре ашыйлар...» – дип сөйлисез. Бу эшләрнең җыланнарда барчасы бар икәнен яшермим. Шулай булса да, мин андый җыланнар җөмләсеннән түгелмен. Мин туганнан бирле һичбер җан иясен тешләгәнем вә чакканым юктыр.

Әгәр мин агусыз да дөньяда торырга ышансам, авызымдагы укны суыртып алдырыр идем. Кыскасы гына, мин җыланнарның иң изгесемен. Әгәр бу сүзләремә ышанмасаң, сынамак өчен генә миңа балаларыңны биреп кара, – дигәч, Мужик:

– И Җылан дуст! Синең сөйләгәннәрең, ихтимал, ялган да булмас, шулай булса да, гаеп итмә, мин сине бала караучылыкка кабул итә алмыймын; син үзең, бәлки, изге дә булырсың, әмма синең хәзер азыкны ашап ятканыңны күргәч, синең яныңа йөзләп, меңләп усал җыланнар җыелып минем барча балаларымны һәлак итәрләр, – диде.

*

Дустлар! Бу тәмсилдән нәрсә фәһемлисез?

## Егет сайлаучан Кыз

Бер Кызның күңеленә кияүгә бару дәрте керде.

Хәер, монысы гөнаһ түгел, әмма гөнаһ менә кайда: бу Кыз бик егет сайлаучан иде.

Син бу Кызга шундый кияү тап: үзе яхшы һәм гакыллы булсын, дәрәҗәле булсын, простой булмасын, ак булсын, пакь булсын, матур булсын һәм, моны алгач, бик ихласлы сөйсен; хатыным дип, һичбер каты сүз әйтеп хафаларга батырчылык итә алмасын...

Бу сыйфатларның һәммәсе кемдә табылсын? Шулай булса да, Кызның ишегалдына һәр яктан өчәр атлы кияүләр, кияүләр генә түгел, кияүләрнең падишаһлары җыелалар иде.

Җә, инде нинди кияү сайларга кирәк? Кыз да чарлактан тамаша итә: кайсы кияү дәрәҗәдә түгел, кайсы дәрәҗәдә дә – медале аз; берсенең кашы куерак, икенчесенең борыны киңрәк, өченчесенең дәрәҗәсе дә бар, ләкин кесәсендә акчасы юк...

Әлхасыйль, матур Кызның күңеленә һичберсе ошамады.

Бераз көннән Кызның өенә һәр тарафтан яучылар килә башладылар; килсәләр дә, бу яучылар җә бик ямьсез, яки уртача гына кешеләрдән килгәннәр.

Матур Кыз үз-үзенә: «Минме аларга хатын булачак кыз? Мин андый кияүләрне каршымнан көтүкөтү кудым. Мин андый вак-төяк кияүләрнең һичкайсына бармам; әле мин кияүгә барырга ашыкмыйм, миңа кызлык гомере күңелле!» – дип сөйләнгәнлектән, бу яучылар да куылдылар. Болардан икенче яучылар да ишетеп, алар да Кыздан өмид өзделәр; асла килмәс булдылар, тик Кызның тәрәзә төбеннән генә сирәк-сирәк кияүләр үткәлиләр иде.

Шул рәвешчә бер ел үтте, ике ел, өч ел үтте, Кызга һичкем яучы җибәрми; теге яучы карчыкларны имгә эзләсәң дә таба алмассың.

Шулай итеп, күп-күп еллар үткәч, безнең Кызның да күзләре ачылды; ул үзенең Алма апай, Матур апай, Дустым апайларын берәм-берәм санарга башлады; бу апайларның һәрберсе балалы хатыннар рәтеннән саналалар иде.

Әмма бу егет сайлаучы Кызны бөтенләй онытканнар; гөнаһ шомлыгына каршы, Биби әби, Шәрифә карчыклар да килмиләр иде.

Ахырда, егет сайлаучы Кыз картайды. Мискинә көзгегә караса, көзге дә, бер дә яшермичә, җыерчыклана башлаган битне күрсәтә. Күзенең йолдызланган нурларын да ирсез үткән гомерләр урлаган. Сач тарый башласа, сачта да берничә бөртеккә кырау төшкән...

Менә һәр яктан бәла! Борынгы, ут янында әйләнгән күбәләкләр шикелле, моның тирәсендә йөргән егетләр кая киткәннәр?

Бичара Кыз, инде нинди генә ямьсез егет күрсә дә, өмидсез күзләренең кырые белән генә карый иде, әмма егетнең бу Кыз уенда да булмаган шикелле, моның Кыз икәнен дә белү ихтималы да юк иде.

Матур Кыз, һич булмаса, ахыр гомеремне ир белән үткәрим, дип, агач таяк белән йөри торган сиксән яшьлек бер Картка куана-куана барды.

*

Егет сайлаган кызларга гыйбрәт!

## Тавыклар һәм Каракош

Каракош бер кояшлы якты көндә туйганчы сәер итеп, рәхәтләнеп калмак нияте илә биек һаваларда, яшеннәр туа торган җирләрдә канатларын акрын һәм бик вәкарь берлән генә селкеп оча иде.

Берзаман ни сәбәптәндер әллә күп оча торгач, арып, хәл җыймак өченме, бу кошлар падишаһы бер кисмәк өстенә килеп кунды.

Падишаһның, шул җирдә генә бакчада булган имәннәргә, наратларга кунмыйча, кисмәк өстенә кунуына гаҗәпләнерлек тә бар. Әллә, кисмәккә аның мәрхәмәте килеп, кисмәк өстендә падишаһ утырганлык берлә мөшәррәф булсын, дидеме? Ни булса да булыр, падишаһларның серен белер хәл юк, Каракош шул кисмәк өстендә бераз вакыт утырып торды.

Моның монда утырганын күргән төкле аяклы, бүрекле Тавык иптәше илә бу түбәндәге сүзләрне сөйли иде: «И иптәш, бу каракошлар ни өчен бик кадерле булалар, һәрвакыт телләрдә сөйләнәләр һәм акчаларга да аларның сурәтен төшерәләр? Әгәр бу хөрмәт аларның очулары өчен булса, менә мин дә, әгәр теләсәм, кисмәк өстенә куна алам. Ул каракошларның да күзләре, аяклары барыбер безнеке шикелле ич. Иптәш, әле үзең дә күрдең: бу Каракош нинди түбән очты!»

Каракош, бу сүзләрне тыңлап торырга чыдый алмыйча: «И дустлар! Кайвакытта безгә Тавыктан да түбән төшәргә тугъры киләдер. Әмма Тавыкларга һичбер вакытта да болытка җитү насыйп булмыйдыр!» – диде.

## Мәрхәмәтле Төлке

Аучы яз көнендә Карлыгачны атып үлтерде. Бу бәхетсезлек Карлыгачның үлүе илә генә бетмәенчә, бичараның артында ике-өч баш яңа гына йомыркадан чыккан балалары калды.

Мескен балачыклар, аянычлы вә җан авырттыра торган тавышлары илә черелдәп, уянмас йокыга киткән аналарыны уятырга тырышалар иде.

Бу хәлне, бу күренешне караган кешенең, никадәр таш йөрәк булса да, җаны ачыр вә шәфкать каннары кайнарлык иде.

Берзаман Төлке, бу ятимнәрнең оясына якын килеп, шул оя яныннан үткән һәрбер коштан бу үксезләргә мәрхәмәт итүләрен сорап, суфиланып утыра иде.

Югары, күренер-күренмәс әйләнеп очкан Тургайга карап: «И син, Тургай! Юкка буш һаваларда канат талдырып әйләнгәнче бу атасыз-анасыз балаларга игенлекләрдән, кырлардан бер-ике бөртек орлык булса да китереп бирсәң, нинди савап булыр иде!» – дия иде.

Шул тирәдә генә йөргән бер Чәүкәгә дә: «И Чәүкә дуст! Синең балаларың әллә кайчан үсеп зур булдылар, инде алар үзләре дә үзләренә җитәрлек азык таба алырлар. Син инде менә бу тәрбиячеләре булмаган Карлыгач балаларына ана бул, аларны җылы мамыгың илә җылыт».

Шуннан пырхылдап очкан Чыпчыкка да: «Юкка чырылдап, пырылдап йөргәнче, күз алдыңдагы бәхетсез кошчыкларга чебен, чикерткә аулап ашатсаң, хисапсыз әҗерләр алыр идең. Анасызларга ана булып торсаң, боларның анасызлык кайгыларын оныттырыр идең», – дия иде.

Әлхасыйль, көннәр үтә. Белмим, Төлкенең нәсихәтләрен тыңлаучы булдымы, юкмы? Әмма баягы ятим кошчыклар, ачлык, сусызлыкта тыныч утыра алмыйча, берзаман Төлкенең авыз төбенә үк егылып төштеләр. Хәзер без карыйк: Төлкенең сүзе илә фигыле арасында нинди мөнәсәбәт бар икән? Төлке үзенең авызына төшкән бичара кошчыкларны кычкыртып, черелдәтеп ашады да китте.

*

Укучы! Исең китмәсен, кем ки яхшылык хакында сөйләп, кешеләрнең колагын тондырса, бел ки, ул кеше икенче берәүнең кесәсеннән генә яхшылык итәргә яратучы буладыр.

Ул яхшы белә ки: аның үзенә ул яхшылыктан бер тиен дә зарар килми, әмма үз өлешенә бер изгелек итәргә тугъры килсә, ул бөтенләй ушбу Төлке кеби буладыр.

## Картайган Арыслан

Каты нәгърәсе берлән урманнарны тетрәткән, гайрәте берлән барча җанварларны калтыраткан Арыслан картайды.

Борынгы көчле тырнаклары вә үткен тешләре зәгыйфьләнде; бичара Арыслан корышкан, салынган аяклары өстендә үз гәүдәсен көчкә генә күтәреп йөри башлады.

Арыслан шул хәлендә бервакыт сахрада аһ-ваһ итеп ыңгырашып ятканда, күзен ачып караса, күрә ки, барча хайваннар моның каршына искедәге үчләрен алырга килгәннәр: мискин Арысланны җә тәкәббер Ат килеп тибә, җә Бүре килеп тешли, җә үткен мөгезле Үгез килеп кабыргасына төртә иде.

Бәхетсез Арыслан, Ходайның тәкъдиренә буйсынып, күкрәге белән сулап, һаман әҗәл көтеп ята иде; берзаман дошманнарына тегәләбрәк карап күрде ки, Ишәк тә моны тибәргә әзерләнә; тик катырак авырта торган җирне сайлап маташа.

Арыслан, бу хурлыкны күргәч, егъларга керешеп: «И Раббым! Мине мондый оятлар берлә изгәнче, әҗәлне тизрәк җибәрсәң, бик разый булыр идем; миңа җан бирү никадәр авыр булса да, Ишәктән җәбер күрүдән артыграк булыр иде», – дия иде.

*

Үзеңнең барачак, йөриячәк юлыңа таш атма. Яшь вакытта ни чәчсәң, шуны карт көнеңдә урмыйча кабергә кермәссең.

## Батыр Кырмыска

Ниндидер бер Кырмыска тумаган һәм тумас диергә ярарлык дәрәҗәдә көчлелек илә мәшһүр иде.

Рави сахихның сүзенә караганда, бу Кырмыска ике, хәтта өч бөртек богъдай ярмасын ялгыз күтәрә аладыр иде.

Кырмыска шулкадәр батыр иде ки, күзенә бер Корт күренсә, аны хәзер барып үтерә, кайда гына бер Үрмәкүч күрсә, аңа да япа-ялгыз һөҗүм итеп, чагып үтерә һәм оясына да өстерәп алып килә иде.

Батыр Кырмыска сахрада шулкадәр шөһрәт тапты, хәтта Кырмыскалар ашаганда-эчкәндә, ятканда-торганда һаман моның батырлыгын гына сөйлиләр иде.

Батырымызның бу макталудан башы әйләнеп, үзенең көчен Кырмыскаларга гына түгел, шәһәрдәге адәмнәргә дә күрсәтмәкче булды.

Бервакыт Кырмыска печән төягән бер Мужикның арбасына үрмәләп менде дә шәһәргә юнәлде.

Мужик өенә кайтып җитте, печәнне бушатты; билгеле, Кырмыска да төшеп, үзенең көчен күрсәтеп, адәмнәрнең исләрен китәрү фикере белән эшкә кереште: пәһлеванызбыз йә бер саламны кузгата, йә бер яфракны селкетә; егыла, тора. Ләкин моның эшен нидәндер берәү дә күрми иде.

Кырмыска, аңар да карамый, һаман да эшендә; тирләде, пеште, әле һаман да халыкның Кырмыска уенда да юк.

Мискин пәһлеван, фикеренең бөтенләй үк яңлыш чыкканына хурланганлыктан, арба янында яткан Актырнакка карап: «И дустым, сезнең шәһәрдә кешеләр барчасы күзсез икән. Күрәмсең, ни гомердән бирле азапланам лабаса. Сукыр булмасалар, күрерләр иде; минем батырлыгымны безнең җирдә һич белмәгән кеше юк», – дип хурланып, ачудан чак ярылмыйча, кире сахрасына кайтып китте.

## Тәүбә иткән Төлке

Мужик, ничектер Төлкегә очрап, бу Төлке Мужикның тавыкларын бик кырганлыктан җөдәгәнгә күрә, бу рәвешчә Төлкене вәгазьләргә тотынды: «И Төлке дуст, бер дә яшермичә, дөрестен генә әйт әле, без бу урында икәү генә бит, ни сөйләсәк тә, ишетүче юк: син ни өчен һәрвакыт тавыкларны урлыйсың? Минем уемча, синең бу кәсебеңдә тузан кадәр дә изгелек булмаса кирәк. Мин үзеңне кызганам; гәрчә урлау зур гөнаһ та булсын, сине бөтен дөнья яманласын да, мин анысын әйтмим, аны Ходай үзе белер; әмма менә ничек синең бу кәсебеңдә изгелек, сәгадәт юк: син һәр иртәге ашыңда, көндезге ашыңда җаныңны кулыңа гына тотып, тавык оясына киләсең; һичбер куркусыз, качусыз азык таба алмыйсың. Шулай йөри торгач, ихтимал, беркөнне кыйммәтле туның да тавык оясында калыр»,– диде.

Төлке, бу сүзләрне ихлас берлән тыңлаганнан соң, җавапка керешеп: «И Мужик дуст! Бу тормыш, бу гомер кемгә һәм нинди җан иясенә килешсен? Син, иптәш, минем саф күңелле вә тугъры уйлылыгымны белсәң иде! Дөрест, караклык берлә кәсеп итүче дөньяда бер мин генә түгел. Шулай булса да, азык-суымның берсе дә хәлальдән булмаганлыгы исемә төшсә, үзем дә пычак алып суелырлык булам. Ләкин ни чара? Дөнья мәшәкате авыр, балаларым да бар»,– дигәч, Мужик, янә дә нәсихәткә башлап: «Син, Төлкеҗан, әгәр бу сүзләреңне ялган әйтмәсәң, мин сиңа хәләль азык та табып бирә алам: менә син минем тавыкларым оясына каравылчы бул, минем тавыкларымны икенче төлкеләрдән сакла. Син төлкеләрнең хәйләсен бик ачык беләсең. Минем өйгә барсаң, майга, иткә гарык булырсың, симерерсең!» – диде.

Төлке, Мужикның бу сүзләренә каршылык күрсәтмичә, аның өенә килеп, хезмәткә бил бәйләде. Монда Төлкегә рәхәт иде; Мужик бай, азык күп иде.

Безнең каравылчының тамагы туйды, симерде, йоннары ялтырап, матурланып китте. Ләкин, ни чара, күңеле һаман пакьләнмәде. Бервакыт караңгырак төнне генә көтеп торды да, тавыкларның барчасын буып ташлап, килгән юлы илә китте.

*

Намусы, ояты булган кеше, нинди тарлыкка төшсә дә, урламас; әмма каракка миллион тәңкә бирсәң дә, урлаудан туктамас.

## Фил

Фил ничектер падишаһ Арыслан каршында зур хөрмәткә ирәкте.

Моның болай дәрәҗәгә менүе урмандагы хайваннарга таралгач, алар: «Бу Фил карарга матур да түгел, сөйкемле дә түгел, ул кай җире белән Арыслан каршында хөрмәт тапты икән?» – дип, гаҗәпләнеп сөйләшә башладылар.

Шул арада Төлке, койрыгын болгап: «Әгәр Филнең койрыгы минеке төсле матур, мамыклы вә алтын төсле булса, мин аның дәрәҗәгә менүенә бер дә гаҗәпләнмәс идем»,– дигәч, Аю да, сүз башлап: «Әллә Филнең тырнаклары зур һәм үткен булганлыктан, ул Арысланга ошады микән?» – диде.

Башкалар сөйләгәндә мин нигә карап торыйм дидеме, Үгез дә: «Ул Филнең борыны астында ике ак сөяге бар бит, Арыслан аны, бәлки, мөгез дип белгән булыр»,– дигән генә иде, бер яктан Ишәк тә, чабата чаклы колакларын селкеп: «Мин беләм, әгәр Филнең колаклары зур булмаса, асла ул дәрәҗәләрне таба алмас иде!» – диде.

*

Без, макталган кешенең колакларын, борыннарын билгеләмәсәк тә, аңар катыштырып, үзебезне мак-

таштыргалыйбыз.

## Чүлмәк илә Казан

Чүлмәк илә Казан, бик дустланып, гомер буе аерылмаска вәгъдә куйдылар.

Чүлмәк балчыктан гына ясалып, Казан чуеннан булганлыктан, Казанның дәрәҗәсе югарырак булса да (җә, дустлашуда исәпләшү нигә кирәк?), болар дустландылар.

Шул дустлык буенча учак алдында, мич башында бу ике дуст һаман бергә күренәләр, дөресте генә, бер-берсеннән бер адым да аерылышмыйлар иде.

Менә берзаман Казан бу фани дөньяны тамаша итеп күрмәк ниятенә төште. Югарыдагы вәгъдәне бозарга ярамаганлыктан, Казан Чүлмәк илә бергә бер арбага утырып киттеләр.

Сәфәр бит, ахрысы. Шеш-шеш чыгып торган ташлы таулардан, әллә нинди тигезсез күперләрдән үтәргә туры килә. Казанның хәле тыныч, әмма Чүлмәкнең хәле минуттан минутка начарлана бара иде.

Шулай булса да, Чүлмәк, үзенең Казан берлән дуст булганына куанып, асла кире кайтуны уйламый, һаман бара гына иде.

Еракмы, никадәр җир йөргәннәрен белмим, әмма өйгә кайтканда, Чүлмәкнең тетелеп беткән кисәкләре генә кайтканын бик ачык беләмен.

*

Укучы! Дустлыкта берлек, тигезлек, тиңлек кирәклеген әйтмәсәм дә беләсең инде.

## Нәүхәчеләр

Борын заманда Мисырда шундый гадәт бар иде: мәсәлән, бер баерак кеше үлсә, аның җеназасы артыннан ялланган Нәүхәчеләр (Егълаучылар) җибәрәләр иде.

Шул Нәүхәчеләр, зыяратка барып җиткәнче һәм кайтканчы, җеназа артыннан бер дә калмыйча егълап йөриләр иде.

Бервакыт шәһәрдә бер кадерле Кеше вафат булгач, теге Нәүхәчеләр мәрхүмнең бәһасез гомеренең бик кыска булганлыгын вә аны ишексез, тәрәзәсез бер йортка алып барганнарын көйләп-көйләп әйтеп егълап баралар иде.

Бу кыйланышларны, бу аһ-ваһларны тыңлап торган бер намәгълүм Кеше, бу егълаучыларга хитабән:

– И сез, хәсрәт ияләре! Тавышыгызны басыгыз, кайгырмагыз; менә мин бер дога беләм, әгәр ул доганы укысам, мәет хәзер терелер, – дигәч, тегеләр, егълауларыннан туктап, барчасы бердән моның аягына егылып:

– И ата! Зинһар, хәлемезгә мәрхәмәт ит, син мәетне тергез, ләкин тергезгәндә тагы бер-ике көннән үләрлек булсын. Әгәр ул тагы бер мәртәбә үлсә, безне янәдән егъларга чакырырлар. Бу Кешедән тере вакытта бер тиен дә алып булмый иде, әгәр ул терелеп, дөньяда тора калса, тагы да бер тиен дә бирмәс,– диделәр.

*

Шундый байлар бар ки, аларның әҗәле генә бер файдага ярыйдыр.

## Аш пешерүче

Ниндидер бер Аш пешерүче, биш-ун гына минутка күршедәге кабакка кереп, ашханәдәге кәбаб булачак итләрне тычканнан, күседән сакларга Мәчене калдырган иде.

Берзаман Аш пешерүче кайтып керсә, ни күзе берлә күрсен: идәндә бәлеш төпләре, каз ботлары, паштет эчләре аунап яталар. Әмма каравылчы Мәче, почмактагы серкә мичкәсе янында мыраулап, миялап, пешкән үрдәкне ашап ята.

Аш пешерүче укыганрак кеше булса кирәк, дәрхаль Мәчене вәгазьләргә башлап: «И оятсыз! Битсез! Син бу эшне эшләргә кешеләрдән генә түгел, хәтта стеналардан оялырга кирәк иде. Бу сәгатькә кадәр синең изгелегең, синең тугърылыгың мәсәлләрдә сөйләнә иде. Инде барча күршеләр сине яманларлар: «Ул Мәче бозык! Ул Мәчене ашханәгә кертү түгел, ач Бүрене абзарга кертү ярамаган шикелле, аны капкадан да кертергә ярамый»,– диерләр.

Мәче исә вәгазьне тыңлый; тыңласа да – һаман эшендә.

Аш пешерүче сүзнең буасын җибәргән: аның авызыннан аккан вәгазьләрнең хисабы юк иде. Ашчы вәгазь сөйләгән арада, Мәче дә чебешне тәмам иткән иде.

*

Бу Аш пешерүчегә, Мәчене сүз берлә инсафка китерергә тырышканчы, чыбык берлә тәэдиб итәргә кирәк иде.

## Чабак

Мин пигамбәр түгел. Әмма шәм янында күп әйләнгән күбәләкнең канаты көячәкне алдан хәбәр бирәмен. Болай итүем илә мине «пигамбәрләнә» дип сүкмәңез.

Исемдә юк, нинди суның яр башындадыр, су падишаһлыгының дошманнары – балыкчылар, кармакларыны салып, калкавычтан бер дә күзләрен алмыйча карап утыралар иде.

Мәгәр шул җирдә генә үз-үзен җитез һәм үткенгә санап йөргән вә үз-үзенә бик ышанган бер Чабак тора иде.

Чабак сукыр түгел, кармакны күрде. Менә ул кармак берлән уйнарга тотынды: бер ук шикелле атылып кармак янына бара; бер артка китә; бер атылып китә дә, гүя Балыкчыдан көлгән шикелле, Чуалчанның башыннан гына капкан булып тартып, үзе артка качып китә, янә килә дә кармакның җебеннән азрак тарткалап китә.

Балыкчы исә, «әнә эләгә, менә эләкте» дип, тик йөрәге сикереп утыра.

Кармакны алып карый, очы күренә; салынган Чуалчан ашалган. Янә сала, янә ала. Чабак та кармак янында кубар шикелле әйләнә.

Шул рәвешчә Балыкчы илә Чабак алдашып, хәйләләшеп торганда, бер күпне күргән Карт балык Чабакка бу сүзләрне әйтә иде:

– И җүләр Чабак! Син ни өчен һаман кармаклар тирәсендә әйләнәсең? Әллә сиңа кармак тирәсеннән башка суда урын беттеме? Гафил булма, син кармакка якынлашкан саен, бәлагә дә якынлашасың. Әгәр бу сүземне тотмасаң, син озакламыйча безнең су илә бәхилләшерсең.

Гакыллы сүзне ахмакка әйт, чукракка әйт – икесе дә бердер.

Чабак бу нәсихәткә каршы:

– И ата! Син юк нәрсәдән куркасың. Дөрест, кешеләр хәйләкәр, әмма мин аларның хәйләләрен ап-ачык күреп торам. Менә күрәмсең: монда бер кармак, әнә тегендә икенче кармак. Син, ата, карап тор әле, мин ничек балыкчыларны кызык итәрмен, – дип сөйләнә-сөйләнә, яшен шикелле атылып бер кармакка барып ябышты.

Берсеннән китте, икенчесеннән үтте. Ах! Өченчесенә барып эләкте! Инде качмакчы да булды, әмма соңрак иде.

## Кыр кәҗәләре

Көтүче кыш көнендә урманда бер агач төбеннән берничә Кыр кәҗәләре тапты.

Менә, Көтүченең уенча, байлык! Менә хәзинә!.. Бу кадәр байлык вә бәхеткә ничек чыдарга кирәк? Көтүче, мискин, ихтыярсыз, күзеннән яшь чыгара-чыгара, Ходайга шөкер итә иде.

Көтүчегә куанырга, шөкер итәргә юл да бар: бу Кәҗәләрдә Хуҗаның асла катышы юк. Боларның җонын да Көтүче үзе кыркачак, сөтен дә үзе савачак...

Ләкин эшнең бер җире генә килешмәде: ул да, вакыт кыш көне булганлыктан, бу Кыр кәҗәләрен ашатырга печән булмавы вә, булса да, азлыгы иде.

Күп уйлар, күп фикерләр соңында безнең Көтүче моңар да акыл тапты: ул үзенең Сарыкларының печәнен әкрен-әкрен бу кунак Кәҗәләргә ашата башлады. Көтүченең күңеле ачылган, кунакларны сөя, башларын сыйпый; Кәҗәләре янына көненә йөз мәртәбә генә килә торгандыр!

Кайвакыт бу кунакларның азыгына иске хуҗа – Сарыклары сузыла башласалар, бичараларның башларына сугып җибәрә иде.

Әлхасыйль, яңа кунакларның зарары булса кирәк, яз башына чыкканда, Сарыкларның коры сөякләре генә калган иде.

Берзаман көннәр җылынып, урманнарда яшеллекләр генә күренә башлаган иде, Кыр кәҗәләре барчасы берьюлы, Көтүчегә койрыкларын гына күрсәтеп, урманга качтылар.

*

Көтүче! Мин сиңа бер сүз әйтим, хәтерең калмасын: син, Кыр кәҗәләрен сыйлап азык бетергәнче, үз Сарыкларыңны яхшы сакласаң булмасмы иде?

## Этләрнең дуст булышуы

Ашханә тәрәзәсе төбендә Актырнак илә Сарыбай кояшка каршы җылынып яталар иде.

Шулай ятканда, сүздән сүз чыгып, этләрнең тормышларыннан, көн күрмешләреннән күп сүзләр сөйләнде.

Актырнак әйтә: «И дустым! Бу дөньяда сөешү-дустлашудан да татлырак нәрсә бар микән, ике җанның берләшеп, берсен берсе тәгъзим вә ихтирам итүеннән дә күңелле эш бар микән? Менә безнең арамызда шундый дустлык булса, без гомеремезнең ничек үткәнен дә белмәс идек».

Сарыбай, моны тыңлап торгач: «Мин күптән шуны уйлыйдыр идем. Без икемез дә бер йортның каравылчылары булгач, безгә ни өчен кычкырышырга һәм ни сәбәпле талашырга? Хуҗаларга рәхмәт: ашарга, эчәргә бар; ач булмыйбыз. Белмим, ни өчендер безнең ата вә бабаларымыз бер-берсе илә тату тормаганнар. Менә, Актырнак дуст, бир кулыңны, без икәү кыяматкә кадәр аерылмаска дуст кушылыйк һәм үземездән соңгыларга да күчергеч булыйк», – дип сүзне бетергәч, Актырнак Сарыбайга кулын бирде, бөтенләй ахирәт дустлары булдылар.

Бу эштән соң яңа дустлар бик куаныштылар. Хәзер генә анадан туган кеби җиңеләйделәр. Шатлыклары эчләренә сыймаганлыктан, кая барып бәрелергә дә белмиләр иде.

Шуннан берничә минут үтмәде, бу ике дустлар кочаклашып, берсен берсе куышып, сикерешеп уйный гына башлаганнар иде, гөнаһ шомлыгына каршы, шул арада ашханә тәрәзәсеннән бер сөяк ташладылар.

Менә берзаман дустлар сөяккә йөгерешеп бардылар. Сөякне берсе берсенә бирәселәре килми. Һәр икесе тешләрен ыржайтып талашырга, чәйнәшергә тотындылар, канга батыштылар.

Бу хәлне Хуҗалары күргәч, дустларның өстләренә салкын су сибеп, көчкә-көчкә генә аерып җибәрделәр.

*

Мондый дустлыклар илә дөнья тулгандыр. Замана дустларын сөйләгәндә, гөнаһлы булмыйча сөйләмәк мөмкин түгелдер. Ике дустның сөйләшкәннәрен тыңлап торсаң, боларның җаннары бер икән дип уйларсың; аларга сөяк ташласаң, бөтенләй ушбу этләр кеби булалар.

## Бала Козгын

Һавадан бер Каракош, килеп, куй көтүе өстенә төште дә туганына бер-ике генә ай булган бер Бәрәнне тырнагына элеп китте.

Бу хәлне якыннан гына карап торган бер Козгын баласы, күреп, үзенә-үзе: «Инде алгач, зуррак куйны алырга кирәк иде; бу Каракошларда бер дә акыл юк икән, андый маңка Куйлар илә нигә тырнак пычратырга кирәк! Бу кадәрле зур көтүдә Бәрәннән башкалар да бар ич. Менә мин, теләсәм, нинди Куйны алырга белермен»,– дип сөйләнә-сөйләнә, көтү өстенә очып барып, барча Куйларны күзеннән кичергәндә, моңар Сыердан аз гына кечкенә бер Кучкар күренде.

Бу Кучкар безнең бала Козгынның күңеленә ошагач, ул, озак уйламаенча, Кучкарның бөдрәләнеп-бөдрәләнеп оешкан киез шикелле толыбына үткен тырнакларын батырды.

Инде, безнең канатлы аучыбызның уенча, табыш бик зур, тик эш күтәреп очуда гына калган. Әмма һәр җирдә тугъры килгән «яшьлек – җүләрлек» мәкале безнең бала Козгынга да кыек килмәде. Бичара Козгынчык азыкны күтәрергә көчәнә, азаплана, вә хәлбуки теге Кучкарның аучы тырнагына эләккәненнән хәбәре дә юк; ул әүвәлгечә тыныч кына авызындагы чирәмне чәйнәп тик тора.

Хәзер инде безнең аучы аудан өмид кисте. Инде, ичмаса, үзе генә котылса да күп шөкер итмәкче була. Ләкин ачкүзлелек илә тырнаклар бик тирән баткан, кадаклап куйган шикелле, селкетер дә хәл юк.

Бу хәлне Көтүчеләр күрделәр дә, Козгынның тырнакларын пычак белән кисеп, көчкә генә алдылар. Соңра, очып китмәсен дип, аучының канатларын да кисеп, үзен балаларга уйнарга бирделәр.

*

Бертөрле гакыллырак татар сәүдәгәрләренең Мәскәүдән бер-ике мең генә алып, эшне машина кеби

әйләндергәнен икенчеләре күрәләр дә, алардан көлеп, биззат үзләре Мәскәүгә барып, кырык-илле меңлек вексельгә кул куялар да бөтенләй ушбу яшь Козгын хәленә төшәләр.

## Үткен пәке

Бер Иптәшем илә сәфәрдә йөргәндә, кич булгач, бер авылга фатирга кереп, йокыга яттык.

Берзаман иртә берлән торсам, күрше бүлмәдән Иптәшемнең кычкырган, ыңгырашкан, ишәк кеби бакырган тавышы ишетелә.

Кичә кич кенә бернәрсәсез, сәламәт яткан Иптәшемнең бу хәленә гаҗәпләнеп, бүлмә аркылы: «Ни булды сиңа, Иптәш, әллә бер-бер төрле авыру эләктеме?» – дип сорадым.

Иптәшем җавапта: «Юк, бернәрсә дә юк, тик бераз сакал-мыек кына төзәтәм»,– диде.

Соңра мин, тавыш һаман да туктамагач, аның янына бардым.

Карасам, моның кулында бер үтмәс чалгы пычак, каршында көзге: чыраен сытып, кашларын җыерып, мыек төзәтеп утыра.

Бичара, үтмәс пычак илә кыра торгач, иякләрен, ireннәрен тәмам кискәләп бетергән, куллары вә авызы канга буялган.

Белдем ки, моның ишәк тавышлары чыгаруына сәбәп шул икән!

Шулай бу кызыкны тамаша итеп торган чагымда, Иптәшемнең янында гаять үткен һәйбәт английский пәке күрдем дә аңар: «Ник бу яхшы пәке илә файдаланмыйсың?» – дидем.

Иптәшем җавабында: «Үткен пәке иренемне кисәр дип куркам»,– диде.

*

Дөньяда күп кешеләр бар ки, үткен вә гакыллы кешеләрдән куркып, үз тирәләрендә күбрәк ахмакларны йөртәләр.

## Тычканнар киңәше

Тычканнар, беркөнне җыелып, үзләрен һәртөрле куркынычлардан сакламакчы булдылар.

Бу җыендагы гакыл илә Тычканнарга, Мәчеләрдән курыкмыйча, Аш пешерүчеләрне, Асрауларны бер дә шикләнмичә гакылдан яздырырга мөмкин булачак.

Бу мәҗлестә рәис, кемнең койрыгы озын булса, шул булачак булды. Тычканнарның игътикадларынча, кемнең койрыгы озын булса, шул гакыллы була, имеш.

Тычканнарның бу фикерләре хатамы, дөрестме – без анысын тикшермибез. Әле без, инсаннар була торып та, кешене һәм гыйлемен мыегы берлә киеменнән үлчимез. Без әле хикәямезгә килик: тычканнарның мәслихәте буенча барча озын койрыклылар сайландылар. Әгәр арада берсенең койрыгы өзелгән булса, аны мәҗлескә кертмәскә карар бирделәр.

Тычканнар, Күселәр кеби сугыш эчендә үскән халыкка койрык өзелү генә гаеп саналмаска тиеш булса да, нидәндер койрыксыз булу җә бер уңмаганлыктан, җә гакыл камил түгеллектән санала иде.

Бервакыт эшләр җайга салынды; мәҗлес әркяны бер караңгы төндә келәттәге он ларында җыелыштылар.

Хакимнәр җирле-җиренә урнашкач ук, кайдандыр бер койрыксыз Күсе килеп чыгып, хөкем итә башлады.

Бу хәлне бер яшь Тычкан күргәч, иптәшләренә хитабән: «Карагыз әле! Бу койрыксыз Күсе ни өчен безгә хөкем итә? Безнең баягы карар кая китте? Әгәр бу хаким булырга ярарлык Күсе булса, үз койрыгын үзе саклый белер иде. Бу койрыксыз безне генә түгел, бөтен идән асты халкыны харап итәр»,– дигәч, бер карт Тычкан, бу яшь Тычканны орышып: «Син тик утыр! Бик күпне белә башладың! Бу койрыксыз Күсе минем кодам ич»,– диде.

*

Дөньяда кода-кодагый хәтере өчен күп иттифакълардан чыгыла.

## Әтәч илә Энҗе бөртеге

Чүплек башларында казына торгач, Әтәч ничектер бер Энҗе бөртеге тапты да үз-үзенә сукранып сөйләргә тотынды: «Энҗе дигән булалар! Бу Энҗе нинди юк нәрсә! Әгәр бу табылганчы, миңа, казып мәшәкатьләнгәнем өчен, бер Тары ярмасы табылган булса, мин нинди шат булыр идем».

*

Түбән фикерле кешеләр, нәрсәләрнең кыйммәтен белмәгәнлектән, күп вакытта шушы Әтәч кеби хөкем итәләр.

## Йөкче илә Юл кисүче

Олы юл янында, куаклыкта, кичкә табарак бер юл кисүче Карак, оясыннан башын чыгарып яткан ач Бүре кеби, киң сахраларны, ерак тауларны бер-бер күзеннән үткәреп, кичке ашлык бирәр нәрсә булмасмы өмиде илә ята иде.

Берзаман Карак ерак түгел бер авыр йөк илә килгән Йөкчене күрде.

Менә Каракның уенча бәхет!

Бу йөк, әлбәттә, ярминкәдән чәй, шикәр, ефәк, постау алып кайта торгандыр, дип уйлады.

Йөк якын килеп җиткәч тә Карак: «Тпрру! Тукта!» – дип кычкырды да кулындагы зур күсәге илә Йөкченең өстенә ташланды.

Йөкче мискин – начар, кечкенә кеше һәм юл йөреп арыган иде. Шулай булса да, мал вә җан татлы бит: Йөкче дә, арба кендеге алып, Каракка каршы торды. Ул, гәрчә тәбәнәк кенә, кечкенә генә кеше булса да, мал вә җан тугърысында тау кадәр булып китте.

Сугыш башланды. Бу сугыш озак һәм куркынычлы булып, шактый мөддәт дәвам иткәч тукталды.

Каракка күп зарар юк, тик бер күзе генә чыккан да бер дюжина теше генә коелган вә бер кулы гына сынган.

Шулай да җиңү һаман Карак тарафында калды, Йөкче үлде.

Хәзер инде тыныч калды, тизрәк йөкне карарга кирәк: анда нәрсә бар? Хәер, Каракның сугышы бушка китмәгән: йөктә салам берлә төргән бик күп лампа пыялалары бар икән.

*

Дөньяда шундый юк кына нәрсәләр өчен шулкадәр зур җинаятьләр, олугъ кансызлыклар кыйлалар.

## Ике Күрше

Күрше Күршесене кунакка чакырды.

Чакырылмыш Күрше сыйланырга чакырылдым дип уйласа да, Чакыручының максуды үзенең күптән түгел генә яллаган җыручыларын Күршесенә күрсәтү иде.

Җырлаучы Егетләр җырларга тотындылар: кайсының тавышы калын, кайсыныкы нечкә; берсе артка кала, икенчесе тамак кыра, өченчесе йөткерә...

Бичара Кунакның, мондый ямьсез тавышлардан башы әйләнеп: «И Күрше, Күрше! Син мине чакырып, кәефләндерәм дигән булып, тик күңелемне генә болгаттың»,– дигәч, Чакыручы: «Бик дөрест әйтәсең, Күршем, мин аларның начар җырлаганнарын үзем дә беләм, бары мин аларны аракы эчмәгәннәре өчен генә яратам»,– диде.

## Яшь Агач

Мужикның урманда балта тотып барганын бер яшь Агач күрде дә, Мужикка кычкырып:

– И Агай! Зинһар, хәлемә мәрхәмәт итеп, минем тирә-ягымдагы карт Агачларны кисә күр; мин, алар каплап торганга күрә, якты дөньяны күрә алмыйм вә иркенләп, рәхәтләнеп үсә алмыйм; тамырларым да, шушы карт Агачлар тыгызлаганга күрә, кирәгенчә җәелә алмыйлар. Миңа җил дә, кояш нуры да керә алмый. Әгәр син карт Агачлардан мине коткарсаң, мин бер ел эчендә урманның беренче матур Агачы була алыр идем, бөтен сахра минем күләгәм илә капланыр иде. Менә, күрәмсең, шул картлар зарарыннан минем калынлыгым һаман чыбык шикелле генә, – дип ялынгач, Мужик, үзенең беренче дустына хезмәт күрсәткән шикелле, безнең яшь Агачка ярдәм күрсәтмәкче булып, кулына балтасын ипләп тотып, аз гына вакыт эчендә теге карт Агачларның һәммәсен кисеп аударды.

Менә инде яшь Агачның күңеле булды, куанды, аңар дөнья иркен калды.

Ләкин бу куанулар урынлымы?

Хәзер инде бичара яшь Агачны кояш яндыра, җә бозлы яңгыр кәефен ала, җә ком, туфрак бураны килеп, җиргә чаклы бөгеп, иелдереп китә.

Көннәрдә бер көн бик каты җилле давыл килде дә яшь Агачны шартлатып сындырды да китте.

Бу хәлне күреп торган бер Җылан, җирдә сынып яткан яшь Агачка карап:

– И яшь бала! Инде кемгә үпкәләмәкче буласың? Бу бәла синең үзеңнән булды. Әгәр син карт Агачларга тарланмаган булсаң, ул агачлар сине җилдән, яңгырдан саклаган булырлар иде; син ышыкта, тыныч кына, рәхәтләнеп үсәр идең.

Гакылсыз! Ул Агачларга да мәңге суы сипмәгәннәр иде, аларның гомере беткәнен көтсәң, аңарчы син дә үсеп куәтләнер идең, үз нәүбәтеңдә син дә зур Агач булып дөньяны күреп торыр идең, һәм бу бәлаләр башыңа килмәгән булыр иде, – диде.

## Күл

Көтүче, Идел янына утырып, яңагына таянып, үзенең кайтмаска югалган бер малы тугърысында моңланып-моңланып җырлап утыра иде. Бичараның күптән түгел генә бер сөекле Бәрәне Иделгә баткан иде.

Көтүченең бу зарларын тыңлап торган кечкенә генә бер Күл, Көтүченең кайгысын уртаклашып вә Иделне яманларга керешеп: «Бу Идел бигрәк ачкүзле, һичбер вакыт туя белми. Әгәр аның төбе дә минем төбем шикелле аркылы күренә торган булса, ул обжорның нәрсәләр йотканы бик ачык күренер иде.

Мин, әгәр дә Идел шикелле гөнаһлар эшләсәм, оятымнан җирне казып югалыр идем яисә караңгылыкларга кереп яшеренер идем.

Әгәр тәкъдир миңа ул кадәр күп сулы булырга язган булса, мин, һич шөбһәсез, бөтен дөньяның бизәге булыр идем, суларым илә хәтта тавыкка да зарар китермәс идем.

Минем суларым бик сакланып кына агар һәм агач ботакларын булса да агызмас иде; бөтен сахра вә ярларым миңа рәхмәт укырлар иде.

Мин бөтен кырлар вә болынлыкларны терелтер идем, ләкин аннан бер генә яфракны булса да агызып китмәс идем.

Кыскасы, һичбер җирдә кайгы вә хәсрәтләр ясамыйча, минем суым, саф көмеш кеби, диңгезгә кадәр тын гына агып барыр иде», – дип сөйләнә иде.

Күл шулай сөйләнгәннән соң, бер атна үтмәде, шул тирәдәге тауга чиләкләп-чиләкләп яңгыр яуды. Аның таулардан аккан сулары безнең Күлгә төшеп, Күл суга баеды, Идел илә бәрабәр булды.

Менә берзаман Күлнең котырган дулкыннары ярлардан сикереп чыгалар, очраган төпчек вә бүкәннәрне шар кеби тәгәрәтеп агызалар, хәтта меңьеллык имәннәрне дә аударалар; аны батыралар, моны агызалар...

Җә, хәзер безнең Күлнең баягы җуашлыклары, инсафлары кая киткән?

Бу Күлнең сулары беркөнге кайгырып утырган Көтүчене дә барча сарыклары илә бергә агызып алып китте.

*

Бәгъзеләр, баесам – фәлән итәр идем, баесам – төгән итәр идем, диләр дә, баегач, менә шушы Күл кеби булалар.

## Сукыр тычкан һәм Каракош

Ерак җирләрдән килеп, Каракош илә хатыны бер кара урманга кереп, бер карт имәнгә оялап, бөтен гомерләрен шунда үткәрмәкче булдылар.

Бервакыт үзләре сайлап тапкан бер карт имәнгә оя ясап, җәй буе шунда балалар үстерергә уйладылар.

Боларның бу ниятләрен ишеткән бер Сукыр тычкан Каракошка:

– И Кошлар падишаһы! Бу сез оялаячак имәннең төбе чергән, тиз заманда авып төшү ихтималы бар. Мин сезгә бүтән агачка оялауны мәслихәт күрер идем,– дип киңәш бирсә дә, Каракош агач төбендәге чокырдан ни эшләп киңәш алсын? Бөтен халыкның Каракошның күзләре үткен дип мактаулары кая китә? Һәм Сукыр тычканның падишаһлар эшенә керешергә ни эше бар?

Ул, Сукыр тычкан берлә күп сөйләшмичә, ояны тиз генә ясарга кереште.

Озак та үтмәде, падишаһның сарае эшләнеп бетте. Бара торгач, балалар да булды, бәхет өстенә бәхет!

Берзаман Каракош иртә берлән, хатын вә балаларына азык алып, шатланып кайтса, ни күзе берлән күрсен: имән ауган, һәм Падишаһ хатыны вә Шаһзадәләр барчасы басылып үлгәннәр.

Бу эштән Падишаһ кошның йөрәге янып, үз-үзен бу рәвештә шелтәли башлады: «Мин бу бәлане һичнәрсәдән түгел, тик үземнең тәкәбберлегемнән генә күрәмен. Мин бик хур күргән Сукыр тычкан миңа ана нәсихәте кеби яхшы үгет бирде. Мин исә, нәфесемә ияреп, кабул итмәдем».

Шул арада бер яктан Сукыр тычкан да: «И Падишаһ кош! Үзеңә мәгълүм: минем оям һәрвакытта да агач төбендә була, шул сәбәпле мин тамырлар хәлен бик яхшы беләм»,– дип, Каракошның җәрәхәтенә тоз сипте.

**Шигырь**

Бән димәгел, бән димәктә күп бәла;
Бән димәклә улды шәйтан мөбтәля.

## Мәче баласы һәм Сыерчык

Кайсыдыр бер өйдә бер Сыерчык бар иде.

Үзе сайрау һөнәрендә начар булса да, бик гакыллы вә фикерле булганлыгыннан, сайравының начарлыгыны яшерә аладыр иде.

Шул ук өйдә бер Мәче баласы да булып, Сыерчык моның илә араларына кыл да сыймаслык дәрәҗәдә дуст иде.

Мәче баласы да, бик җуаш булганлыктан, Сыерчыкка сөемле иде. Бервакыт боларның хуҗалары кунаккамы, кайдадыр китеп бик озак торгач, Мәче баласы һәр көн барып ризыклана торган ашъяулыктан аерылып, моны ачлык, кыйхытлык җөдәтә башлады.

Мәче баласы, рузаның катылыгы үзәгенә үткәнлектән, идән буенда кызганыч тавышлар илә мыраулап, күңелсезләнеп йөри иде.

Бу хәлне күреп торгач, Сыерчык Мәче баласына киңәш юлында шушы рәвешчә сүзгә кереште:

– И дустым Песи! Син бигрәк саф күңелле вә җуаш табигатьле икәнсең, мин синең үз файдаңны үзең белмәвеңә исем китә. Әнә борын астындук читлектә Тургай асылынып тора. Читлек ишеген ач та шул Тургайны алып аша. Син гафил булма, сиңа балалыгыңны ташларга вакыт инде. Бу дөньяда кем көчле булса, ул ни кыйлса да ирекле.

Фәйләсүф Сыерчыкның бу сүзләре Мәче баласының хушына китеп, ул, дәрхаль читлекне ачып, Тургайны чыгарып, тотып ашады.

Бу Тургай, гәрчә Мәчене туйдырырлык булмаса да, йөрәк ялгарга ярады.

Соңра Мәче баласы, бөтенләй туюның да юлын эзләп, як-якка карады да, озак уйламыйча, теге киңәшне өйрәткән хәлфә Сыерчыкның үзен дә тәгъзим берлә генә ашады.

*

Берәү кардәшенә кое казыса, үзе төшәр.

## Сандугач

Ниндидер бер кош Аулаучы, урманнардан, куаклыклардан аулап, берничә Сандугач тоткан иде. Мискинчекләрне һәркайсын үз өендә сайратыр өчен, почмакларда асылган читлекләргә ябып куйды. Бу бичараларның сайрар һәм кәефләнер урыннары куаклар башы иде. Инде зинданга ябылгач, сайрау кайгысымы? Шулай булса да, ни эшләмәк кирәк! Болар кайсы кайгыдан вә кайсы ялгызлыктан сайрашалар иде. Боларның арасында бигрәк моңлысы, бигрәк газап чиккәне үзенең сөйгән дустыннан аерылган бер Сандугач иде. Бу бәхетсез кошның яшь аралаш күзләре һәр заман кырлар, сахралар тарафына текәлгән иде. Әмма егълаганга карап хәсрәт бетәме соң? «Гакылсызга авырлык төшсә – җылый, гакыллыга читенлек килсә – котылырга чара эзли» дигән шикелле, бу Сандугач та үзен-үзе ушбу сүзләр илә җуатырга керешге: «Тукта әле, мин ни өчен бу чаклы хәсрәтләнәм? Әлбәттә, мине суярга дип тотмаганнар. Хуҗам да җырларны, матур сайрауларны тыңларга һәвәсле. Әгәр мин яхшылап сайрап, тавышымның матурлыгы хуҗама ошаса, ул мине яратыр; яраткач, мине бу зинданнан коткарып, азат итү ихтималы да бар».

Кошымыз шулай уйлады вә уйлаганынча сайраргa да башлады.

Бу үзенең кайгылар тарата вә күңелләр дәртләндерә торган сайраулары илә кичке таңны озаткан шикелле, иртәге таңны да каршылый иде.

Ахырда ни булды? Яшь кош бу сайравы илә үзенең бәхетсезлеген генә арттырды: начар сайраган яки бер дә сайрамаган Сандугачларга читлек ишеге әллә кайчан ачылды, азат иттеләр. Әмма бу никадәр матур сайраган вә кәефле җырлаган саен, моны тагы катырак каравылладылар.

## Кеше һәм Арыслан

Көчле булмактан гакыллы булмак кат-кат артыктыр.

Моңар ышанмаган кеше, менә бу хикәячекне укыгач, гакылның артыклыгына канәгать хасил итәр.

Бер Аучы үзенең авын агачлар арасына җәеп, нинди булса да табыш көтеп торганда, яңлыш үзе Арыслан тырнагына эләкте.

Арыслан, каһәрләнеп: «Бет, и бәдбәхет мәхлук! Менә минем тырнагымда тикшереп карыйк әле, синең тазалыгың вә көчлелегең кайда икән? Сез, Адәм балалары, үзеңезне бөтен дүрт аяклы хайваннарга, хәтта арысланнарга да падишаһ дип йөрисез, имеш. Менә хәзер сезнең бу дәгъвагызның тиешле-тиешсезлеген карарга форсат табылды»,– диде.

Бичара Аучы Арыслан тырнагыннан зәгыйфь кенә тавыш илә: «Без сездән көч вә куәт ягыннан өстенлекне дәгъва кыйлмыйбыз, бәлки гакыл илә сездән югарылыкны дәгъва итәбез; менә мактанырга батырчылык итәмен ки, мин хәзер бу җирдә үземнең гакылым илә шундый эш эшләрмен ки, сез ул эшне көчегез берлән эшли алмассыз», – дигәч, Арыслан: «Сөйләмә! Мин сезнең мактанган әкиятләреңезне тыңлап ардым инде...»

Аучы: «Юк, падишаһым, әкият түгел, мин хәзер осталыгымны күз алдыңда күрсәтәм. Әгәр сүзем ялган булса, минем качып котылыр хәлем юк, соңыннан да ашарга өлгерерсең. Менә минем агач арасында җәйгән үрмәкүч ояларым бар, шуның астыннан мин гакылым берлән чыга алам, һәм син дә көчең берлән чыгып кара. Әнә үзең дә күрәсең: ул – үрмәкүч оясы, таш стена түгел, әнә аз гына җилгә дә селкенеп торадыр».

Арыслан: «Җә, элек үзең чыгып кара!» – дигәч, Аучы мәһарәт белән шома гына ау астыннан чыкты.

Аның артыннан Арыслан да, җәядән атылган ук шикелле сикереп, ау астына барып керде.

Әмма бәхетсез Арысланның ау астына гомердә дә кергәне юк иде. Мискин хайван ауга чорналып калды.

Гакыл көчне җиңде.

Көчле Арыслан һәлак булды.

## Күке илә Күгәрчен

Күке, ботакка кунып, бик хәсрәтләнеп вә моңаеп кына утыра иде.

Моның болай күңелсезләнүен икенче ботакта утырган Күгәрчен күргәч: «И Күке дуст! Ни эшләп болай мискинләнеп, кайгырып утырасың? Әллә якты җәй көннәре үтеп, караңгы көз көннәре якынлаганга күңелең бозылдымы?» – дип гөрләде.

Күке, моңар каршы сүз башлап: «Мин бичарага, мин бәхетсезгә ничек кайгырмый түзәргә кирәк! Менә, Күгәрченем, үзең уйлап кара әле: мин яз башыннан бирле балалар үстердем, ана булдым. Инде балаларым үстеләр, һәркайсы бер якка очып таралып та беттеләр. Әмма: «Анамыз ни хәлдә тора икән?» – дип килеп тә карамыйлар. Һич мине ана дип белмиләр... Кайвакытларда Үрдәк балаларының аналары тирәсендә һич аерылмый әйләнгәннәрен һәм Тавык чебиләренең аналары бер сүз әйтеп чакыргач та яңгыр шикелле сибелеп килгәннәрен күргәндә, йөрәкләрем янып китә; көнләшә башлыйм. Ахырда түзә алмыйча егълыйм», – дип зарланды.

Күгәрчен, Күкенең зарларын тәмам тыңлагач: «И Күке дустым! Мин сине чын күңелемнән кызганам. Әгәр синең хәлең миңа төшсә, мин әллә кайчан үлгән булыр идем. Әмма, Күкеҗан, мин җәй буе сине сынадым, без икәү һаман диярлек бергә тордык. Ләкин мин нидәндер синең бер дә эш белән шөгыльләнгәнеңне күрмәдем, тик һаман синең агачтан агачка очып, пырхылдап йөргәнең генә күренде. Шулай булгач, син кай арада балаларыңа оя ясап өлгердең?» – диде.

Күке җавабында: «Юк, мин үзем һичбер оя-фәлән ясамыйм, мин йомыркамны һәрвакыт башкалар оясына гына саламын»,– дигәч, агач башыннан бер Карга: «Син алай кеше оясында үстергәч, ул балаларыңнан нигә изгелек көтәсең? Һәм нигә хәер өмид итәсең?» – диде.

*

Аталар! Аналар! Бу – сезгә сабак. Мин моны балаларны гаепләр өчен язмадым.

Балаларыңыз сездән аерылып, кеше кулында үссәләр, кечкенә вакытта сездән хөрмәт күреп, сезнең тарафтан сөелми үссәләр, карт көнегездә сезгә әйләнеп тә карамаслар.

Болай булганда, сез балаларыңызны шелтәләмичә, үз-үзеңезне шелтәләңез.

## Ике Күгәрчен

Ике Күгәрчен ике туган шикелле гомер итәләр иде. Боларның берсе икенчесеннән башка ашамыйлар да, эчмиләр дә иде.

Берсен бер җирдә күрсәң, икенчесе, билгеле, шунда. Боларның куанычы да, кайгысы да уртак иде.

Бу рәвешчә торганлык берлә бу ике дуст гомерләренең ничек үткәнен дә күрмичә калалар иде.

Бу ике дустка кайвакытларда кайгыга, хәсрәткә дучар булырга тугъры килсә дә, боларга һичбер вакытта ялгызлык, күңелсезлек кеби нәрсәләр тырнак батыра алмый иде.

Шулай рәхәт-рәхәт кенә вакыт кичереп торганда, берзаман берсенең күңеленә сәфәр кайгысы, сәяхәт дәрте төште.

Бу Күгәрченнең, җир йомыркасын әйләнеп, төрле гаҗаиб-гараибне күреп, ялганны дөресттән аерырлык һәм булган илә булмаган әкиятләрне фәрекъ итәрлек гыйлем табып кайтасы килде.

Моның бу дәрткә төшкәнен икенчесе белгәч, яшь аралаш күзләрен дустына тегәләп, бу сүзләрне әйтә иде: «И мәрхәмәтсез дуст! Син кая бармакчы буласың? Бу дөнья буенча өстерәлеп йөрүдә ни файда бар? Син, мине кызганмасаң да, үзеңне кызган. Сәфәрдә очраячак ерткучы кошларны, карчыгаларны, куркынычлы, бозлы яңгырларны исеңнән чыгарма. Һич булмаса, яз башы җиткәнен көтәргә кирәк. Үзең беләсең, хәзер вакытсыз, азык та аз, һавалар да бозык. Язга чыккач, мин дә сине туктатмам, теләгән җиреңә барырсың. Чү! Менә Козгын да кычкырды. Бары да хәерсезлеккә ишарәт. Зинһар, китмәсәнә, җаным. Әле бергә торырбыз – бик күңелле бит. Кая бармакчы буласың син? Бер дә гакылым җитми. Син әллә миннән туйдыңмы? Аерылмакчы буласыңмы? Син китсәң, мин бөтенләй ятим каламын; яңгырлар, җилләр миңа гына тиячәк; син киткәч тә, төшемә әллә нинди куркынычлы нәрсәләр керә башлар; күңелем сиңа киләчәк бәлаләрне уйлап куркыр. Баш өстемдә аз гына күк күкрәгән тавыш ишетсәм: «Ах! Минем дустым кайда икән? Сау микән? Тамагы тук микән? Һавасызлыктан күләгәләнә торган җире бар микән?» – сөальләре илә тәшвишләнеп хәсрәтләнермен».

Бу сүзләр, бу ялынулар безнең сәйяхнең йөрәгенә үтте. Дусты кызганыч, ләкин сәфәр дәрте берлә башы әйләнгән, гакылы киткән. Нишләргә дә белмәгәч, дустының күңелен бу рәвешчә җуатырга тотынды: «И сөекле дустым! Мин синнән тик өч-дүрт кенә көнгә аерыламын. Үзең дә беләсең: мин аягым берлә сәфәр итмим – очам. Мин бар көчем илә очып, аз вакытта күп җирләрне, күп нәрсәләр күреп, янә синең канат астыңа кайтып керермен. Ул вакытта безгә сөйләшергә сүз күбәер, мин һәр сәгатьтә бертөрле җирне искә төшереп, кай җирдә нинди гаҗаибләр күргәнемне һәм кайда нинди гадәтләр, нинди кыйланышлар барлыгын сиңа хикәят итәрмен. Син дә бу кызыклы сәяхәт хәлләрен ихлас берлә тыңларсың, һәр җирләр, һәр таулар, төрле сулар – һәммәсе күз алдында томанлы картинка кеби күренер, һәм минем берлә бергә йөреп, күзең күргәннән ким булмассың».

Нишләмәк кирәк? Дустлар үбештеләр дә аерылыштылар.

Безнең юлчы канатын селкеп оча. Ул сәфәрдә инде.

Шулай очып барганда, менә берзаман моның каршысына җилле яңгыр килә, күк күкри, яшен ялтырый.

Күгәрчен түбән караса, анда тик күгәреп яткан диңгез шикелле сахра гына күренә. Кайда ышыкланырга кирәк?

Күгәрченнең бәхетенә каршы, күзенә бер корган имән күренде. Мөсафирымыз тизрәк шунда барып ышыкланган булды. Әмма җилдән дә котыла алмады, яңгырдан да саклана алмады.

Бичара тәмам юешләнде, чыланды. Гомердә болай яңгыр вә җил астында калганы юк иде, бу юлы калды һәм бик каты туңды.

Күп вакытлар үткәч, болытлар таралган кеби булды, бер яктан кояш та ялтырап чыкты.

Мөсафирның күңелендәге дәрте һаман ераграк барырга куша иде. Ул азрак тагын да селкенде дә юлга төште.

Инде күп заманнар үтте; юлчымызның карыны да ачыкты. Ул очып барган вакытында «азык күренмәсме икән?» фикере белән сахраларны күзеннән кичерә бара иде.

Бервакыт моның күзенә бер аулак кына җиргә сибелгән ярмалар күренде. Хәзер азык табылды. Ачыккан сәйях, тиз генә төшеп, ярманы чүпләргә башлады.

Чүпләп туйгач, очып китим дисә, гөнаһ шомлыгы, ул ау эченә сибелгән ярма икән! Мискин кош ауга чорналып калды. Һәр яктан бәла!

Моның әҗәле җитмәгәнгә каршы, ау иске икән: күп тартыла торгач, ауны өзде дә котылды. Котылса да, бер аягы суелды һәм канады – эштән чыга язды.

Ни булса да, алды-артына карамый, гакылсыз, һушсыз хәлдә күтәрелеп китте. Күз алды караңгыланган; үзе дә кая барганын белми, һаман оча иде.

Сәфәрдә куркынычлар бетәме соң? Кисәктән моның каршысына залим Карчыга килеп чыкты. Күгәрчен, мискин, Карчыганы күргәч, бөтенләй шашып, бар көче, куәте илә канатын селкеп кача башлады. Качса да, күп йөргәнлектән, хәле беткән иде.

Озакламый, моның күзе янында Карчыганың тырнаклары күренеп китеп, аның канатының җилләре

дә исә башлады.

Шул вакытта, хикмәти Хода, бер Каракош пәйда булып, канаты белән Карчыганы бик каты сукты да, ерткучы икенче ерткучыга азык булды.

Безнең Күгәрчен, үлемнән котылгач, тиз генә бер авыл янындагы читән арасына кереп посты.

Әмма моның берлә генә сәйях тынычландымы? Күгәрченнең монда качканын бер Бала күреп, моның башына таш атып, башын җәрәхәтләде.

Бәхетсез кош, бу җирдә дә хәер күрмәгәч, акрын гына, тагы әллә нинди бәлаләр күрмим дип, ватылган башы, бозылган канаты, суелган аягы илә өенә таба юнәлде.

Инде сәфәр дәрте сүнде. Ул инде сәяхәт итү фикерләреннән тәмам тәүбәи нәсух итте.

Әле безнең Күгәрчен бөтенләй үк бәхетсез түгел икән: оясына кайтса, дусты, каршы чыгып, көтеп тора икән. Сәйяхемез дәрхаль дустының канаты астына барып сыенды, янә үбештеләр.

Юлдагы мәшәкатьләр бер-бер сөйләнде. Болар тагы борынгыча тора башлаганлыктан, ул михнәтләр тәмам онытылды.

*

И сез, бөтен дөньяны сәяхәт итәргә теләүчеләр!

Сез дәрт берлә янасыз. Шуның өчен бу тәмсилне укып чыксаңыз, зарар тапмассыз.

Сез кайда барсаңыз да, дустларыңыз торган җирдән матур, күңелле урын тапмассыз.

## Аккош, Чуртан һәм Кыскыч

Бервакыт Аккош, Чуртан, Кыскыч – өчесе бер йөккә җигелеп, аны алга алып бармакчы булдылар.

Болар өчесе дә тиреләреннән чыгарлык булып, көчәнеп тарталар, ләкин йөк һаман да кузгалмый. Бу йөк аларга, бәлки, авыр да булмас иде, ләкин Аккош һавага тартыла, Кыскыч артка өстери, Чуртан суга таба тарта.

Боларның кайсы гаепле, кайсы хаклы – анысында безнең эшемез юк, ләкин йөк әле һаман да шул урында.

## Бүре хакында

Бүре падишаһ Арысланнан Сарыкларга башлык булырга риҗа итте. Һәм Төлке дустының тырышлыгы аркасында Бүренең гарзы хале ана Арыслан (сәйиидәтес-солтан) аркылы Арысланга җиткән иде.

Арыслан, әлбәттә, Бүренең кан эчкүче залимлеген күп ишеткән булырга кирәк: тиз генә Бүрегә бу вазифаны бирмәскә теләп, тәфтиш итмәк өчен, Юлбарыс, Кәркедән, Каплан, Фил, Кабан дуңгызы кебиләрне каршына чакырып: «Сез Бүрене ничек дип беләсез?» – дип сорашты.

Бу хайваннар һичберсе үзләренә Бүренең золымы тимәгәнлегене сөйләгәч, Арыслан Бүрене сарык абзарына башлык итеп куйды.

Әмма Сарыклар ни әйтәләр? – моны сораган кеше дә юк. Дөрестен әйткәндә, бу тугърыда иң элек Сарыкларның фикерен сорашырга кирәк иде.

## Арыслан илә Тычкан

Тычкан, Арыслан янына килеп, тәгъзим берлә генә шул якын-тирәдә бер агач төбенә ояларга рөхсәт сорады вә диде: «И падишаһ! Син гәрчә урманда иң көчле вә гайрәтле бер зат булсаң да, гәрчә синең бер нәгърәң бөтен җанварларны тетрәтергә җитсә дә, киләчәкне белеп булмый бит. Кем белә? Бәлки, мин шушы кадәр зәгыйфь вә көчсез бер мәхлук булсам да, бервакыт сезгә бер файда тиерермен».

Арыслан, Тычканның бу сүзләренә гаять тә ачуланып: «Синме?! И кызганыч җанвар! Кит, югал хәзер күземнән! Тере вакытта тизрәк башыңны алып кач. Югыйсә мин сине дөньяга килмәгән шикелле итәрмен. Миңа, Арысланга, файдам тияр дигән була бит! Ах, әдәпсез нәрсә!» – дип, бик каты гайрәтләнде.

Тычкан, мискин, бар хәле белән, җан коткарыр өчен качып, күздән дә югалды.

Ләкин Арысланның бу тәкәбберлеге буш кына калмады.

Бервакыт ул, үзенә азык эзләргә чыкканда, яңлыш Аучының үләннәр арасына корган авына эләкте. Монда инде нәгърәләр, үкерүләр файда бирми.

Мискин Арыслан никадәр тартылса да, җолкынса да, Аучының табышы гына булып калды: аны шәһәргә алып кайтып, кешеләргә күрсәтер өчен, тимер читлеккә ябып куйдылар.

Арыслан читлек эчендә теге Тычканны исенә төшерде. Әгәр Тычканга шәфкать иткән булса, ул, ауның җепләрен кимереп өзеп, Арысланны бәладән коткара алачак иде.

*

Коега төкермә, бервакыт су эчәргә кирәк булыр, диләр.

## Җумарт дуст

Без үземезгә кирәк булуы мөмкин булмаган нәрсәне кешегә бик җумартланып бирәмез. Менә шул сүзне куәтләр өчен, монда бер мисал да китерәмен.

Бер Төлке, Тавык ояларын актарып, туйганчы ризыкланып, ашаганнан артканын запаска калдырып, аны бер җиргә күмеп, үзе бер печән кибәне төбенә килеп яткан иде.

Берзаман Төлке яткан җиреннән генә ерактан үзенә таба бер карамчык килгәнен күрә; бу карамчык, һаман якынлаша-якынлаша, Төлкенең янынук килеп җитте. Төлке, караса, күрә ки – бу үзенең Бүре дусты икән.

Бүре, килеп җиткәч үк, дусты Төлкегә, бүген иртәдән бирле искәнеп йөрсә дә, ашарлык бернәрсә дә таба алмаганлыгын, көтүчеләрнең дә йокламаганлыкларын, этләрнең дә усаллыкларын бер-бер бәян итеп, Төлкедән бераз ашарга өмид итте.

Төлке нигә кызганмасын – үзенең дусты ич! Бүре үзенең ихтыяҗын сөйләп тәмам иткәч, Төлке, Бүрегә хитабән: «И газиз дустым! Шулай ук ачыктыңмыни? Алай булса, менә шушы бер кибән печәнне рәхим итеп ашасаңыз ла! Сез ачлыктан хәлас булсаңыз, мин бик шат булыр идем»,– диде.

Кяшки бу хәйләкәр теге яшереп куйган запас хакында бер генә сүз әйтсә, Бүре өчен нинди зур бәхет булыр иде.

*

Бүренең печән ашамыйча, печән ашаганны гына ашаганлыгы билгеледер.

## Бәти

Бер Кәҗә бәтие, балалыгы вә яшьлеге илә Бүре тиресен киеп, бакчага сәер итәргә китте.

Бу, шул кыяфәте илә бакчага кереп, яшел чирәмнәрдән татымакчы булып, авызын түбән таба сузган гына иде, шул вакыт моны ерактан күргән этләр, Бүре дип белеп, барчасы бердән моның өстенә атылып, кайсы муеныннан, кайсы биленнән вә кайсы ботыннан тешләп, бичараны аяктан да ектылар.

Мискин Бәтинең әҗәле җитмәгәненә каршы, бу хәлне көтүчеләр күреп, этләрне көч илә генә аерып алдылар.

Этләр тешенә эләкмәк уен түгел; бичара бәти үлемнән котылгач, көчкә-көчкә генә өстерәлеп, сарыклар абзарына барып керә алды һәм гомер буена ыңгырашып, күңелсезләнеп йөрүчән вә ашаганы да сеңмиторган зәгыйфь бер Сарык булып калды.

Әгәр дә Бәтинең башында гакылы булса, Бүре тиресен кию кайда, бәлки, Бүрегә охшауны уйларга да куркыр иде.

*

Явызларга тыштан гына булса да охшарга ярамый.

## Көзге һәм Маймыл

Маймыл, көзгедән үзенең сурәтен күргәч, әкрен генә янындагы Аюга аягы берлән төртеп: «Кара әле, иптәш! Көзгедә нинди кыяфәтсез, нинди ямьсез бер хайван күренә. Кара әле, аяклары нинди кәкре, кара әле, йөзе нинди килешсез! Әгәр мин шул көзгедә күренгән нәрсәгә аз гына охшасам да, хәсрәтемнән буылып үләр идем.

Хәер, әйтергә мөмкин, минем иптәш вә дустларым арасында да бу көзгедә күренгән хайван төсле ямьсезләр биш-алтылап бар, хәтта мин аларны бармак берлән санап күрсәтә алам»,– диде.

Аю моңар җавапта: «И Маймыл иптәш! Син иптәш вә дустларыңны санап мәшәкатьләнгәнче, бер мәртәбә үзеңә генә карасаң булмасмы?» – диде.

## Сабан сөрүче

Бер Чебен, зур бер Үгезнең мөгезенә кунып, кырдан кайтып килгәндә, аңар үзенең таныш чебеннәре очрап: «Иптәш! Каян кайтасың болай?» – дип сорагач, Чебен тәкәбберләнеп кенә: «Мин сабан сөреп кайтып киләм»,– диде.

## Ишәк илә Сандугач

Ишәк Сандугачны күрде дә, аның янына килеп: «Тыңла әле, дустым! Миңа сине, ул сайрарга бик маһир, дип мактадылар. Менә мин үз колагым илә синең тавышыңны ишетмәкче вә яхшы-начарлыгыны үзем хөкем итмәкче булдым»,– диде.

Сандугач, дәрхаль үзенең һөнәрен күрсәтергә башлап, әллә тагы мең төрле көйләргә борып сайрарга кереште.

Ул бер чут-чут итеп куеп, бер сызгыра, бер назикәнә генә, тавышын әкренләтеп, бер бөтен урманга вак кына ядрә сибелгән кеби яңгыратып җибәреп, ничек тә булса матуррак сайрарга тырыша иде.

Сайрауның тәэсиреннән искән җилләр һәм сайрап торган вак-төяк кошлар туктадылар. Көтүләр бер урынга яттылар. Көтүче дә, сулышын көчкә генә алып, Сандугач тавышын эреп, изелеп тыңлый иде.

Сандугач сайраудан туктады.

Шул вакыт безнең Ишәк, маңлаен җиргә куеп: «Әйе, Сандугач, син һәйбәт сайрыйсың, сине бер дә күңелсезләнми генә тыңлап була; ләкин шунысы кызганыч: син безнең күршедәге Әтәч белән таныш түгел икәнсең. Әгәр син аның белән танышып, аннан бераз өйрәнсәң, тагы да матур сайрар идең»,– диде.

*

Ярабби, син безне дә мондый хакимнәрдән сакла!

## Мөхәррир һәм Карак

Мәхшәрнең куркынычлы мәйданына ике кешене хөкемгә китергәннәр иде. Берсе – олугъ җулларны кисүче, күп кешеләрнең каннарын түгеп, малларын алучы; икенчесе – бик данлыклы, бөтен дөньяга исем-чабы таралган Мөхәррир – китап язучы. Бу Мөхәррирнең сүзләре килешле һәм симез муллаларга шампанский эчәргә фәтвалый. Шәригатьне киң күрсәткән, китапларның төбенә төшкән. Аракыны да моның китабында җимеш суы гына дигән, хатын-кызның качуыннан, дәһа тугърысы, инсафыннан көлгән.

Нә исә ахырда коточкыч судьялар алдында хөкем булды. Бу ике гаепләне җәһәннәмнең аулак почмагына гына илтеп, калын зынҗырлар илә асылган ике зур казаннарга икесен дә салдылар. Зобанилар үз куллары илә казаннар астына ут яктылар. Утның эсселегеннән җәһәннәмнең ташлары сикерә иде.

Бу рәвешчә ничә гомерләр, ничә йөз еллар янгач, Каракның астындагы ут сүнде; Мөхәррир астындагы ут минуттан минутка кыза һәм эсселәнә бара. Мөхәрриремез күңеленнән утның сүнүен көтә, котылуны өмид итә. Иптәше котылып, бу ялгыз гына калганга бик күңелсез булдымы – Мөхәррир әфәнде, Аллага сукранып, ачы газап эчендә бу сүзләрне әйтә иде: «И Ходаем, синдә һич рәхим юк икән! Минем ни гөнаһым бар? Гомерем буе китап яздым, бөтен җир йөзенә исемем таралды. Гаебем булса, тик азрак иркенрәк язганмын. Бу ни бәла бу? Мин Карактан да начар булырмын дип уйламаган идем...»

Мөхәррир шулай мыгырдап торганда, кисәктән җәһәннәм төтеннәре арасыннан күзләре яшендәй ялтыраган, кулында гөрзи, чәч араларында җыланнар ыжылдап тора, кап-кара йөзле, арыслан тырнаклы бер зобани чыгып, Мөхәррир өстенә утлар чәчеп: «И бәдбәхет! Синме дингә тарайдың? Синме нәфескә охшаган эшне шәригать куша дидең? Һәм син Карак илә үзеңне бер күрмәкче буласыңмы? Ул Каракның зарары үзе тере вакытта гына булды, әмма син үлдең, сөякләрең череп туфрак булдың, синең бозыклыкларың, синең усаллыкларың дөнья гомере беткәнче барды; кайчан кояш чыкса, син калдырган усаллык, бозыклыклар да дөньяга чыга иде. Синең җимеш суларың илә исереп сугышып, үлтерешеп җөрүчеләр, синең хатын-кыз качмасын дигәнгә иярүчеләр зина, фәхешлекләр илә башлары әйләнеп, дөнья-ахирәт бәхетләреннән коры калганнар. Шул үлтерешүчеләрнең бер тамчы канына, җылаучыларның бер къәтрә күз яшенә – һәммәсенә син гаеплесең; синме Аллаһы Тәгаләгә каршы Нәмруд кеби коралланасың!» – дип орышып, шелтәләп, Мөхәррирнең өстенә казан капкачын шалт иттереп япты да китте.

## Гауваслар

Иске заманның бер Падишаһы үзенең кәкре фикере илә гыйлемнең файдасыннан күбрәк зарары барлыгын тапты. Ул гыйлем кешенең күкрәгеннерет черетә, кулларын нечкәртә, имеш. Әгәр дә үз мәмләкәтендә булган барча галимнәрне кудырса, үзен-үзе бик зур изгелек кыйлучылардан санамакчы булды. Падишаһ үзе дә, бу фикеренең дөрестлегендә шөбһәләнеп, шул фикер тугърысында халыкларның ни әйткәнен белер өчен, галимнәрнеме, белмим, җаһилләрнеме,– берничә йөз кеше җыеп, бер мәҗлес ясады.

Халык гыйлем тугърысында төрлесе төрле сүз сөйли иде. Кайсы әйтә: «Аллаһы Тәгалә безгә, гыйлем эстәсеннәр дип, гакыл биргән. Безнең атамыз Адәм галәйһиссәлам гакылы илә фәрештәләрдән өстен булган, һәм адәмнәр гыйлем өчен бирелгән гакыллары илә яратылмышларның иң хөрмәтлесе булганнар. Адәмнәрдән кат-кат көчле хайваннар, гакыллары булмаган сәбәпле, адәмнәргә та кыямәт кол булганнар»,– ди.

Кайсылары әйтә: «Халык укыган саен бозыла, динне җиңелгә саный, муллаларга да тәгъзимдә косурлык итә, хаҗилар алып кайткан Мәрьям ана чәчен хөрмә агачының мунчаласы ди һәм, шул хәерсез гыйлем булмаса, Әндәлес дәүләтләре, холәфаи Габбасия мәмләкәтләре харап булмас иде»,– ди.

Җыелган кешеләрнең очсыз-койрыксыз сүзләре һәм гыйлем вә җәһел мәсьәләсе хосусында язылган тау-тау кәгазьләре Падишаһның башын гына чуалталар иде. Падишаһ, бу мөшкил мәсьәлә хакында болай гына сөйләүләргә канәгать итмичә, борынгыдан да зуррак мәҗлес ясады. Бу мәҗлескә җыелган халык, әлбәттә, тик торырга җыелмаган. Тагы зур тавыш, тагы зур кычкырышлар күтәрелә башлады.

Шул арада халык эченнән бер Карт чыкты. Бу Картның чәһрәсеннән, йөзеннән сакалны тегермәндә генә агартмаганлыгы аңлашыла иде. Падишаһ, бу Картка илтифат итеп, Карттан бу мөшкил мәсьәләне чишүен үтенде.

Карт, баш өсте дип, мәсьәләне чишмәкче булып, шуңа тәгаллекъләрәк бер хикәяткә керешеп, диер ки: «Һиндстанда бөтен гомерен ярлылыкта, хәсрәттә кичергән бер Балыкчы карт бар иде. Бу карт үлгәч, артында өч баласы калды. Бу балалар бу көнгә кадәр тарлыкта, мохтаҗлыкта вакыт үткәргәннәрен хисаплап һәм аталарының һөнәрен яратмыйча, диңгездән тагы да зур байлыклар алмакчы булдылар. Инде диңгездән балык түгел, энҗе алырга уйладылар.

Болар уйлары буенча, гауваслык (диңгезгә чуммак) гыйлемене бик яхшы үгрәнеп, һәр өчесе диңгезгә чума башладылар. Шулай булса да, бу өч агай-эненең бәхетләре төрлечә иде. Бер борадәр калган икесеннән ничә градус ялкау, аның диңгезгә кереп аягын да җүешләтәсе килми иде. Шуның өчен һәрдаим яр читләренә дулкын илә чыккан энҗеләрне генә җыядыр һәм шул кәсебе илә көчкә генә тамак туйдырадыр иде.

Икенче борадәр тырышып, көчен-куәтен кызганмыйча һәм диңгезнең төпсез җирләренә бармыйча, кадәри хәль генә чумып, энҗеләрне җыеп, үзенең байлыгын сәгать саен арттырадыр иде.

Өченчесе күңелендә «дөрест, диңгезнең читләренә чумсаң да, азлап-азлап кына энҗе алып була, әмма болай азлап алган мал илә тиз баеп булмас» уен яшереп, диңгезнең иң уртасына чумарга кистергән иде. Моның уенча, тирән җирдә хисапсыз хәзинәләр, байлык таулары бар, һәм анда бер энҗе генә булмаенча, гәүһәр, якут, мәрҗән һәм зәбәрҗәтләр дә тулган. Бу борадәр, үзенең гыйлеменә ышанып һәм чуммак фикеренә әсир булып, диңгезнең кайда каралып торган төпсез җире булса, шуны эзләп, ахырда табып, бар көче илә чумып китте. Бәхетсез Җегет диңгезнең төбенә җитә алмады, диңгез төбендәге байлыкларның һәммәсеннән кыйбатлырак җанынннан аерылды. Менә, Падишаһым, гыйлемдә файдалар күп булса да, бәгъзеләр гыйлемне урынсыз истигъмаль итеп, гыйлемнән зарар да табалар», –дип, карт хәтме кәлям әйләде.

## Мөһәндис

Бер яшь Җегет падишаһлар сарае кеби зур бер өй сатып алды. Бу өйнең һәр җире Җегетнең күңеленә бик ошаса да, өйнең суга ерак булуы Җегетнең кәефен бозадыр иде. Җегет бу кәефсезлеккә дә бер дәва тапты. Ул да күңеленнән генә: «Бу өй инде минем үземнеке булды, һәм үз милкемдә үземнең ни эшләсәм дә иркем бар. Мин хәзер бер хәйлә, бер осталык илә, өемне бер дә бозмыйча, су янына алып барам», – дип уйлавы иде.

Бу Җегет һәндәсә гыйлемендә бик маһир булырга кирәк: дәрхаль өйне казып, астына кертеп, теләгән җиренә алып барырга бик зур бер чана ясатты. Өйнең астын казырга хисапсыз хезмәтчеләр дә яллады. Әгәр дә өй казылып, чанага салынып, Җегеткә фәйтунга утырып барган шикелле су янына барырга яраса, Җегет мәшәкатьләрне, акчаны бер дә кызганмаска булды. Хезмәтчеләр, эшчеләр ничә көн, ничә төн казыдылар; ахиреләмер өйне аудардылар, һәм күп кешеләр астында калып үлделәр.

*

Дөньяда бәгъзе кешеләр бар: аларның уе бу мөһәндис фикереннән дә куркынычлырак.

## Хикмәтле хикәя

Заманы әүвәлдә бер Сукыр тычкан бар иде. Ул гомер буе җир астында торып, үзенең аяклары вә үткен тырнаклары илә җирне казудан башка аның эше юк иде. Бу Сукыр тычкан төрле агач вә үлән тамырлары илә ризыкланып гомер кичерә иде. Һәм шул тормышына үзе бик разый һәм канигъ иде. Бу Сукыр тычкан, сукыр булганлыктан, ашау илә йоклаудан башканы уйлап та карамый иде. Көннәрдә бер көн моның оясы өстендәге җир ничектер ишелеп төште. Сукыр тычкан үзенең өстендә искән йомшак кына, сөекле генә җил исүен сизеп һәм әллә нинди, гомердә беренче мәртәбә генә ишетелгән ят тавышлар ишетә башлады. Һәм дә үзенә бертөсле җылы вә җанга рәхәтле бернәрсә Сукыр тычканның җем-җем итеп торган кара тунын җылыта вә кыздыра башлады. Сукыр тычкан, рәхәтләнгәнлектән вә җылынганлыктан, тәмле-тәмле генә киерелергә, сузылырга тотынды. Шул ук вакытта агач башындин җомры гына, җомшак кына бер җанвар сикереп төшеп, Сукыр тычканга сөйкемле генә бер сурәттә ышкынды. Бу җанвар да шат күңелле, кәефле, уенчан Тиен иде. Ул, койрыгын маһиранә генә селкеп, арт аягына утырды да алгы тәпиләре илә агач башыннан алып төшкән чикләвекне авызына китереп, җомшак кына, җефәк сыман мыекларын селкетеп, хәтфә колакларын тибрәтеп, шытыр-шытыр иттереп ярырга тотынды. Тиен, бу рәвешчә чикләвекне тәмам иткәч, Сукыр тычканның янына ук килеп, аның хәленең кәефсезлегенә вә тормышының караңгылыгына гаҗәпләнеп, сораша башлады:

– И дустым! Син ни сәбәпле Кояш тузылган чәчле матур кыз кеби, күк тәрәзәсеннән башын чыгарып дөньяны ялтыраткан вә нурландырган вакытта, һаман җир астында караңгылыкта ятасың? Болай ятудин сахраларда, болыннарда сикереп уйнап йөрмәк ничә мәртәбә күңеллерәк вә кызыклырак булыр иде...

Сукыр тычкан җавапта:

– Мин аңламыйм, син нәрсә хакында сөйлисең? Ул Кояш дигәнең нәрсә? Һәм бер урында тыныч кына ятмыйча, мин ни өчен сикерим һәм ни өчен уйныйм?

Тиен тәкрар:

– Ничек һаман бер урында ятуга җаның түзә? Гаҗаиб төсле матур һаваларга, нурлы Кояшка, ботактан ботакка сикереп уйнаган матур кошчыкларга, саф, хуш исле чәчәкләргә һәм ул чәчәкләрне бер үбеп, бер китеп әйләнеп йөргән аллы-гөлле чуар күбәләкләргә карап ләззәтләнмичә ничек чыдыйсың?

Сукыр тычкан:

– И иптәш! Юк сүзләрне, ялган әкиятләрне сөйләмә! Бер җир бар, ул җирдә тәмле-тәмле тамырлар үсә, без ул җирне тырнакларымыз берлә казып, ашарлык тамырлар табамыз. Әмма синең бу җирдән башка җир бар дигәнең һәммәсе ялган вә хыял гына...

Сукыр тычканның бу сүзләре Тиеннең кәефен бозды. Шулай булса да, Тиен Сукыр тычканны Кояш барлыгына инандырудан өмид өзмәде. Нагаһ шул сәгатьтә Тиен, Сукыр тычканның җылыга рәхәтләнеп аркасын һаман Кояшка таба борганын күргәч, аңгар карап:

– Син, Кояш юк, дисең, әмма үзең Кояш арканы җылытканын сизеп торасың, – диде.

Сукыр тычкан:

– Дөрест, мин сизеп торам, әллә нинди җылы вә җан рәхәтле нәрсә мине җылыта, ләкин мин ул нәрсәнең нинди зат икәнен белмим, нәрсә соң ул? – диде.

Тиен:

– Нәрсә икәнен беләсең килсә, әнә шунда җугары күтәрелеп кара! – дип, Кояшны күрсәтте.

Сукыр тычкан янә дә:

– Мин белмим: ул карамак һәм күрмәк дигәнең нәрсә? – диде.

Шул вакытта Тиен аңлады ки, Сукыр тычкан сукыр икән. Бу хәл Тиенгә бик кызганыч тоелды: Тиен ничек тә булса бу бәлагә бер дәва табу һәвәсенә төште. Һәм үзенең барча гакылын, көчен сарыф итеп, ни хәйлә илә булса да булсын, Сукыр тычканнарны күзле итмәк уен корды. Тиен уйлады-уйлады да ахырда, Сукыр тычканга карап:

– Минем фикеремчә, сезнең сукырлыкыңыз җир астында ятып, мәңгелек караңгылык вә күңелсезлектән һәм җир казып тамыр эзләмәктән башка эш илә шөгыльләнмәгәнлегегездәндер. Әмма сез җир өстенә чыгып, яхшы һавалар тәнәффес итсәңез, тәмле саба җилләре истерсәңез һәм дә ул бөтен мәхлукат өчен яратылган Кояштан истифадә итсәңез, мин өмид итәмен: шаять, сезнең күзеңез ачылыр һәм сез якты дөньяны күрерсез, – диде.

Сукыр тычкан:

– Әйе! Җир асты илә чагыштырганда, монда яхшырак вә иркенрәк, ләкин монда тамырлар юк бит...

Тиен, моның сүзен бүлеп:

– Тыңла әле, җаным! Мин биек-биек агачлар башында гомер итәм, болай җугарыда булганым сәбәп-

ле миңа һәртөрле нәрсәләр аермачык күренеп тора һәм мин күбрәк беләмен. Мин беләмен: әгәр дә бу дөнья йортында бер-бер нәрсә вакыйгъ булса, ул нәрсә, һичшиксез, икенче бернәрсә өчен яки бернәрсә сәбәпле вакыйгъ буладыр. Менә, мәсәлән, синең ояң өстендин җир җимерелеп төште, шул заман мин уйладым ки: «Ә! Бу җимерелү, әлбәттә, ни-нәрсә өчен булса да кирәк икән»,– дип һәм, вакыйгъда да, бу җирнең җимерелүе Сукыр тычканнарга җир өстенә чыгып, Кояшта җылынып, яхшы һава иснәүләре өчендер. Бу галәм галәмел әсбабтыр, – дип, Тиен хәтме кәлям итте дә, баягы рәвештә койрыгын селекте дә агач башына менеп китте. Сукыр тычкан исә яткан җирендин Тиенне уйлаткан уйларын уйлап калды.

Кич булгач, Сукыр тычкан, барча иптәшләрен янына җыеп һәм Тиеннән аңлаган хикмәтләрне бер-бер нәкыль идәрәк, бу рәвешчә сүзгә кереште:

– Әйдәңез, иптәшләр, хәзер кич берлән, Кояш юк вакытта, җирне казып, үземезгә җитәрлек азык табыйк та, көндез дөньяга чыгып, тәмле һавалар исник һәм кайчан булса да безнең күзләремезне ачмак ихтималы булган Кояшта җылыныйк!..

Бу сүзгә яшь Сукыр тычканнарның барчасы күнде, мәгъкуль дә күрде. Әмма картлары:

– Безгә тәкъдир гомергә сукыр булырга язган, без кайда барсак та, күзле була алмамыз, – дип мыгырдый башладылар.

Шулай булса да, картлар азлап-азлап яшьләр юлына керсәләр дә, ышанып җитмәгәнлекләрен белдерү өчен, башларын чайкыйлар иде. Нә исә ахырларның ахырында Сукыр тычканнар, берсе артындин берсе җир өстенә чыгып, җәмигъ җанварларның мабиһил хәяты булган саф һаваларны иснәп, «Дөнья» исемле сарай өчен ясалмыш «Кояш» исемле электрик фонарендин файдаланып, сыгылып-сыгылып киерелергә, рәхәтләнергә тотындылар.

Шул арада Тиен дә килеп, дөньяда чит җирләр булганын, ул җирләрдә Сукыр тычканнар күзле булганын һәм ул җирдәге Сукыр тычканнар инде җир астында тормый башлаганнарын, алар Кояштан файдаланганнарын, Кояш та, Тиен вә башка хайваннарга биргән файдасы шикелле, Тычканнарга да саранлык итмәгәнен сөйли иде. Мондин соң яктыга чыгучы Сукыр тычканнарның һәм шул сәбәпле күзле булганнарның саны көндин-көн арта барды.

Бер матур гына иртә берлән мәшрикъ тарафындин алланып-кызылланып таң ата башлады. Тиен, моны күргәч тә, тиз генә агач башындин сикереп төште дә, Сукыр тычканнарның оясы авызына килеп:

– Килеңез барчаңыз монда, таң атты, таң атты, таң! Таң! – дип, бик каты кычкырды.

Бу тавышка барча Сукыр тычканнар уянып, алды-артлы тишектән чыгып, бер урынга җыела башладылар. Алар шулчаклы күп иде ки, бер башындин бер очы бер дә күренми иде. Болар һәммәсе башларын, гүя бер тән башлары кеби, берҗулы борып, таңны карадылар да җөмләсе куанычларындин бер агыздан:

– Без күрәбез! Без күрәбез! Менә таң! – дип кычкырдылар.

Бу тавыш бөтен җир йөзенә яңгырап, урманнар, таулар, мөхит диңгезләре, бу тавышны тәкрарлап, боларга җавап бирделәр. Һәм бу Сукыр тычканнарның күзләре ачылганга бөтен дөнья вә мафиһасы да шатланыштылар.

## Мөсафирлар һәм Этләр

Төнгә таба ике Мөсафир урамда тәмле-тәмле сөйләшеп баралар иде. Боларның бу тынычлыклары озакка бармады, кинәттән бер капка астыннан кечкенә генә курнос Көчек «тәф- тәф» иткәч тә, аның артыннан икенчесе, аннан өченчесе, дүртенче, бишенче, алтынчы... Күз ачып күз йомганчы иллеләп эт җыелып та калды. Мөсафирлар сискәнеп китеп, берсе кулына таш та алган иде. Икенчесе: «И иптәш, син этләрне өрүдән тыя алмассың, тик эт көтүен тагы да күбәйтерсең; әйдә, алга атлыйк; мин этләрнең холкын бик яхшы беләм», – дигәч, акрын гына илле-алтмыш адым киттеләр. Киткән саен, эт тавышлары азайды, бара-бара бөтенләй үк ишетелми башлады.

*

Көнчеләр синең тәрәккыеңне күрсәләр, әбәда өрерләр. Әмма син аларга карама, үз юлың берлән бар. Өрерләр дә туктарлар.

## Рәхәт йокы

Шул Балага карагыз: никадәр гүзәл йоклыйдыр. Аяк-куллары, күкрәк-билләре нинди килешле бер рәхәтлеккә китмеш. Күкрәгене җиңел-җиңел генә кабартып иңдергән йомшак сулышына, йөзендә дулкынланган шикелле күренгән көлемсерәвенә, һәнүз җиргә тимәгән йомшак кына мамык аякларына караган вакытыңызда, бер Фәрештә, һавада оча-оча аргач, бу бишеккә кереп ял иткәндә йокыга киткән дип уйларсыз.

Бәхетле Бала! Йокла! Һәрдаим тыныч булуыңны теләгән шәфкатьле Анаңның күзе алдында рәхәт-рәхәт йокла! Зур кеше дә йоклый, ләкин бичара йоклаганда дәхи тынычлык таба алмыйдыр. Агырлык берлә сулу алыр, төшендә дә төрле-төрле куркынычлы төшләр күрер, шул төшләр илә саташыр, куркынган саен куркыныр; мискин, мамык түшәккә ятса да, утлы күмер өстенә яткан төсле рәхәтсезләнәдер, башы, зиһене дөнья мәшәкатьләре, мәгыйшәт михнәтләре илә тулмыштыр.

Сәгадәтле Бала! Синең уянган вакытыңда, безнең шикелле, хатын, бала эшләре илә азапланасың юк; уяныр-уянмас синең эшең Әнкәңнең йөзенә карап көлмәктер. Аһ, бу көлү никадәр мәгънәле, никадәр йомшак көлүдер! Менә бу көлүең синең әнкәңнең барча арганлыкларыны бетереп оныттырадыр, синең көләч йөзеңне күргәч тә, әнкәңнең дә йөзе көләр, йөрәгендә сөйләп, язып бетермәслек дәрәҗәдә бер шатлык, бер күңеллелек уянадыр һәм сине хәзер кочагына алып, күкрәгенә бастырып, сиңа ничә төрле сүзләр илә сине сөйгәнлеген күрсәтә, аңлата башлыйдыр, һәм син дә, аңар җавап биргән төсле көлемсерәп, бер тавыш чыгарасың, шуннан соң туйганчы имәсең. Бу эшләрне эшләгәч, синең эшең теге бишектәге татлы-татлы йокыны көтү генә каладыр.

И нарасидә бала! Гөнаһсыз бала! Кулыңда форсат бар вакытта уйна да көл, зирә озакламый шундый бер хезмәтләр, мәшәкатьләр уртасында калырсың ки, бу көнге хуш вакытлар, күңелле заманнарыңның эзе дә калмас.

## Әлифба

Бер бала атасына:

– Әти, син үзең күзлек киеп китап укыйсың бит, миңа да бер күзлек алып бирсәнә, мин дә китап укыр идем, – диде.

Атасы:

– Ярар, угылым, мин сиңа күзлек алырмын, ләкин ул балалар күзлеге генә булыр, – дип, угылына бер әлифба китабы алып бирде.

## Баланың ата-анасын сөюе

Ун яшьлек бала – Шәмсетдин, үз авылларында бер бай кешегә барып, үзенә хезмәт сорады.

Бай кеше моны хезмәткә алырга риза булды вә әйтте: «Ярар, мин сине хезмәткә алырмын, көтү көтәрсең һәм, әгәр син яхшы хезмәт итсәң, аена алты тәңкә бәһа куярмын».

Шәмсетдин моңар каршы: «Ярар, мин кулымнан килгән хезмәтне кызганмам, ләкин син минем айлык бәһамне һәр атна саен бүлеп бирерсең. Чөнки өебездә әткәем, авырып ятканлыктан, эшли алмый, шул сәбәптән һәр атна саен аңар ризыкланырлык акча алып кайтып бирәсем килә», – диде.

Бай кешегә сабый бала Шәмсетдиннең атасына бу кадәр саф мәхәббәт кыйлуы бик ошады. Ул Шәмсетдиннең сүзенә «баш өсте» дип разый булуы өстенә аның айлык бәһасен дә арттырды.

## Яхшылыкка яхшылык

Күгәрчен, суда бер Кырмысканың батып һәлак булырга җиткәнен күргәч, дәрхаль авызына бер яфрак капты да суга ташлады.

Кырмыска бу яфрак өстенә менде дә, дулкын яфракны яр кырыена сөреп чыгарып, Кырмыска үлемнән котылды.

Бервакыт Аучы бу Күгәрченне ауларга хәзерләнгәнен күргәч, Кырмыска, теге яхшылыкны исенә төшереп, Аучының итек эченә керде.

Аучы Күгәрченне аулыйм дигән чакта гына, Кырмыска Аучының ботыннан бик каты тешләде. Авыртудан Аучы кулындагы авын төшереп җибәрде дә, Күгәрчен «прррх» итеп сәламәт очып китте.

## Ике Сабан

Ике Сабан, икесе бер үк тимердән, бер үк һөнәр йортында эшләнеп, базарга чыгарылганнар иде.

Боларның берсе Иген игүчегә сатылып, ул аны алгач ук эшкә кушты. Аның белән җир сөрә башлады. Шул рәвешчә бу Сабан һәр җәйне эшләп, аңар тик ятарга туры килми иде.

Икенче Сабан исә, бер Сәүдәгәр кулына эләгеп, аның кибетендә ауналып, эшсез ята иде.

Шулай озак заманнар үткәч, бу ике Сабан бер җирдә очраштылар.

Кибетчедәге Сабан, күп еллар эшсез ятканлыктан, тәмам тутыгып, саргаеп, караңгыланып беткән иде.

Иген игүчедәгесе исә күп эшләп ачылган һәм көзге шикелле ялтырап тора иде.

Тутыккан Сабан үзенең иптәшенең болай матурланганын күргәч, аннан: «Иптәш, син ни сәбәптән болай ялтырыйсың да, мин ни сәбәптән мондый тутыккан һәм караңгыланган?» – дип сөаль бирде.

Иптәше аңар: «Минем ялтыравым тырышуымнан килде. Әгәр гомерем буе кибет идәнендә кырын ятып торсам, мин дә синең төсле каралыр һәм ямьсезләнер идем», – дип җавап бирде.

## Һәркем эштә

Борһанетдин: «Мин бүген сабакка бармыйм; анда барганчы, кырларга чыгып уйнармын», – дип, басу капкасыннан җөгереп чыгып китте.

Борһанетдин кырда бер Атны күрде. Ул тиз генә Ат янына барды да: «Әйдә, Бахбай, икәү уйныйк, күңел ачыйк», – диде.

Ат: «Юк, җаным, минем уйнарга вакытым юк; минем сабан сөрәсем бар, Хуҗама хезмәт итеп ризык табасым бар, син үзең генә уйнарсың», – дип җавап бирде.

Бала, моннан киткәч, Умарта кортын күрде. Ул аның янына да барып: «Әй, Умарта корты! Әйдә икәү уйныйк, күңел ачыйк», – диде.

Умарта корты да җавабында: «Юк шул, минем эшем бар, җәй көннәре тиз үтеп китә. Минем көзгә кадәр төрле чәчәкләрдән ашыгып-ашыгып бал җыеп каласым бар, үзең генә уйна», – диде.

Борһанетдин, аптырагач, бер Кош янына барып, аның үзе берлә уйнавын үтенде.

Кош та, Борһанетдиннең үтенечен кабул итмичә: «Юк, бала, минем уйнарга вакытым юк; кечкенә балаларыма ашатыр өчен чебен-черкиләр аулыйсым бар», – диде.

Болай да булмагач, Борһанетдин тирән уйга чумды да тиз генә мәктәпкә таба җөгерде.

## Чылбырдагы Эт

Бер ишегалдында ояда чылбырга бәйләнгән карт Эт тора иде. Ул бала чагыннан ук, шул чылбырда йорт каравыллап, Хуҗасына бик күп хезмәт иткәнгә, Хуҗа да бу Этне бик сөя иде.

Хуҗа, кайвакыт моның янына килеп:

– Син мине яратасың, миңа тугъры хезмәт итәсең бит, иншалла, мин дә сине ташламам, – дип әйтеп, карт Этнең күңелен шатландырып китә иде.

Кайчакта, иректә йөри торган урам этләре бу ишегалдына кереп, бу Этне котырталар вә үчеклиләр иде.

– Менә син Хуҗаңа хезмәт иткән буласың; бервакыт күрерсең әле: син картаеп эштән чыксаң, Хуҗаң сине йортыннан куар да чыгарыр әле, ашарга да таба алмассың, – диләр иде.

Ләкин чылбырдагы Эт боларның сүзләрен, Хуҗаның эшен ташлап үзенә көн күрергә киңәш бирүләрен тыңламады.

Көннәрдән бер көн бу Эт Хуҗасының йортыннан ут чыкты. Өй янып бетте; инде утның ялкынлы төтеннәре Эт оясына да җитә башлады.

Бичара Эт бик каты курыкты. Кызганыч тавышлар илә өреп, егълап, ары-бире сугылып, чылбырны өзәргә азаплана башлады. Шулай булса да, аның эчендә: «Шаять, Хуҗам килер әле, мине коткарыр әле», – дигән ышаныч һаман бар иде.

Бара торгач, төтеннән сулыш алырга да читен була башлады. Мискин Эт чылбырны өзә алмый, аңа хәзер янып үләргә генә калган иде.

Шулай торганда, менә берзаман әллә кайдан төтен арасыннан Хуҗа йөгереп килеп чыкты. Аның чәчләре, киемнәре, йөзе тәмам көйгән, бөтен җиреннән төтен чыга иде. Үзе шундый куркынычта булса да, ул ничек тә булса, утны җырып кереп, Этнең чылбырын чиште.

Эт, мискин, котылуы белән Хуҗасына ташланды: өрә, җылый, Хуҗасының битен, кулын яларга башлады. Бичара Эт тик: «Рәхмәт сиңа! Мин синең мине карап торып һәлак итмәсеңә ышанган идем. Рәхмәт сиңа!» – дип әйтә генә алмый иде.

## Шигырьләр, поэмалар

**1905**


Мужик йокысы ......................

Хөррият хакында ......................

Дустларга бер сүз ......................

Иттифакъ хакында ......................

**1906**


Яз галәмәтләре ........................
Кечкенә генә бер көйле хикәя ................
Сорыкортларга ........................
Кемне сөяргә кирәк? .....................
Күз .............................
Государственная Думага ...................
Үз-үземә ...........................
Мактанышу ..........................


**1907**


Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр .........
Шагыйрьгә ..........................
Тартар кошы сайрый .....................
Теләнче ............................
Син булмасаң! ........................
Яз ...............................
Бишектәге бала .......................
Шиллердән ..........................
Мөтәшагыйрьгә .......................
Пар ат .............................
Ләззәт вә тәм нәрсәдә? ....................
«Дөньяда торыйммы?» – дип киңәшләшкән дустыма ...
Юаныч ............................
Шүрәле ............................
Театр .............................
«Алтынга каршы» ......................
Бер татар шагыйренең сүзләре ...............
Утырышу ...........................
Сөткә төшкән тычкан ....................
...га («И матур! иренмәче...») ................
Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре ........
Туган җиремә .........................
Безне урынсыз яманлыйлар ..................
Китмибез! ...........................
Матбага берлә уйнаган бер байга ...............
Мәхбүс .............................
Вәгазь .............................
Бер гәзитә идарәсе хәленнән .................
Ишек бавы ...........................
Байроннан ...........................
Гыйлавә .............................
Бәйрәм вә сабыйлык вакыты .................


**1908**


Бер шәехнең мөнәҗәте ....................
Тәәссер .............................
Урланган мәгънә .......................
Егет илә кыз ..........................
Шәйтанның муенына .....................
Чын вә Ялган ..........................
Шагыйрь ............................
Саташкан ............................
...га («Син дисең...») ......................
...гә («Очраган юлда...») ....................
Алдандым ............................
Кызык гыйшык .........................
Өмид .............................
Тормыш .............................
Җавап .............................
Тешләре ямьсез матурга ...................
Кулың .............................
Тотса мәскәүләр якаң! .....................
Ысулы кадимче ........................

Бер рәсемгә ..........................
Киңәш ............................
Шатлык вә хәсрәт .......................
Улмы? – Ул... ........................
Мәхәббәт ...........................
Төлке һәм йөзем җимеше ...................
Бәйрәм бүген ..........................
Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш .............
Ата илә бала .........................
Яхшы хәбәрләр .......................
Таз ..............................
Су анасы ...........................
Алтын әтәч ..........................
Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә .............
Милләтчеләр .........................
...гә («Шагыйрем!..») .....................
Булмаса ............................

**1909**

Күңел .............................
Васыятем ...........................
Бәгъзе зыялыларымыз ....................
Тәрәддөд вә шөбһә ......................
Исемдә ............................
Күрсәтә ............................
Ике юл ............................
Гаилә тынычлыгы ......................
Ике кояш ...........................
Эштән чыгарылган татар кызына ..............
Гашыйк ............................
Вакъты гаҗезем .......................
Китап .............................
Сөбханалла, сөбханалла ...................
Эш ..............................
Могъҗиза ..........................
Чыршы ............................
Туган авыл ..........................
Яңгыр илә Кояш .......................
Милли моңнар ........................
Яратырга ярый ........................
Киңәш ............................
Япон хикәясе .........................
Күңел йолдызы ........................
Сәрләүхәсез .........................
Теләү бетте ..........................
Ана догасы ..........................
Таян Аллага .........................
Бабай .............................
Кышка бер сүз ........................
Уянмас йокы .........................
Ай һәм Кояш .........................
Җир йокысы .........................
Кошларга ...........................
Сабыйга ...........................
Карлыгач ...........................
Кышкы кич ..........................
Кошчык ............................
Бәхетле бала .........................
Бишек җыруы ........................
Бала белән Күбәләк .....................
Мәктәптә ...........................
Эш беткәч, уйнарга ярый ..................
Арба, Чана, Ат .........................
Кярханәдә ..........................
Кәҗә белән Сарык хикәясе ..................

**1910**

Татар мөхәрриренә .......................
Нәсихәт ............................
Кәҗә тугърысында ......................
Җәйге таң хатирәсе .......................
Күңелле сәхифәләр ......................
Имтияз алган бала .......................
Безнең гаилә ..........................
Һәр ялтыраган алтын түгел ..................
Гали белән Кәҗә ........................
Фатыйма белән Сандугач ...................
Һәркемнең ашыйсы килә ...................
Ялкау маэмай .........................
Шаян песи ...........................
Кызыклы шәкерт .......................
Ак Бабай ............................
Ана илә бала ..........................
Бичара Куян ..........................
Кичә һәм бүген .........................
Ике иптәш арасында ......................
Катиле нәфескә ........................
Газаптан соң ..........................
Ачы тәҗрибә авазы ......................
Җәй көнендә ..........................
Кайчакта ............................
Гомер юлына керүчеләргә ..................
Өмидсезлек ...........................
Үкенеч .............................
Яшьләр .............................
Баскыч .............................
Актык тамчы яшь .......................
Бер мән .............................
Елның дүрт фасылы ......................
Төш ...............................
Өзелгән өмид ..........................
Өйләнү – түгел сөйләнү ...................
Тәләһһеф ............................

**1911**

Борын ..............................
...га («Шома тормыш...») ...................
Мияубикә ...........................
Эшкә өндәү ...........................
Иртә ..............................
Иһтида .............................
Читен хәл ............................
Кадер кич ............................
Сайфия .............................
Тәүбә вә истигъфар ......................
Көзге җилләр ..........................
Золым ..............................
Кечкенә музыкант .......................

**1912**

Сабитнең укырга өйрәнүе ...................
Валлаһи ............................
Хөрмәтле Хөсәен ядкяре ...................
Аң ................................
Үтенеч .............................
Бала оҗмахта .........................
Дошманнар ...........................
Кичке теләк ..........................
Ваксынмыйм ..........................
Сагыныр вакытлар .......................
Авылда авырып яту ......................

Әхлаксызлык ..........................
Буран .............................
Көтмәгәндә ...........................
Көлке түгел ...........................
Сабыйлар җыруы .......................
Монафикъка ..........................
Ни кирәк тагы? .........................
Мәхәббәт шәрхе ........................
Мөнтәкыйд ...........................
Интикадка мөтәгалликъ ....................
Казан вә Казан арты ......................
Яңгыр .............................
Татар яшьләре .........................
Өч хакыйкать .........................

**1913**

Шиһаб хәзрәт .........................
Йокы алдыннан ........................
Суык .............................
Хәстә хәле ...........................
Даһигә ............................
Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре ......
Кыйтга ............................
Тәфсирме? Тәрҗемәме? ....................
Шөһрәт ............................
Толстой сүзләре ........................
Мөхәрриргә .........................
Буш вакыт ...........................
Казан .............................

# Чәчмә әсәрләр

**Мәкаләләр**

Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? .......
Хиссияте миллия .......................
Җәмгыяте хәйрия .......................
Тәнкыйть – кирәкле шәйдер .................
Халык әдәбияты ........................
Юбилей мөнәсәбәте белән ..................
Уянгач беренче эшем .....................
**Истәлекләр, юлъязмалар**

Исемдә калганнар .......................
Мич башы кыйссасы .....................
Казанга кайтыш ........................
Мәкаләи махсуса .......................

**Мәсәлләр һәм балалар өчен хикәяләр**

Мөрит ............................
Аю мәҗлесе ..........................
Вагыйз ............................
Мирон ............................
Бәхет .............................
Җил илә Кояш ........................
Бер Гөл ............................
Мут илә Карлыгач ......................
Ишәк .............................
Ике бала ...........................
Оракул ............................
Көтүче ............................
Кәгазь Очырткыч .......................
Вәзир .............................
Казлар ............................

Мактанчык Куян .......................
Умарта корты вә Чебеннәр ..................
Черки изгелеге ........................
Җылан илә Бәрән ......................
Ташбака илә Куян .......................
Арыслан ауда .........................
Файдасыз җумартлык .....................
Бүре Этләр оясында ......................
Каз ..............................
Тиен .............................
Сарыклар вә Этләр ......................
Дуңгыз ............................
Аю ..............................
Арыслан илә Төлке ......................
Тимерче вә Эте ........................
Алмас ............................
Тычкан илә Күсе .......................
Ике Эт ............................
Сәүдәгәр ...........................
Әтәч илә Күке .........................
Мәче илә Сандугач ......................
Роща илә Ут ..........................
Бүре илә Тычкан ........................
Сыбызгы ...........................
Бытбылдык ..........................
Күке ..............................
Бала караучы ..........................
Егет сайлаучан Кыз ......................
Тавыклар һәм Каракош ....................
Мәрхәмәтле Төлке .......................
Картайган Арыслан ......................
Батыр Кырмыска ........................
Тәүбә иткән Төлке .......................
Фил ..............................
Чүлмәк илә Казан .......................
Нәүхәчеләр ..........................
Аш пешерүче ..........................
Чабак .............................
Кыр кәҗәләре .........................
Этләрнең дуст булышуы ....................
Бала Козгын ..........................
Үткен пәке ..........................
Тычканнар киңәше ......................
Әтәч илә Энҗе бөртеге ....................
Йөкче илә Юл кисүче .....................
Ике Күрше ..........................
Яшь Агач ...........................
Күл ..............................
Сукыр тычкан һәм Каракош ..................
Мәче баласы һәм Сыерчык ..................
Сандугач ...........................
Кеше һәм Арыслан .......................
Күке илә Күгәрчен .......................
Ике Күгәрчен ..........................
Аккош, Чуртан һәм Кыскыч ..................
Бүре хакында ..........................
Арыслан илә Тычкан ......................
Җумарт дуст ..........................
Бәти ..............................
Көзге һәм Маймыл .......................
Сабан сөрүче ..........................
Ишәк илә Сандугач ......................
Мөхәррир һәм Карак .....................
Гауваслар ..........................
Мөһәндис ...........................
Хикмәтле хикәя ........................

Мөсафирлар һәм Этләр ....................
Рәхәт йокы ...........................
Әлифба .............................
Баланың ата-анасын сөюе ...................
Яхшылыкка яхшылык .....................
Ике Сабан ...........................
Һәркем эштә ..........................
Чылбырдагы Эт ........................

.

Литературно-художественное издание

**Тукай** Габдулла
(**Тукаев** Габдулла Мухамметгарифович)

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

Издание второе

Составитель

**Башир** Фарит
(**Баширов** Фарит Каримович)

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Тукай** Габдулла
(**Тукаев** Габдулла Мөхәммәтгариф улы)

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Икенче басма

Төзүчесе

**Бәшир** Фәрит
(**Бәширов** Фәрит Кәрим улы)

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.Г.Зиннәтуллина, Л.З.Шиһапова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.02.2010.
Форматы 84г108 1/32. Шартлы басма табагы 25,2. Тиражы 2000 д. Заказ В-498.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.